**Институт дополнительного профессионального образования**

**ФГБОУ ВО «Набережночелнинский государственный педагогический университет»**

**МКУ "Управление образования Исполнительного комитета Менделеевского муниципального района"**

**Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение**

**«Средняя общеобразовательная школа №4»**

# «Актуальные направления преподавания родного языка и литературы»

***(МАТЕРИАЛЫ региональной научно-практической конференции)***



**г. Менделеевск**

**28.02.2018**

УДК

ББК

Отв. редактор: Р.М.Мавлеева

Составители: Ю.М.Ширшов, И.Л.Кранго

Электронные ресурсы: от издателей к читателям.

Материалы Региональной научно-практической конференции, РТ,

г. Менделеевск, 28 февраля, 2018 г. / Сост. И.Л.Кранго, Ю.М.Ширшов; отв. ред. Р.М.Мавлеева / МБОУ «СОШ №4» Менделеевского муниципального района РТ, 2018. - 215 с.

## ПРЕДИСЛОВИЕ

Представляемый читателям сборник издается по итогам работы региональной научно-практической конференции «Актуальные направления преподавания родного языка и литературы», проведенной , в г. Менделеевске РТ 28 февраля 2018г.

В сборнике вниманию читателей предлагаются материалы данной конференции.

Организатором данной конференции является МБОУ «СОШ № 4» г. Менделеевск, учителя - предметники, МКУ "Управление образования Исполнительного комитета Менделеевского муниципального района РТ".

Конференция является обозначением проблем и путей их решения в сфере изучения языков народов Российской Федерации, в том числе государственных языков Республики Татарстан, а также повышение интереса учащихся к изучению родных языков.

Порядок представления статей — проблемно-алфавитный.

В целом, данный сборник не только обозначил контуры новых подходов к изучению родных языков, но и поставил целый ряд актуальных вопросов.

Представленные в сборнике материалы выражают разные точки зрения на обозначенные проблемы в преподавании родных языков.

Сборник предназначен для учителей родного языка и литературы.

Данный сборник явился результатом работы всех участников конференции. Работы сохранили авторский стиль и грамматику, не рецензировались.

Думается, что материалы, изложенные в статьях участников научно-практической конференции, найдут достойное применение в педагогической практике образовательных учреждений всех видов и уровней.

***«… человек никогда не преуспеет в жизни в широком смысле слова,***

***если однажды не познает успеха в чём-то для него важном…***

***Если ребенку удается добиться успеха в школе,***

***у него есть все шансы на успех в жизни»***

***У. Глассер***

***(американский психолог, профессор,***

***создатель и лидер школы психологического консультирования,***

***автор книги «Школы без неудачников».***

***1925 — 2013).***

## Цели и задачи:

1. Выявление и распространение передового педагогического опыта.

2. Поиск новых приёмов, способов, методов, форм эффективности преподавания родного языка.

3. Повышение интереса учащихся к изучению родного языка.

**Главный редактор:** Мавлеева Р.М.- руководитель ШМО учителей татарского языка и литературы МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №4» Менделеевского муниципального района РТ

**Редакционная коллегия:**

Сафина З. М. –специалист ИДПО НГПУ

Исхакова Р.М. – эксперт аттестационной комиссии МОиН РТ, учитель татарского языка и литературы гимназии №29, г. Наб.Челны

Пупышева Е.Н. – методист ИМЦ

Гильфанова Э.Р.- методист ИМЦ

Васильев О.В., директор МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №4»

Акинина О.Ю., заместитель директора по учебно-воспитательной работе МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №4»

Кранго И.Л. – руководитель ШМО учителей русского языка и литературы МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №4»

Ширшов Ю. М. – учитель информатики и ИКТ МБОУ «Средняя общеобразовательная школа №4»

# Эчтәлек / Содержание


1. **Абдуллина А.С.,** *Зәй муниципаль районы "Зәй 2 нче урта гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе***"Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандартлары нигезендә татар телен һәм әдәбиятын укыту. УУГ формалаштыру методлары"...** стр. 8
2. **Абрамова Т.Н.,** учитель марийского языка и литературы, МБОУ «Ильнетская средняя общеобразовательная школа имени Микая (Герасимова М.С) Менделеевского муниципального района РТ **"Проблемы сохранения и развития родного марийского языка" ...** стр 10.
3. **Абударова И.А.,***учитель английского языкаМБОУ «СОШ №4» Менделеевского муниципального района***"Родной язык – душа народа"** (*Сценарий мероприятияк Международному дню родного языка)* ... стр.12
4. **Аксакова Г.Ш.,** *Мамадыш районы Үсәли мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы* **"Алты эшләпә" алымы**... стр.17
5. **Андреева С.Р.,** учитель марийского языка и литературы, МБОУ «Монашевская СОШ» **«Этнокультурные технологии в образовании и воспитании младших школьников»…** стр.24
6. **Ахметзянова Л.М.,** *Әгерҗе районы Салагыш урта гомуми белем бирү мәктәбенең туган тел һәм әдәбияты укытучысы***"Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә метапредмет компетенцияләр формалаштыру һәм укучыларның коммуникатив күнекмәләрен үстерү"...** стр.24
7. **Багаутдинова Р.Н.,** *МБОУ Красноборская СОШ Агрызскогомуниципального района РТ* **"Шүрәлеләр үч алмый..."**Тукайга ияреп….стр.32
8. **Борһанова Г.Ш.,***Менделеевск шәһәре 4нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **"Татарларны татарча укытыргамы?"...** стр.40
9. **Васильева Т.И.,** *учитель родного языка и литературы,МБОУ «СОШ №3 им. Героя Российской Федерации А.Н.Епанешникова» Елабужского муниципального района РТ* **«Использование метода «кроссенс» на уроках родного языка и родной литературы как средство развития логического и творческого мышления учащихся» (мастер-класс)…** стр.43
10. **Галкина Е.В.,** *МБОУ «Ижевская СОШ» ММР РТ , учитель русского языка и литературы***«Приёмы активизации деятельности учащихся на уроках литературы» (Мастер класс)…** стр.48
11. **Ганиева А.С.,Кәлимуллина А.Х.,** *Менделеевск шәһәре 1 нче урта мәктәбенеңтатар теле һәм әдәбияты укытучылары,***"Туган телем – иркә гөлем"*(****Рус мәктәбенең 4 сыйныфы татар төркеме өчен дәрес конспекты)...* стр.56
12. **Гиззатуллина А.И.,** *Яр Чаллы шәһәренең 41 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **"Катнаш никахның милләт язмышына йогынтысы"...**стр.59
13. **Гомәрова А.М.,***Зәй муниципаль районы "Зәй шәһәре 2 нче урта гомуми белем мәктәбе"нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **"Ф.Хөсни "Сөйләнмәгән хикәя"*(8нче сыйныф, татар төркеме)...***стр.62
14. **Жетыбаева Т.Ж., Сунгатова Р.И.,**учителя русского языка и литературы, МБОУ «СОШ №3» , **«Приемы работы с текстом на уроках русского языка при написании сочинения ОГЭ по русскому языку» (Мастер-класс)...** стр.68
15. **Җиһангәрәева Т.Р., Шәйхетдинова Ә.Б.,***Әгерҗе муниципаль районы Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары* **"Татар телен тирәнтен өйрәнүдә системалы педагогик эшчәнлеккә нигезләнү" ...** стр.73
16. **Забурдаева Р.Р.,***Зәй муниципаль районы"Зәй шәһәре 2 нче урта гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе* **Ю.Ермолаевның «Ике пирожный»**

**әсәрендәге образларга бәя бирү** *(5 нче сыйныфның рус төркеме өчен дәрес эшкәртмәсе)...* стр.77

*17.* **Закирова Г.И.,** *Әгерҗе шәһәре, гимназия №1* **“Китап безне кеше итә...” (Мастер-класс)** **...**стр.80

18. **Закирова Р.А., Муллагалиева Х.М.,***татар теле һәм әдәбияты укытучылары, МБОУ “Гимназия №1”, Менделеевск шәһәре* **“Кеше язмышы кем кулында?”** (9нчы сыйныфта “Бибинур” фильмы буенча үткәрелгән дәрес эшкәртмәсе)...стр. 83

*19.* **Зарипова Ф. Н.,** Менделеевск муниципаль районы, 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, “**“Мин чисталык яратам”** *(Методик эшкәртмә)...* стр.85

20. **Заһидуллина Э.Г.,** *Менделеевск муниципаль районы 3нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Татарстан сувенирлары”** ***(***Сыйныфтан тыш чара)... стр.89

**21. Заһретдинова Ә.Н.,** *Әгерҗе шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе 4 нче санлы урта мәктәбенеңтатар теле һәм әдәбияты укытучысы* **«Фигыль. Нишли? Нишлиләр? сорауларына җавап бирүче фигыльләр»...**стр.92

**22. Зәйнуллина Э.Т., Хәйбрахманова А.Ә.,** *Алабуга шәһәренең 10нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе* **«Дәресләрдә яңа мәгълүмати технологияләр һәм актив методлар кулланып, укучыларда телне өйрәнүгә кызыксыну уяту”...** стр.103

**23. Ибатуллина Ф. А.,** *Менделеевск шәһәре 1 нче урта мәктәбенеңтатар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Тулы һәм ким җөмләләр”...** стр.107

**24. Ильина Э.Н.,** *учитель родного (марийского) языка и литературы, МБОУ Бимской СОШ Агрызского муниципального района Республики Татарстан «* **Урок родного языка в условиях информационного общества»…** стр. 116

25. **Каишева Т.М.,** *учитель русского языка и литературы, МБОУ «Большешурнякская средняя общеобразовательная школа»Елабужского муниципального района РТ «***Проблема сохранения и развития родного русского языка и литературы»…** стр.121

26. **Каримова А. М.,** *Менделеевск шәһәре 1нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы,* **“ Татар телен аралашу аша өйрәтү” ...** стр.128

**27. Касимова В.Н.,** *башлангыч сыйныф укытучысы,* **Лотфуллина И.З.,** *мәктәп китапханәчесе, Әгерҗе муниципаль районы Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе* **“Бәетләрдә халкым язмышы”...**стр.130

28. **Кашапова Г.Х.,** *учитель татарского языка и литературы МБОУ «СОШ №4» Менделеевского муниципального района* **“Слово о родном языке” ...** стр.139

**29. Мәтҗанова Р.Г., Салихова А. Н.,** *МБГББУ “Сарман гимназиясе”нең татар теле һәм әдәбияты укытучылары* **“Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект эзләнү эшенең башкарылу юллары”...** стр.144

**30. Мавлеева Р.М.,** *Менделеевск шәһәре 4 нче урта мәктәбенеңтатар теле һәм әдәбияты укытучысы,* **Аяз Гыйләҗев” Җомга көн, кич белән...”(презентация)...**стр.148

*31.* **Мингалиева В. Р.,** *Менделеевск шәһәре 2 нче урта мәктәбенеңтатар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Дару үләннәре” (***4 нче сыйныф, рус төркеме)...* стр.150

**32. Мингалиева Н.А.,** *Менделеевск шәһәре 2нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Ана телен укытуны камилләштерү”...** стр.155

**33. Михайлова С.Т.,**МБОУ «Ильнетская СОШ имени Микая (Герасимова М.С.)» Менделеевского муниципального района РТ **Конкурс « Знатоки родного языка» (**Внеклассное мероприятие, посвящённое Международному дню родного языка) … стр.158

**34. Мортазина Л.И.,** *Әгерҗе муниципаль районы Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы* “**Башлангыч сыйныф укучыларының**

**коммуникатив күнекмәләрен формалаштыруда проект эшчәнлеген файдалану үзенчәлекләре”...**стр.162
35. **Мулланурова Лариса Данифовна,** *Менделеевск шәһәре 3 нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Ашамлыклар”** *(дәрес планы)...*стр.163
**36. Нуркаева Г.Ф.**, *Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 9нчы урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Без ашханәгә барабыз”...**стр.168
**37. Ризванова Ә. Ә., Ногманова Г.Ф.,** *Әгерҗе шәһәре 1нче гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары* *“**XX гасыр 20-30 нчы еллар татар әдәбияты**“* (**Татар әдәбиятыннан планлаштырылган метапредмет нәтиҗәләрен бәяләү өчен контроль-диагностик материаллар)...**стр.170
38. **Садыкова А.Н.,** *Менделеевск шәһәре 1нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***“Сәләтле балалар белән эшләү”...**стр.172
*39.* **Садыкова Г. Р**., *Зәй муниципаль районы 6 нчы урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **«Сәламәт бул!»** ***(1 нче сыйныф, рус төркеме)...***стр.176
40. **Семякова Е.Б.,** *учитель начальных классов, МБОУ «Ильнетская СОШ имени Микая (Герасимова М.С.)» Менделеевского муниципального района РТ* «**Роль семьи в сохранении и развитии родного языка и национальных традиций»…** стр.182
41. **Смирнова Г.Р.,** *Менделеевск шәһәре 1нче урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Татар теле дәресләрендә сәләтле балаларның дивергент фикерләвен үстерү чарасы буларак фәнни тикшеренү эшчәнлеген оештыру”...**стр.185
42. **Тухбатова Ч.И.,** *Менделеевск муниципаль районы “Ижевка урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Татар теле һәм әдәбиятын укытуда килеп чыккан кыенлыклар һәм аларны чишү юллары”...**стр.189
43. **Умнова Л. И.,** *Тукай районыМәләкәс гомуми урта белем бирү мәктәбенеңтатар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Сынмаганнар, сыгылмаганнар...”** *(Татар мәктәбенең 8 нче классында А. Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәрен өйрәнү)...*стр.192
*44.* **Фатыйхова Ф.Ә,** *Алабуга шәһәре Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 9нчы урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Кышкы табигать”** *(4 нче сыйныф, рус төркеме)...*стр.202
**45. Шайдуллина Г.Х.,** *Алабуга муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе “Россия Федерациясе Герое А.Н.Епанешников исемендәге 3 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **“Чөнки, шуңа күрә теркәгечләре”***(“Безнең Татарстан” тексты буенча)...*стр.204
46. **Шафикова Г.Р.,** *Алабуга муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе“Россия Федерациясе Герое А.Н.Епанешников исемендәге 3 нче урта гомуми белем мәктәбе” нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы* **Ихсан Әхтәмнең “Ана рәхмәте” хикәясе...**стр.209

**“Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандартлары нигезендә татар телен һәм әдәбиятын укыту.УУГ формалаштыру методлары.”**

**Абдуллина Айгөл Сөләйман кызы,**
*Зәй муниципаль районы*
*“Зәй 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*

Җәмгыять һәм икътисадтагы бик тиз үзгәрешләр кешедән яңа шартларга җайлашуны, катлаулы сорауларны оптималь хәл итүне, билгесезлек ситуацияләрендә югалып калмауны, төрле кешеләр белән аралашуны дөрес көйләүне, һәм шул ук вакытта әхлаклы, әдәпле кеше булып калуны таләп итә. Заманча мәктәпнең бурычы – үзен мөстәкыйль тормышта ышанычлы хис иткән кеше тәрбияләү.

Федераль дәүләт стандартлары әлеге бурычны үтәргә мөмкинлек бирә. Стандартның нигезендә системалы-эшчәнлекле юнәлеш ята. Моннан чыгып,бүгенге көндә укытучыдан укучыга әзер белем тапшыру системасыннан баш тартырга кирәк. Укытучының бурычы –балаларда белем алырга кызыксыну һәм теләк уяту, аларны уку эшчәнлегенә кертеп җибәрү, мөстәкыйль уйларга, алган белемнәрен практикада куллана белергә өйрәтү. Яңа буын федераль дәүләт стандартларының принципиаль аермалыгы булып белем алуның күрсәткеченә, нәтиҗәсенә ориентлашу тора.

2010 нчы елдан башлап пилот мәктәп режимында яңа стандартны тормышка ашыру өстендә эшли башладык. Безнең мәктәптә барлыгы 5 татар теле укытучысы эшли. Башка предмет укытучылары белән бергә норматив документларны өйрәндек, яңа стандарт белән иске стандартларның аермасын карадык, төп укыту программасын эшләү өчен эш төркемнәре оештырдык, татар теле һәм әдәбиятыннан 1-4 нче һәм 5-9 нчы сыйныфлар өчен эш программалары төзедек. Үзебезнең татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмәсе утырышларында, төрле чыганаклардан информация алып, ФДББС шартларында үткәрелә торган заманча дәрес структурасын төзедек, дәрескә технологик карта төзергә өйрәндек, укучыларның белемнәрен бәяләү критерийларын булдырдык, шулай ук дәрестән тыш эшчәнлек буенча 4, 5, 6 нчы сыйныфларда иҗади түгәрәкләр оештырдык.

Хәзер, дәрескә әзерләнер өчен, башка еллар белән чагыштырганда, укытучыга күбрәк вакыт кирәк. Элек без дәрестә планлаштырылган бар нәрсәгә өлгерергә омтыла идек, хәзер укучыларның эзләнү, материал туплау, уку бурычын дөрес билгеләү эшчәнлеген оештырырга тиеш, чөнки Федераль дәүләт стандартының аерылгысыз өлеше булып универсаль уку гамәлләре тора. Планлаштырылган нәтиҗәләр предмет буенча гына түгел, ә шәхси һәм метапредмет булырга тиеш. Шулай ук укучының үзбәяләвенә, үзүсешенә ориентлашырга кирәк.

Универсаль уку гамәлләре балага уку эшчәнлеген мөстәкыйль башкарырга, аның максатын куя белергә, шул максатка ирешү өчен тиешле алымнар һәм чаралар сайларга, эшчәнлекнең барышын күзәтеп барырга һәм нәтиҗәләрен объектив бәяләргә мөмкинлекләр тудыра.

***Уку гамәлләре универсаль***: алар аерым фәннәр өстендә тора, төрле фәннәрне өйрәнүне системага берләштерә, бер фәндәге гамәлләр башка фәннәрне өйрәнүгә күчерелә ала; гомуммәдәни, шәхси һәм танып белүдә үсеш һәм шәхеснең үзүсешен, белем бирү процессының барлык баскычларында дәвамчанлык, күчүчәнлек булдыра; махсус фән эчтәлегенә карамастан, баланың һәртөрле эшчәнлеген оештыру һәм тәртипкә салуның нигезе булып тора. Универсаль уку гамәлләре – уку эчтәлеген үзләштерүнең һәм балаларның психологик сәләтләрен үстерүнең ышанычлы шарты.

Универсаль уку гамәлләреформалаштыру берничә этапны үтә:

1) иң элек фәнне өйрәнгәндә укучыда уку гамәлен үтәүдә беренче тәҗрибә һәм аны мөстәкыйль рәвештә үтәүгә мотивация формалаша;
2) аннары, булган тәҗрибәгә нигезләнеп, укучы универсаль уку гамәлләрен үтәүнең гомуми ысулларын үзләштерә;
3) алга таба өйрәнелгән УУГ төрле уку дисциплиналарының предмет эчтәлегендә практикалаштырыла, үзконтроль оештырыла, әгәр кирәк булса, төзәтү кертелә;
4) ахырдан, дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда УУГ формалашу дәрәҗәсенә контроль ясала һәм укыту процессында системалы куллану оештырыла.

Кайбер укытучылар, аеруча татар теле укытучылары, укучыларның белем алуга карата түбән мотивация булу проблемасы белән очрашалар. Бу очракта УУГ формалаштыру аеруча мәгънәгә ия.

Танып белүгә мотивация булдыруда бик эффектив чара – дәрестә проблемалы ситуацияләр тудыру. Бала белемне әзер килеш түгел, ә үз хезмәте, үз тырышлыгы белән эзләп ала. Укучының нәрсәнедер белмәве турында белүе дәреснең әһәмиятле нәтиҗәсе һәм яңа теманы аңларга стимул булырга тиеш.

Информацияне кабул итүдә “Беләм – беләсем килә – белдем - өйрәндем” дигән алым бик уңышлы. “Беләм” этабында балалар парларда эшлиләр, “Беләсем килә” – максат кую этабы, “Белдем” этабында укучы яңа һәм иске информацияне чагыштыра, “Өйрәндем”- эшчәнлекнең нәтиҗәсен аңлау этабы.

Шулай ук, текст белән эшләү, текст буенча план төзү, прогноз ясау, мәсәлән сез текстны ничек дәвам итәр идегез?, текст яки тема буенча “верное – неверное утверждение”, кластер төзү, диалог, дискуссия, төркемнәрдә, парларда эшләү, проект эшчәнлеге, эзләнү-тикшеренү эшчәнлеге, театральләштерү, экиятләр, хикәяләр, балладалар язу – болар барысы да универсалҗ уку гамәлләрен формалаштыруда зур урынны алып торалар.

Яңа стандартлар нигезендә укучыларның белемен бәяләү системасы да яңа. Укучыларның предмет буенча белемнәре белән бергә УУГ формалашуы да бәяләнә. Контроль – диагностик материаллар комплекты үз эченә контроль эш, мөстәкыйль эш, практик эш биремнәрен, диктантларны, тестларны һ.б. формаларны үз эченә ала. Бәяләү чаралары комплекты эш программасының бер өлеше һәм мәктәп администрациясе, яки күзәтү органының тикшерү объекты булып тора.

Яңа стандартларны тормышка ашыруда берникадәр **проблемалар** да килеп чыкты

- дәреслекләр җитмәү;

- элекке еллардагы дәрес үткәрүнең тотрыклы методикасы яңа форма һәм технологияләрне куллануны ниндидер күләмдә тоткарлый;
- проект эшчәнлеге укытучыдан проект методларының технологиясен югары дәрәҗәдә белүен таләп итә;
- метапредмет гамәлләрне формалаштыруны бәяләү өчен диагностик материаллар булмавы укытучының эшен авырайта;

Проблемалар күп. Аларны хәл итеп була. Яңа стандартлар нигезендәге белем бирүнең максатларын тормышка ашыру гарантиясе булып укытучының педагогик эшчәнлеккә карата яңа позициясе, яңа мөнәсәбәте тора.

## <u>Проблемы сохранения и ряазвития родного марийского языка</u>

**Абрамова Т.Н.,**
*учитель марийского языка и литературы*
*МБОУ «Ильнетская средняя общеобразовательная школа*
*имени Микая (Герасимова М.С)*
*Менделеевского муниципального района РТ*

В соответствии с законом Российской Федерации «Об образовании» одним из главных принципов государственной политики в сфере образования в настоящее время является единство федерального, культурного и образовательного пространства, защита и развитие системой образования национальных культур, региональных культурных традиций и их особенностей в условиях многонационального государства. Духовные ценности, составляющие содержание национальных культур и региональных традиций, — это родной язык, мудрые жизненные устои наших предков, т.е. гуманные адаты, способы организации труда, художественные промыслы, украшающие жизнь людей, праздники, обряды, многожанровый фольклор марийцев и многое другое. Не случайно на первом месте среди составляющих содержание нашего наследия стоит родной язык. Ибо родной язык является специфической формой национальной культуры, несущей информацию из глубины веков. Еще К.Д. Ушинский обращал внимание на то, что родной язык есть самая живая связь, соединяющая отжившие, живущие и будущие поколения народа в одно великое историческое целое. В языке народа сокрыты все его думы и чаяния, его характер, его стремления. И с уверенностью можно сказать, что народ, чьи дети не говорят на родном языке и не знают традиций, обычаев своих предков, не соприкасаются с художественными промыслами, обречен на постепенную духовную гибель. В этих условиях одной из важных проблем в обучении и воспитании является сохранение и развитие родных языков, культур. Этому и мы являемся свидетелями. Ведь в нашей многонациональной республике функционируют не только школы, где обучаются дети какой-то одной национальности, но и школы со смешанным национальным составом учащихся. Сам факт, что школы со смешанным национальным составом учащихся в республике получили большое распространение нужно признать явлением положительным, особенно с точки зрения решения национальных проблем.

Действительно, совместное обучение детей разных национальностей в одной школе является одним из факторов сближения и единения народов, проживающих в республике. Свою работу по обучению родному языку мы начинаем с разъяснения того, что овладение своим национальным языком любому человеку необходимо, чтобы не потерять духовные связи со своим народом, с национальной культурой. Думаю, родителям стоит вести разъяснительную работу о необходимости изучения родного языка подрастающим поколением. Ведь знание языка родного этноса - нравственный патриотический долг каждого марийца. «Успешно обучать детей родному языку можно и нужно в семье. Приоритетную роль в этом деле играет мать. При отсутствии заинтересованности ребенка и поддержки семьи даже под руководством талантливого учителя и при наличии хорошего учебника трудно достичь изучения ребенком родного языка». Культура, традиции, язык, черты национального характера и особенности национальной психологии, устная поэзия народа с раннего детства должны войти в кровь того, кто в свое время станет педагогом, передающим эти ценности подрастающему поколению. Культурно-нравственные ценности родного народа подрастающему поколению следует передавать не как безжизненные реликвии славного прошлого, а как нравственно - этнический ориентир во всей их предстоящей взрослой жизни, что в дальнейшем поможет нам, учителям, решить проблему сохранения и развития родных языков, культур, традиционных промыслов марийского народа. Определенный опыт в этом плане накоплен преподавателями нашей школы, где преподавание предметов марийский язык, как нам кажется, на должном уровне. Родной язык в школе преподают специалисты, имеющие высшее образование. В школе имеется учебный кабинет марийского языка и литературы. Наша учебная база полностью укомплектована учебниками, наглядными пособиями таблицами, дидактическим материалом. Привитию интереса к языку, культуре, традициям родного края, народным промыслам способствует внеклассная работа. Кроме конкурсов, классных часов, открытых уроков, недель родного языка и литературы в школе за последние 2 года наши обучающиеся участвуют и становятся победителями научно-практической конференции и чтений школьников на языках народов Российской Федерации в городе Казань. Каждый год учащиеся нашей школы становятся победителями олимпиады по марийскому языку и литературе в муниципальном туре. Отрадно отметить, что для решения проблемы сохранения, развития родных языков, культур, традиционных промыслов в последние годы продолжается практика проведения республиканских олимпиад по марийскому языку, где наши обучающиеся показывают хорошие результаты. Для развития марийского языка, культуры, традиционных промыслов среди населения необходимо тесно сотрудничать со средствами массовой информации. В школе ежегодно ведется подписка газет «Марий эл», «Кугарня» и детского журнала «Ямде лий». С журналом тесно сотрудничают дети: они высылают свои интересные статьи и фото. В школьной библиотеке проводятся выставки новых детских книг. В школе функционирует детский марийский фольклорный кружок. Детей обучает марийским танцам и пениям, знакомит с обычаями и традициями марийского народа учитель

марийского языка Абрамова Тамара Николаевна. Детский ансамбль «Марий сем» является дипломантом и лауреатом многих районных, региональных, республиканских конкурсов. От знания и владения родным языком любой гражданин, специалист ничего не потеряет, наоборот, приобретает необходимый уровень грамотного общения и выполнения жизненных, служебных и коллективных потребностей. Это поможет ему лучше знать, понимать историю своего народа, его культуру и национальные ценности. Молочным языком называют аварцы родной язык, языком матери - марийцы. Сохраним же языки, передающие духовные ценности каждого народа грядущим поколениям. И как сказал великий поэт с мировым именем Расул Гамзатов: «И если завтра мой язык исчезнет, То я готов сегодня умереть».

## Родной язык – душа народа

*(Сценарий мероприятия*
*к Международному дню родного языка)*

**Абударова Индира Адельевна,**
*учитель английского языка*
*МБОУ «СОШ №4»*
*Менделеевского муниципального района*

***Цель мероприятия:***: познакомить ребят с Международным днем родного языка, формировать бережное отношение, как к родному, так и другим языкам, гордость за свой родной язык, чувство принадлежности к своим предкам, народу, культуре, воспитывать патриотизм, толерантность

***Задачи:***

1. Помочь учащимся увидеть и почувствовать неисчерпаемые возможности родного языка;
2. Продолжать развивать и устную связную речь учащихся, мыслительную деятельность, память, воображение, внимание; обогащать словарный запас учащихся; расширять их кругозор.
3. Прививать любовь и интерес к родному языку и иностранным языкам, воспитывать культуру речи.

***Оборубование:*** мультимедийная презентация; карточки с заданиями для конкурсов -«Дополни пословицу», «Грамотеи», жетоны.

***Форма проведения:*** конкурс «Знатоки языка».

**1ведущий**: Хәерле көн димен барчагызга,
Кояшлы көн телим гөлләргә,
Сөйкемлелек телим яшь кызларга
Ә батырлык сезгә - егетләргә!

**2ведущий:** Добрый день, дорогие друзья! Сегодня мы собрались не случайно. По решению ЮНЕСКО 21 февраля - Международный день родного языка .И по этому случаю мы сегодня собрались на большой праздник.

**3-йведущий:** Hello, dear friends and our guests!  We all were born in our wonderfull multinational republic Tatarstan and speak different languages. Today we are commemorating the “Day of Languages”. This event dates back to the day when the students of Bangladesh went to the demonsnrtation , they demanded to declare their native language as a governmental one

**1ведущий:**21 февраль – Халыкара туган тел көне. Дөньяда 7000 гә якын тел бар. Шуларның 83е киң таралган. Ә 383 тел бөтенләй юкка чыгарга мөмкин. Мәсәлән Силец Дини телендә 1 кеше, Африка урманнарында яшәүче ючи кабиләсе телендә 5 кеше генә сөйләшә.

**3-йведущий:** There are more than five thousand languages in the modern world. Everylanguagehasitsownhistoryanddignity

**2ведущий**: Один из постулатов древности гласит: «Врата мудрости никогда не бывают закрытыми». Изучая родной язык, вам, возможно, удастся чуть пошире распахнуть эту таинственную дверь мудрости

**Ученик №1**

Сегодня все наречия планеты

Идут единой поступью под марш,

Неся в себе культуру милой речи,

И уникальность среди равных масс.

Родной язык - богатое наследство,

Пришедшее из глубины веков.

Ты отражаешь мысли человека,

Ты помогаешь выразить любовь,

Ты создаешь из букв стихотворенья.

Храня в запасах сотни тысяч слов,

Спустившееся к нам благословенье –

Родной язык, проникший в нашу кровь.

**3-й ведущий:** А сейчас послушаем шуточное стихотворение
(Ученик 1)
Если б знали вы, ребята,
Как бывает трудно нам:
В изученье иностранном
Ох, как много разных драм!

Как Петрову дать герундий,
Как про Passive рассказать,
Как заставить на уроке
Свои знанья показать?

Монолог у Teacher чаще,
Только Teachers говорят.
Почему упорно Pupils
На уроке всё молчат?

«Мин, апа, ваш English не знаю», –
Сказал Шакиров Айдар. –
«Мин его не понимаю.
Said me ,Багавиев Ильдар

Мы хотим сказать, ребята:
Без языков сейчас никак –
Инженер ли, аппаратчик,
В будущем без знаний – крах!

Изучайте, расширяйте
Кругозор свой, слов запас.
Времени зря не теряйте.
Иностранный много даст.

Нужен для поездок разных,
Чтоб инструкции читать,
Чтоб смотреть TV – каналы
Или дипломатом стать.

Изучайте, обладайте
Знания вам так нужны.
**Времени зря не теряйте**
А помощники вам – мы!

**2 ведущий:** Великий татарский поэт Габдулла Тукай понимал, как необходимо для татарского народа приобщение к мировой культуре, сближение его с другими народами и их языками.

**(стих на английском)Туган тел**

**1 ведущий**

- А сейчас, дорогие ребята, уважаемые гости, мы проведем турнир «Люби и знай языки!» Давайте же покажем, что мы знаем, любим, относимся бережно к родному языку, а еще знаем и другие языки.

Итак, первый конкурс (тур)

**1 Ведущий.** 1 тур «**Жемчужины родного языка»**

Эпиграфом к этой странице мы взяли слова М.Горького: «В простоте слова – самая великая мудрость. Пословицы всегда кратки, а ума и чувства в них на целые книги»

У каждого народа о родном языке созданы пословицы, поговорки.

**2 Ведущий:** Задание: предлагается начало пословицы, а вы должны продолжить.

- Что написано пером- **не вырубишь топором.**
- Слово не воробей: **вылетит- не поймаешь.**
- Живое слово **дороже мёртвой буквы.**
- Лучше ногой запнуться, **чем языком**.
- **Язык до Киева доведёт**.
- Хорошо говоришь, **да было бы что слушать.**
- Язык мой- враг мой: **прежде ума ( наперёд ума) глаголет**.
- Языком не торопись, **а делом не ленись**.
- Много говорено, **да мало сказано.**

Авыз күрке – тел, ... (тел күрке сүз.)
Бауның озыны, ... (сүзнең кыскасы яхшы)
Әйткән сүз - ... (аткан ук)
Яхшы сүз – җан азыгы, ... (яман сүз – баш казыгы)
Картларның сүзен ... (янчыкка җый)
Сөйдергән дә тел, ... (көйдергән дә тел)
Авыздагы сүзгә син хуҗа, ... (авыздан чыккач җил хуҗа)

**2 ведущий: 2 конкурс**
**Подбери англ эквивалент к русским пословицам**

**3 ведущий. And now translate please these proverbs from Russian into English**
A friend in need is a friend indeed. — **Друг познается в беде**.
Live and learn. **— Век живи — век учись**.
Knowledge is powerю-**Знание- сила**
A good beginning makes a good ending. — **Лиха беда начало**.
It's never too late to learn. — **Учиться никогда не поздно.**
Rome was not built in a day. **— Москва не сразу строилась**.
First think, then speak. — **Слово не воробей, вылетит — не поймаешь.**
Two heads are better than one. — **Ум хорошо, а два лучше.**

**Музыка бию кое**
**1ведущий** Татар халкы элек-электән җырга, моңга гына түгел, биюләргә дә бик оста халык була.
Биюченең итәкләре
Бии, бии кыскара
Биючегә сүз әйтмәгез
Бии-бии остара. *(татарский танец)*
**2ведущий** Родные языки множества наций, проживающих в одной стране «Нанизаны словно на нитку одну». Их цель одна – передать мудрость, накопленную веками – своим потомкам.
***Ученик** СТИХ на татарском языке(звучит мелодия)*
**2ведущий:** Наш родной язык как хлебосольный хозяин радушно распахивает двери перед языками других национальностей, обогащаясь в свою очередь словами и выражениями. Ничто на свете не связано с человеком так прочно как язык. Нет на свете лучше средства общения. Чем лучше ты владеешь родным

языком, а также другими языками, тем больше у тебя права называться человеком.

**1 ведущий** О красоте и богатстве языка высказывались многие мудрецы, государственные деятели, писатели. А знаете ли вы?

**3 тур (Угадайте цитату)**

1) И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле (Г.Тукай)

2) И минем җандай кадерлем
И җылы, тере телем! (Х.Туфан)

3) Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел,
Икесе дә безнең өчен
Бик кирәкле, затлы тел. (Шәйхи Маннур)

4) .How many languages you know — that many times you are a person.

Сколько языков ты знаешь, столько раз ты человек.

5) A different language is a different vision of life

Другой язык – это другое видение жизни.

(Фредерико Феллини)

6) . To have another language is to possess a second soul.

Владеть другим языком – это как иметь вторую душу.

(Карл Великий)

7). Language is the road map of a culture. It tells you where its people come from and where they are going.

Язык – это дорожная карта культуры. Он поведает, откуда пришли его люди и куда идут.

(Рита Мэй Браун)

8) He who does not know foreign languages does not know anything about his own.

Кто не знает иностранных языков, ничего не знает и о своём собственном.

(Гёте)

**1ведущий** Һәр халыкның туган теле – аның мәдәнияте, тарихи көзгесе. Шуңа да телебез сафлыгы, матурлыгы, аһәңлелеге өчен барыбызга да армый-талмый көрәшергә, эшләргә кирәк.

**2 ведущий** Говоря каждый на своем родном языке, гражданин мира привносит в него что –то свое, собственное, но всегда нужное и полезное. Человек с самого раннего детства слышит и запоминает и говорит на родном и любимом, на своем языке. Любовь к языку зарождается в нас с колыбельных песен и сказок.

***3-йведущий:*** From the early childhood human's life is connected with his native language. A child learns to speak while listening his granny's fairy-tales and mothers cradle-songs.

**Сказка «Теремок» на английском языке**

**3 конкурс «Конкурс загадок»**

**1 ведущий**: Родной язык. Он впитан с молоком.

Звучит как музыка, нам сердце услаждая

В международный день родного языка

На языке родном тебе мы пожелаем:

Люби язык, храни на день и на века!

Не забывай мелодию родного языка.

Сакла телне, ярат телне

Тел ул боек, тел кадерле!

**3 Ведущий:** Dear friends! Learn more foreign languages and don't forget your own native language!

**Исполнение песни:** «Туган тел» на трех языках.

## “Алты эшләпә” алымы

**Аксакова Г.Ш.,**
*Мамадыш районы Үсәли мәктәбенең*
*башлангыч сыйныф укытучысы*

Әдәби уку — башлангыч мәктәптә төп предметларның берсе. Бу фән аша кече яшьтәге мәктәп баласына һәрьяклы белем бирелә. Укучының аңы дөньяны: әдәби әсәрләрне генә түгел, безне чолгап алган тирәлекне — кешеләр һәм табигать дөньясын да — дөрес кузалларлык сизгер була. Бары тик югары аң тәрбияләп кенә әйләнә-тирәлекне дөрес күзалларга мөмкин.

Федераль дәүләт белем стандарты информацион җәмгыятьтә аралашырлык шәхеснең күпьяклы үсешен күздә тота.

Башлангыч мәктәптә әдәбият дәресләренең төп максаты: 4 ел уку дәверендә балада дөрес һәм йөгерек уку күнекмәләре булдыру, халык авыз иҗаты, язучы һәм шагыйрьләр әсәрләре белән якыннан таныштыру, чәчмә һәм шигъри әсәрләрне укып, аларны анализларга, эстетик ләззәт алырга өйрәтү.

Федераль дәүләт белем стандартын куллану элекке текст белән эш алымнарын кире кагу дигән сүз түгел. Ләкин, әсәрләрне анализлаганда дәресне әзер схема буенча алып бару, һәрвакыт укытучы фикере белән килешү, барлык укучылардан да бертөрле, охшаш җаваплар таләп итү кебек алымнардан баш тартырга кирәк. Балаларны башлангыч сыйныфтан ук әсәргә анализ ясарга, тексттагы күренешләргә, геройларга үз мөнәсәбәтләрен белдерә белергә өйрәтү мөһим. Балаларның әсәргә мөнәсәбәтләре төрлечә булырга, әсәр эчтәлеге буенча төрле бәхәсләр туарга мөмкин. (Укытучы балаларга “Синең фикерен дөрес түгел” дип әйтергә тиеш түгел.) Балалар барысы да бертөрле уйлый алмый, аларда укытучы уйламаган яңа фикерләр дә туарга мөмкин. Балаларның креатив фикерләү сәләтен үстерү өчен дә әдәби әсәрләр иң кулай материал. Федераль дәүләт стандартларын тормышка ашыру максатыннан мин әдәби уку дәресләрендә тәнкыйди фикерләү технологиясенең **“Алты эшләпә” алымын** кулланам. Ул Британия психологы, язучы Эдвард де Бононың 1970 нче елда бастырылып чыккан “Фикерләүнең алты эшләпәсе” теориясеннән алынган. Ул

киң таралган “баш миен штурмлауның” (мозговой штурмның) иң популяр алымы булып тора.

Бу алым ярдәмендә балалар оялмыйча үз фикерләрен әйтә алалар, чөнки теге яки бу проблеманы чишкәндә фикерләр төрле булачак, ягъни “Алсу болай диде, минеке дөрес булмас” дигән нәрсә юк. Димәк, кыска гына вакыт аралыгында проблема төрле яклап карала. Бу үз чиратында тыйнак яки сүлпән укучыларда тәвәкәллек уята, проблеманы мөстәкыйль чишүгә ышаныч тудыра. Фикерләргә өйрәтә.




Проблема 6 яктан тикшерелә:

Ак эшләпә - өйрәнгән мәгълүматның уңай якларын әйтәләр

Сары эшләпә – – нинди яңа мәгълүматлар белгәннәрен әйтәләр

Кара эшләпә – тискәре якларын

Кызыл эшләпә – укучылар үзләренең эмоцияләрен белдерәләр

Яшел эшләпә – креатив, иҗади фикерләрен әйтәләр, фаразлар (икенче төрле булса, ничек булыр иде)

Зәңгәр эшләпә – барлык фикерләрне гомумләштереп, йомгаклап әйтү

**“Алты эшләпә” алымы** төркемләп эшләү ысулы балаларга бик ошый. Укучылар күп төрле булган кебек, аларның фикерләүләре дә, дөньяны танып-белүләре дә төрле. Укучыларны өч яки алты төркемгә бүләбез. Алымны куллана башлаганда, өйрәтү өчен башлангыч сыйныфта өч төркем дә җитә. 4 сыйныфта алты төркемгә дә бүләргә була. Аларның һәрберсенә төрле төстәге эшләпә бирәбез. Нинди төстәге эшләпә алуга карап, укучылар укылган әсәр буенча геройларга карата үз фикерләрен белдерәләр, проблемаларны анализлыйлар, нәтиҗәләр чыгаралар. Бу алымны 4 сыйныфта өйрәнелә торган Фатих Хөснинең “Сөйләнмәгән хикәя” әсәре өстендә карап үтәрбез.

**Дәреснең технологик картасы**

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| I.Оештыру,мотив-лаштыру | 1.Исәнләшү,уңай психологик халәт тудыру.<br>Матур итеп елмаеп<br>Исәнләшик, дусларым.<br>Малайларым, кызларым,<br>Исәнмесез, дусларым!<br><br>-Ә хәзер мин сезнең һәркайсыгыз белән сүзләр түгел, ә күзләр белән тыныч кына,эндәшмичә генә исәнләшеп чыгам. Шул ук вакытта сез миңа күзләрегез белән кәефләрегезне дә күрсәтергә тырышырсыз.<br><br>2.**«Аң штурмы» алымы**<br><br>− Бүген ничәнче число?<br><br>− Атнаның кайсы көне?<br><br>−Сыйныфта кем кизү?<br><br>−Барлык укучылар да дәрестәме?<br><br>−Һава торышы ничек?<br><br>−Кәефләрегез нинди? | Исәнләшү.Дәрескә әзерлекне күрсәтү.Укытучыны сәламләү.<br><br>Сорауларга җавап бирү, сөйләм эшчәнлегенә кушылу. |
| II.Төп өлеш. | -Бүген без сезнең белән, укучылар,Ф.Хөснинең “Сөйләнмәгән хикәя” әсәрен укырбыз. Әсәр буенча геройларга карата үз фикерләребезне белде-рербез,проблемаларны анализларбыз, нәтиҗәләр чыгарырбыз.<br>Моның өчен фикерләү технологиясенең “АЛТЫ ЭШЛӘПӘ” алымы кулланабыз. Ул Британия | |

| | | |
|---|---|---|
| | психологы, язучы Эдвард де Бононың 1970 нче елда бастырылып чыккан “Фикерләүнең алты эшләпәсе” теориясеннән алынган. Эшне башлау өчен алты төркемгә бүленергә кирәк булачак. Алты төстәге эшләпәләрне киеп төрлечә фикер йөртә башлаячаксыз.<br><br>**<u>Сары эшләпә.</u>**<br>Бу төркемдәге укучылар бары тик фактлар белән генә эшли. | Укучылар “Сөйләнмәгән хикәя”нең төп вакыйгаларын санап чыгалар, нинди персонажлар булуын әйтәләр һәм аларга кыскача бәя бирәләр. Төркемдәге һәр укучы үз фикерен әйтә. Әсәрнең персонажлары: Биктимер, чабатачы Әхми, әнисе, малайлар.<br>Чабатачы Әхми гаиләсе бик ярлы булган, хәтта коймак пешерү өчен дә, таба эзләп, күршегә чаба торган булалар. Әнисе Биктимерне таба алырга югары очка җибәрә. Ул кайтканда тауда чана шуучы малайларны күрә һ.б.вакыйгалар әйтелә. |
| | **<u>Ак эшләпә.</u>**<br>Әсәр турында бары “Ак уйлар”, бары тик уңай фикерләр генә әйтелә. Һәр вакыйганың, образның позитив яклары турында сөйләнә. Ни өчен шулай | “Сөйләнмәгән хикәя”нең төп герое Биктимер тыңлаучан. Ул әнисе эш кушуга ук чыгып |

| | | |
|---|---|---|
| | уйлаулары турында аңлаталар.<br><br>**<u>Кара эшләпә.</u>**<br>Бу эшләпәне алган төркем нәкъ киресен, ягъни вакыйгаларның тискәре якларын гына сөйлиләр. Килеп чыккан проблемаларга бәя бирәләр.<br><br>**<u>Кызыл эшләпә.</u>**<br>Бу эшләпә эмоциональ фикерләүне таләп итә. | йөгерә. Акыллы. Хыялый, уйлап табучан. Табага утырып, таудан шуу кемнең башына килер иде икән? Берәр башка малай булса, кызыгып карап торыр иде дә, кайтып китәр иде. Таудан шуганда ул бәхетле минутлар кичерә. Канатлы кошка охшап кала. Бар да аңа кызыгып карыйлар. Минем дә аның кебек табага утырып шуасым килеп китте, дигән җавапларны ишетергә була.<br><br>Туйганчы коймак ашап, рәхәт кичерергә әзерләнгән Әхми гаиләсенең хыялы тормышка ашмый, гаилә ач кала. Кем гаепле? Биктимер әнисе кушканны онытып, көн буе тауда шуды, шуңа күрә коймак пешмәде, гаилә бәхетле мизгелләр кичермәде. Үзен бәхетле тойган Биктимер ата-анасы турында онытты. Ул дөрес эшләмәде. Өйгә кайткач, әнисе аны кыйнарга теләде. Бу минутта малай да бәхетсез иде.<br><br>Рәхәтләнеп тау шуучы малайларны күргәч, |

| | | |
|---|---|---|
| | **<u>Яшел эшләпә.</u>**<br>Бу эшләпәне алган төркем башкалардан иҗади булуы белән аерылып торырга тиеш. | Биктимер югалып калмады, табасына утырып шуа башлады. Миңа аның бу сыйфаты бик ошады. Балалар аңа кызыгып карап торганда, минем дә табага утырып таудан шуып карау теләге туды. Әнисе Биктимерне орыша башлагач, миндә аны кызгану хисләре уянды. Әтисе аны кыйнатмады, чөнки ул улын аңлый, аның улы әллә нигә бер рәхәтлек кичергән икән, моннан бернинди дә зыян юк. Әтисе дөрес эшләде дип уйлыйм. Биктимер балаларга хас булганча уен белән мавыкты. Мин дә кайвакытта әни-әти кушканны эшләргә онытам.<br><br>Биктимер – тыңлаучан малай. Әгәр таба алып кайтасы көнне дә шулай булган булса, аларның гаиләсе бәхетле булыр иде. Сирәк кенә булса да, аларның да бәхетле буласы, тәмле ашыйсы килә. Биктимер табаны вакытында алып кайткан булса, бу кызыклы хикәя дә булмас иде. Бәлкем, Биктимер үзенең шундый табага утырып шуу фикере белән |

| | | |
|---|---|---|
| | **Зәңгәр эшләпә.**<br>Бу эшләпә фәлсәфи фикер йөртү турында. Ул дәрескә йомгак ясарга ярдәм итә. Гомуми нәтиҗәләр чыгарыла. Бу эшләпә “хуҗалары” башкаларның фикерләрен игътибар белән тыңларга тиешләр, чөнки алар алдында иң җаваплы бурыч – барлык төркемнәрнең җавапларын берләштереп, нәтиҗә чыгару тора. Дәрескә төп йомгаклау ясала. | тормыштагы проблемалы очраклардан чыга белергә өйрәнгәндер. Без кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең, хисләрнең катлаулы булуын да күрмәс идек. Мин Биктимер урынында булсам, нәкъ шуның кебек эшләр идем.<br><br>Ата-ана сүзен тыңларга кирәк, гаиләдә берүзең генә бәхетле булып булмый, башкалар турында да уйларга кирәк. |
| III.Рефлексия.Укучыларны бәяләү. | **“Синквейн язу”** ысулын кулланып, укучылар белән дәреснең максатына ирешү-ирешмәүне анализлый. | Үзара фикер алышалар,эшләренә нәтиҗә ясыйлар. Үзбәя.<br><br>Биктимер<br>Акыллы,хыялый<br>Шуды,онытты,пешмәде<br>Ата-ана сүзен тыңларга<br>Башкалар турында да уйларга |


Соңгы ике төркем эшчәнлеге балаларның иҗади, фәлсәфи фикер йөртүен таләп итә, укытучы ярдәме дә кирәк булуы мөмкин.

Һәр укытучы балаларның яшь үзенчәлекләрен, сыйныфның әзерлек дәрәҗәсен истә тотып, уку материалын үзләштерү мөмкинлегеннән, классның профиленнән, текст төренә, эчтәлегенә туры килгәнен үзе сайлап ала. Федераль дәүләт белем стандартлары буенча уздырылган дәресләр иҗади эзләнүләргә юл ача, укучыны шәхес буларак үстерергә, укытуны тормышка якынайтырга булыша. Традицион укыту системасынан аермалы буларак, заман дәресләре укучының интеллектуаль, рухи, физик үсешен үстерү генә түгел, аның кызыксынуын формалаштыру, үз үсешен күрү, белемен арттыру теләге тудыру,үз көченә ышаныч тудыру да өстәлә. Укучыларны бергәләп эзләнү,

төркемләп эшләү күнекмәләренә өйрәтү, укытучы һәм укучы арасында эшлекле мөнәсәбәт булдыру дәресне отышлы итә. Укучы дәрестән чыкканда: “Мин нәрсә белә идем? Бүген нәрсә белдем? Алар арасында нинди бәйләнеш булды?- дип аңлап, үз үсешен ачыклап чыгарга сәләтле булырга тиеш.

## Этнокультурные технологии в образовании и воспитании младших школьников


*Андреева С.Р.*
*учитель марийского языка и литературы*
*МБОУ “Монашевская СОШ”*
*Менделеевского муниципального района*


**Данный файл находится во вложеных файлах**

**(рәсемгә 2 тапкыр басарга)**

## “Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә метапредмет компетенцияләр формалаштыру һәм укучыларның коммуникатив күнекмәләрен үстерү”


**Ахметзянова Лилия Мөхтәр кызы,**
*Әгерҗе районы Салагыш урта гомуми белем бирү мәктәбенең*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

Татарстан Республикасы мәгариф сәясәтенең төп бурычы –иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт телендә һәм чит телләрдә дә иркен аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияәү.

Дәүләт стандартлары таләпләреннән чыгып, ана телен укытуның төп бурычлары түбәндәгеләрне тәшкил итә:

- укучыларда ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
- укучыларның сөйләм эшчәнлеген һәм фикерләү сәләтен, төрле шартларда әдәби телдә дөрес аралаша белү күнекмәләрен үстерү;
- татар теле гыйлеме, аның төзелеше, кулланылыш өлкәсе, төп нормалары, сөйләм этикеты, стилистик чаралары белән танышу, сүз байлыгын арттыру;
- тел фактларын анализлый, тел күренешләрен күрә, таба белү сәләтен, тәкъдим ителгән мәгълүматтан мөһимен сайлау осталыгын үстерү;
- алынган белемне һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәтү.

Шул рәвешле бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – төп максатыбыз. Бу исә заман мәктәбе укучыларга билгеле бер дәрәҗәдә белем бирү белән генә чикләнмичә, аларны мәстәкыйль рәвештә даими белем тупларга, һәрьяклап үсешкә ирешергә, үз-үзе белән идарә итә белергә, җәмгыятьтәге мөһим процесслар турында хәбәрдар булырга өйрәтергә тиеш дигән сүз.

Икенче буын федераль дәүләт белем бирү стандартларында әйтелгәнчә, мәктәп эшчәнлегенең төп максаты – белем алу күнекмәләре формалаштыру, ягъни субъектның үз-үзен камилләштерүгә аңлы рәвештә, яңадан-яңа социаль тәҗрибәләр туплау аша барырга сәләтле итү.

Соңгы елларда мәгарифне модернизацияләүнең төп идеяләренең берсе укучыларның төрле тормыш хәлләрендә куллана белү компетенцияләрен формалаштыруда булды. Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – системалы-эшчәнлекле (системно-деятельностный подход) юнәлеш, ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре дип билгеләнелә.

Уку дәвамында укучы төрле фәннәрдән билгеле бер күләмдә мәгълүмат ала, ләкин һәрвакытта да алган белемнәрен тормышта куллана алмый, килеп туган ситуациядән чыгу юлларын таба алмый. Гомуми белем бирү мәктәпләрендә төп игътибар белем туплауга бирелә, ә бит шәхес тәрбияләү әле белем алу белән генә чикләнми. Укучының дөньяны тулаем күзаллавы, танып белүе таләп ителә. Метапредмет технологиясен куллану һәр балага төрле типтагы эшчәнлек өчен шартлар тудырып, аның шәхси үсешен күздә тота.

Бүгенге көндә, татар телен укыту мәсьәләсе киеренке хәл рәвешен алган заманда, татар теле укытучыларының укучылар, ата-аналар, милләтебез алдында җаваплылыклары тагы да артты. Башка милләт кешесе генә түгел, хәтта үз милләтеңнән булган кешенең дә “Нигә кирәк ул татар теле? Аның белән ерак китеп булмый” дигән кебек фикерләрен ишеткән хәлдә туган телгә карата хөрмәт һәм кызыксыну уяту укыту-тәрбия эшендә яңа алымнар куллануны таләп итә.

Туган телебезнең, әдәбиятыбызның асыл җәүһәрләрен укучы күңеленә җиткерүнең нинди үтемле юлларын табарга? Иҗади фикерләү сәләтләрен, грамоталылыкларын ничек үстерергә? Үз телеңнең, үз милләтеңнең кеше өчен иң кадерле, изге төшенчәләр булуын ничек төшендерергә?

Мин, туган тел һәм әдәбияты укытучысы буларак, методик тема итеп «Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның коммуникатив күнекмәләрен һәм метапредмет компетенцияләр формалаштыру» темасын алдым.

**Тикшерену объекты буларак** укучыларның метапредмет компетенцияләрен формалаштыручы һәм үстерүче белем бирү процессын билгеләдем.

**Тикшерену предметы итеп** татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә һәм дәрестән тыш эшчәнлек вакытында кулланган эш алымнарын саныйм.

**Проблема:** Электрон җайланмалар һәм Интернет челтәре үсеше чорында яшәүче укучының метапредмет компетенцияләрен формалаштыру юлларын табу.

**Максатым:** укучыларда метапредмет компетенцияләр формалаштыруда татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә предметара бәйләнешләр куллану нәтиҗәлелеген нигезләү, коммуникатив күнекмәләрен үстерү.

**Бурычлар:**

1. «Метапредмет компетенцияләр» төшенчәләрен ачыклау.
2. Предметара бәйләнешкә кагылышлы технологияләре куллану юлы белән укучыларның метапредмет компетенцияләрен формалаштыруда иң отышлы метод һәм алымнарны сайлау.
3. Эш тәҗрибәсен башка педагоглар белән уртаклашу.

**Методһәм алымнар:** Мәгълүмати-коммуниктив технологияләр, аңлатмалы-иллюстратив метод (Power Point программасында презентацияләр төзү), өлешчә эзләнү методы (төрле чыганаклардан һәм Интернет челтәреннән мәгълүмат эзләү, туплау, үзләштерү), укучыларның гыйльми күнекмәләрен коррекцияләү һәм тикшерү методы, чагыштырма анализ ясау методы, проект технологиясе, шәхескә хөрмәт белән карау технологиясе.

**Методик тема өстендә эшләү этаплары:**

**Оештыру этабы** (2015-2016) Методик темага кагылышлы фәнни хезмәтләрне өйрәнү. Сайланган теманың актуальлеген, төп гамәли максатларын, бурычларын билгеләү. Эш планын булдыру; көтелгән нәтиҗәләрне формалаштыру.

**Тормышка ашыру этабы** (2016-2019). Предметара бәйләнешләргә, яңа технологияләргә нигезләнеп, укучыларның аралашу максатын, урынын, вакытын, социаль хәлен истә тотып, аларны үз фикерләрен төгәл һәм эзлекле итеп белдерергә өйрәтү. Әлбәттә, бу – катлаулы эш. Шуңа күрә ул төрле типтагы дәресләр, дәрестән тыш чаралар үткәрү аша еллар дәвамында алып барыла.

**Гипотеза:** дәресләрне һәм дәрестән тыш чараларны предметара бәйләнешкә нигезләнеп оештырганда балалардаметапредмет компетенцияләр формалашыр һәм туган телгә карата кызыксыну уятыр.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

а) Предметара бәйләнешләрдән файдаланып, укыту-тәрбия эшен алып бару;

б) Әлеге технологияләрне актив куллану нәтиҗәсендә, укучыларны татар теле һәм әдәбияты белән кызыксындыру, аларны татар телендә гамәли рәвештә аралашырга өйрәтү;

г) Төрле фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда катнашу;
д) Эш тәҗрибәсен коллегалар белән уртаклашу.

Нәрсә соң ул метапредмет компетенцияләр? «Мета» - эчендә, өстендә - барлык предметлар өчен гомуми. Метапредмет – үзләштерелгән универсаль эшчәнлек ысулларын белем бирү процессы кысаларында да реаль тормыш хәлендә дә куллана белү. Менә шуларның аеруча мөһимнәре:

- регулятив – үз эшчәнлеге белән идарә итү; контроль һәм коррекцияләү, инициативалык һәм мөстәкыйльлек;
- коммуникатив – сөйләм эшчәнлеге, хезмәттәшлек итү күнекмәләре;
- танып-белү – мәгълүмат белән эш, уку моделен куллану, гомуми схемалар чишү, логик операцияләр үтәү, чагыштыру, анализ, классификацияләү.

Мин, туган тел һәм әдәбият укытучысы буларак, әдәбият дәресләрен укучы өчен мөһим тормыш дәресләре дип саныйм. Әдәби әсәрләрне, текстларны анализлаганда укучыларны уйландыра торган проблемалы сораулар бирәм, һәр укучының уйлануына һәм үз фикерен әйтүенә ирешергә тырышам.

Татар теле һәм әдәбиятын укытуда предметара бәйләнешләр куллану, һичшиксез, укучыда белем алуга кызыксыну хисе уята. Ул гына да түгел, телне гамәли рәвештә үзләштерүгә этәрә. Менә шуңа күрә дә мин татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә предметара бәйләнеш булдыруга зур игътибар бирәм. Федераль Дәүләт белем бирү стандарты нигезләрендә дә бу төп игътибарга алына: универсаль уку күнекмәләрен яисә метапредмет компетенцияләр формалаштыру дигән сүз.

Татар теле дәресләрендә алган белемнәрне ныгыту максатында әдәбият материалларын бик уңышлы кулланырга була:татар язучыларының әсәрләреннән файдалану, шигырьләрне сәнгатьле уку; грамматик категорияләрне кабатлаганда мәкаль-әйтемнәрне, табышмакларны, җырларны файдаланырга мөмкин.

Шулар арасыннан мин татар теле дәресләрендә укучыларның грамоталылыган үстерү юнәлешендәге эш тәҗрибәм белән уртаклаша алам. Билгеле булганча, татар теленең сүзлек составында гарәп, фарсы, рус теленнән һәм рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләр бик күп. Татар теленең үз сүзләре арасында да, алынмалар арасында да кыен язылышлы сүзләр күп. Укучыларның грамоталылыгын күтәрү максатыннан мин укучылар өчен “Сүзлек диктантлары” төзедем. Алар алфавит тәртибендә урнаштырылган. Шулар нигезендә һәр класста сүзлек диктантлары өстендә эш алымын куллануны укучыларның грамотолылыгын күтәрүдә һәм сүзлек запасын баетуда уңышлы алым дигән нәтиҗәгә килдем. Һәр сүзлек диктантыннан соң, берничә грамматик бирем бирелә. Укучы ул биремнәрне үтәп, тел гыйлеме буенча төрле белемнәрен искә төшерә.Иң соңгы бирем итеп шушы сүзлеккә кергән сүзләр кергән берничә халык мәкале бирелә. Шул мәкальләрдәге фикерне ничек аңлавын белдереп, укучы 8-10 җөмләлек текст яза. Шул рәвешле, кыен язылышлы сүзне ул берничә тапкыр үзе дә кулланып, дөрес язылышын кат-кат күрә, иҗади фикер йөртү

сәләтен дә үстерә, сөйләмен, хәтерен халык авыз иҗаты җәүһәре белән дә баета.(Кушымта)

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеге федераль дәүләт стандартлары таләпләрен тулысынча тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Дәрестән тыш эшләр белем бирү процессының бер өлеше булып тора. Шуңа күрә, укучыларның белемнәрен тирәнәйтү, эстетик зәвыгын үстерү, дөньяга карашларын формалаштыру, иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан, мәктәптә сыйныфтан тыш эшләрне оештыруга да нык игътибар итәргә кирәк.

Татар теле буенча аларның төрләре гаҗәеп күп: телдән журнал, бәйгеләр, викториналар, диспутлар, иҗат түгәрәкләре, галимнәр, язучылар белән очрашулар, экскурсияләр,конференцияләр һ.б. Бу эшләрнең барысы да төп программа материалын тирәнтенрәк өйрәнүгә, киңәйтүгә, укучыларыбызның телебезгә, мәдәниятебезгә карата кызыксынуларын арттыруга хезмәт итәргә тиеш.

Дәрестән тыш эшләрне оештыруда эзләнү характерындагы эшләр бирү бик отышлы дигән нәтиҗәгә килдем. Башта укучыларга аерым темаларга эзләнү характерындагы эшләр бүлеп бирәм. Шул эшләрнең нәтиҗәсе буларак газета яки альманах чыгарыла. Бу юнәлештәге эшне башкарганда, укучылар укытуның коммуникатив нәтиҗәләренә ирешәләр. Коммуникатив нәтиҗәләр үз эченә әңгәмәдәшеңне тыңлый белү, аралаша белү сәләтен, парларда яки күмәк эшли белү күнекмәләрен ала.

Эш нәтиҗәсе буларак, мәктәбебездә чыгарыла торган газетаны мисалга китерәсем килә. Бу газета битләрендә үзен иҗади яктан сынарга теләгән һәр укучы үз язмасын күрә ала. Мәктәптә, авылыбызда булган төрле вакыйгалар, истәлекле даталар, күренекле шәхесләр турындагы мәкалә, шигырь һәм башка иҗат җимешләре төрле рубрикалар астында урын алалар. Мәктәбебездә урнашкан "Туган як музее" укучыларга өчен зур иҗади чыганак булып тора. Музей материалларын эзләнү-тикшеренү эшләрендә уңышлы кулланабыз. Һәр экспонат – зур кыйммәткә ия. Авыл тарихына, табигатенә, ономастикасына, якташ язучыларга һәм башка сәнгать әһелләренә багышланган тикшеренү эшләребез белән укучылар төрле конкурс, конференцияләрдә катнашып, дипломнарга лаек булдылар.

Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүдә район күләмендә үткәрелә торган "Көмеш каләм" иҗат фестиваленең дә роле бик зур. Монда төрле мәктәп укучылары үзләренең иҗади көчләрен сыныйлар. Алар "Яшь шагыйрь», «Яшь журналист», «Яшь хикәяче" секцияләренә бүленеп, бирелгән тема буенча иҗади эш башкаралар. Салагыш мәктәбенең бу җәһәттән дә горурланырлыгы бар: һәр елны укучыларыбыз алдынгы урыннарны яулап алып баралар. "Әгерҗе хәбәрләре", "Яңарыш" газеталары битләрендә дә укучыларыбызның иҗат җимешләре даими басылып тора.

Татар телен укытканда яңа, заманча технологияләргә мөрәҗәгать итү сорала, чөнки, тәҗрибәдән күренгәнчә, аларны куллану укыту сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, укучыларның мөстәкыйль эшләү сәләтен үстерә, үз-үзенә ышанычын арттыра, аларда фәнне өйрәнүгә кызыксыну уята һәм укучыларны туган илен яратучы, аның киләчәген кайгыртучы шәхес буларак тәрбияли. Соңгы вакытта

социаль челтәрләрдә “Гыйлем” проекты тарафыннан тәкъдим ителә торган язмалар еш күренә башлады. “Гыйлем” проекты татар телендә белем алу һәм фәнне өйрәнү өчен мөмкинлек тудыру максатын күз алдында тотып эшли. 2014 елда оешкан бу проектның фәнни популяр сайты бар. Ул филология һәм мәдәни багланышлар институты белән хезмәттәшлек итә. “Гыйлем” берләшмәсе тарафыннан кварталга бер журнал чыгарыла, социаль челтәрләрдә төркемнәре эшли, матбугат чараларында кызыклы фәнни рубрикалары чыга. “Гыйлем” берләшмәсенең тел, әдәбият өлкәсенә караган төрле мәгълүмати пабликларын дәресләрдә уңышлы кулланып була. Алар аеруча башлангыч һәм урта звенода укучы балалар өчен кызыклы. Мин бу язмаларны башка коллегаларыма да кулланырга тәкъдим итәм. vk.com/gylem төркемендә көн саен яңа кызыклы материаллар чыга.

Шул рәвешле, мин татар теле һәм әдәбияты дәреслләрендә метапредмет компетенцияләр формалаштыру һәм укучыларның коммуникатив күнекмәләрен үстерүне тормышка ашырам.

Туган тел укытучысы булу –зур җаваплылык ул. Гаиләсендә татарча сөйләшергә җай тапмаган, татарча бер әдәби китап укырга яратмаган ата-аналарның балаларында туган телгә хөрмәт хисе уяту, милли сыйфатлар тәрбияләү, милли үзаң уяту – һәммәсе туган тел укытучыларын борчый торган сораулар. Милләтнең саклануы турыдан- туры телгә бәйле. Әби-бабаларыбыз үз телләрен, йола-бәйрәмнәрен күпме гасырлар аша югалтмыйча, саклап алып килеп безгә тапшырганнар, нинди генә авырлыкларны үтмәгәннәр. Тарихтан гыйбрәт итеп алырлык мисаллар бихисап...

Мин һәр дәресемә зур җаваплылык хисе белән, дулкынланып, шатланып керәм. Әнә алар – миңа кызыксыну тулы күз карашларын төбәгән татар кызлары-уллары. Милләтебезгә хас йөз сызыклары күзләремне иркәли. Күңелләренә мәрхәмәтлелек, игелеклелек орлыкларын, зиһеннәренә белм нигезләрен, телләренә туган телебезнең сүз байлыгын күбрәк салып калдырырга иде аларның.

## Кулланылган әдәбият

1. Камаева Р.Б.,Мөхәммәтҗанова А.Х. Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / төз.: – Казан: ТРМҮИ, 2015.
2. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре - Казан, 2001.
3. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле.- Казан, 2002
4. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – казан, 1987.
5. Хәйдәрова Р.З., Малафеева Р.Л. – Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы

Кушымта

**Сүзлек диктанты №1**

Автобиография, автовокзал, автограф, агымсу, адәм, алиһә, ахирәт, ахмак, ахры, ахыры, ахрысы, ашъяулык, аһәң (ле), ашханә, авыру, афәт, архив, адрес, акбүз , ай-һай, аттестат, архитектор, атмосфера, аккордеон,аягүрә, ач-ялангач, аръяк, аккургаш, аппликация.

**Биремнәр:**

1. Кушма сүзләрне күчереп алырга, тамырларын билгеләргә.

2. 2 иҗекле алынма сүзләрне күчереп язарга.

3. Сингармонизм законына (рәт гармониясенә) буйсынган сүзләрне күчереп язарга.

4. Сүзләрне сүз төркемнәре ягыннан билгеләргә.

5. Аръяк сүзенә фонетик анализ ясагыз.

6. Түбәндәге татар халык мәкальләренең мәгънәсен сез ничек аңлыйсыз? Шул турыда аңлатып, 50 сүздән дә ким булмаган текст язагыз. Текстыгызда кереш сүз һәм кереш җөмләләр кулланыгыз.

***1) Ашның тәме тоз белән, адәмнең яхшылыгы сүз белән.***

***2) Адәмнең хөрмәт күрүе дә, хурлык күрүе дә үз кулында.***

**Сүзлек диктанты №2**

Бәхет, бәхәс, бәла, бәһа, берөзлексез, берсүзсез, билләһи, биниһая, беркатлы, бәхилләшү, беркем, бернәрсә, беркайда, бернинди, берьяклы, берьюлы, бәгырь, бәгърем, баһадир, берсекөн(гә), борщ, борынгы, бөтендөнья, бассейн, баштанаяк, баштүбән, башкала, берара, бервакыт, бертигез, бухгалтер.

1. Бөтендөнья сүзенә фонетик анализ ясагыз.
2. Беркем, бернәрсә, беркайда, бернинди сүзләре – алмашлыкның кайсы төркемчәсенә карый? Бу сүзләрне юклык алмашлыклары буларак тагын ничек кулланырга була?
3. Баһадир, борынгы сүзенә синоним табып, җөмлә төзеп языгыз.
4. Беркатлы кеше дип нинди кешегә әйтәбез?

а) икейөзле

ә) тиз ышанучан

б) ялагай

5. Кайсы сүз “Сүз көрәштерү” фразеологизмының мәгънәсенә туры килә?

а) бәхилләшү

ә) бәхәсләшү

б) берләшү

6. Түбәндәге татар халык мәкальләренең мәгънәсен сез ничек аңлыйсыз? Шуларның берсен сайлап алып, 50 сүздән дә ким булмаган текст языгыз. Текстыгызда кереш сүз һәм кереш җөмләләр кулланыгыз.

***1) Бәхет башы – тәүфыйк.***
***2) Үткен тел – бәхет, озын тел – бәла.***
***3) Һәркем үз бәхетенә үзе сәбәп.***

**Сүзлек диктанты №3**

Вазифа, вәгазь, вәгъдә, вәхши, варис, водолаз, военкомат, вөҗдан, васыять, варенье, винегрет, велосипед, вәкаләт.

1. Бирелгән сүзләрне, в хәрефенең 2 аваз белдерүен исәпкә алып, 2 төркемгә бүлеп языгыз.
2. Сингармонизм законына буйсынган сүзләрне күчереп языгыз.
3. Хәреф саны белән аваз саны туры килмәгән сүзләрне транскрипциядә күрсәтегез.

4. Бу сүзләр арасында намус сүзенә синоним булган сүзне күчереп языгыз.
5. Васыять сүзенә фонетик анализ ясагыз (1.Сүзне иҗекләргә бүлеп язарга, басымын билгеләргә. 2. Сүздәге аваз һәм хәрефләрнең санын билгеләргә. 3. Сузык авазларга һәм тартык авазларга аерым-аерым характеристика бирергә)
6. Түбәндәге мәкальләрнең икесен дә кулланып, 50 сүздән ким булмаган текст языгыз. Мәкальләрдә әйтелгән фикер белән сез килешәсезме? Язмагызда үзегез белән булган вакыйга турында язсагыз була.

***1) Вәгъдә – намус көзгесе.***
***2) Вөҗданы пакь – йөзе ак.***

***(Шул рәвешле алфавит тәртибендә биремле диктантлар дәвам итә)***

## “Шүрәлеләр үч алмый...”

Тукайга иярep….

**Багаутдинова Р.Н.,**

*МБОУ Красноборская СОШ*

*Агрызского муниципального района РТ*

Кичә уздырыласы зал матур итеп бизәлгән. Түрдә - Г.Тукай портреты, бөтен җирдә чәчәкләр. Г.Тукай әсәрләреннән күргәзмә.

I өлеш.

Алып баручы:

- Менә тагын җир өстенә ямьле яз килде, үзе белән бик күп бәйрәмнәр алып килде. Шулар арасыннан иң якыны, зурысы - бөек Тукаебыз туган көн. 26 апрель - безгә халкыбызның даһи улын бүләк иткән көн буларак бөтен җиһанга билгеле. Язкөне килде ул җиргә, яз көне китеп барды. Якты дөньяда 27 ел гына яшәп, 7 ел гына иҗат итеп калса да, аның шигъри мирасы мәңгелеккә җитәрлек. Ул үзе дә мәңгелеккә сәфәр чыккан шагыйрь.

Г.Тукай – татар әдәбиятының күренекле вәкиле, ул иҗтимагый фикерләве, фәлсәфи карашларының тирәнлеге белән аерылып торган шагыйрь. Ул әкиятче дә, тәнкыйтьче дә, публицист та, туган халкының куанычына сөенгән, фаҗигасен тетрәнеп җырлаган әдип тә. Тукайга багышланган шигырьләр язылды, зур калын романнар басылды, аның шигырьләре кат-кат өйрәнелде, аңа ияреп, яңа әсәрләр язылды. Тукай геройлары күпме балага олы, туры юлны күрсәтте.

Һәр ел саен апрель аенда бөек шагыйребезнең туган көнен билгеләп үтәбез. Һәр ел саен Казанда сөекле шагыйребезнең һәйкәле янында шигърият бәйрәме уздырыла: милләтебезнең йөзек кашы булган Тукаебызга багышланган шигырьләр укыла, аның исеменә лаек булган сәнгатҗ әһелләренең исемнәре атала.

1 укучы: Тормышыңда бәйрәмнәр дә аз булган,
Тартыш белән үткән көннәрең.
Шуңа ахрысы искә алынмыйча
Үткән синең туган көннәрең.

Бәйрәмнәрең алда икән әле –
Шагыйрь карый алга текәлеп,
Халкың килгән сиңа мәхәббәтен
Ал чәчәкләр белән күтәреп.

Син күрмәгән яңа буын килде,
Котлап синең туган көнеңне,-
Киләчәктә барган улларыңнан

Ишеттереп туган телеңне.

Алып баручы: Г.Тукай – татар әдәбиятының күренекле вәкиле, ул иҗтимагый фикерләве, фәлсәфи карашларының тирәнлеге белән аерылып торган шагыйрь. Ул бер үк вакытта тәнкыйтьче дә, ялкынлы публицист та. Туган халкының авыр язмышын уртаклашкан, аның куанычына сөенгән, фаҗигасен тетрәнеп җырлаган олы йөрәкле әдип тә.

2 укучы: Г.Тукай кечкенәдән үк әкиятләр, бәетләр, җырлар тыңлап үскән, халык уеннарын яраткан. Аның әкият геройлары булган Шүрәлеләр, Су анасы бик күбебезнең төшләренә кереп йөдәткән. Әллә алар чыннан да булганмы? Халык әйтсә, хак әйтә, диләр бит. Әйдәгез, халыкны тыңлыйк.

Ак сакаллы бабай: Безгә картлар сөйли торган иде, имеш, Шүрәле кара урманда яши. Тышкы кыяфәте беләк кешегә охшаган. Куллары озын, бармаклары ике-өч карыш. Түше йөнтәс, кайчакта озын колаклы да, мөгезле дә була. Алга бөкрәебрәк йөри, кешечә сөйләшә. Менә шул кеше телен белүе күпләрне харап итә дә инде. Кешеләргә яз һәм җәй айларында иртән кояш чыкканда яисә кич кояш баегач та күренә. Аны тануы җиңел: ул кешедән сорашырга ярата да, үзе сорауларга җавап бирергә яратмый, ди. Шүрәлегә тешләрне күрсәтергә ярамый: тешегезне күреп, көлә дип уйлый һәм үтергәнче кытыклый.

Шүрәледән котылу юлы да бар: инеш, чишмә суларын гына кичеп чыгарга кирәк. Шүрәле судан курка икән , ди.

3 укучы: Бабай, ул Шүрәле турында районыбызның мәгърифәтче язучысы, мөгаллиме Даут Гобәйди шигъри легенда да язып калдырган. “Шүрәле каргаган авыл” дип атала. Без аны укыдык. Менә болай башлана:

“Булган, ди, Ишморатның күк биясе,
Ярата икән аны абзар һәм иясе.
Матур булган, яхшы һәм җанлыклы,
Шәплектә өяздә бер һәм данлыклы.”

Бабай: Улым, мин аны укыдым. Менә син Каюм Насыйри бабайны тыңлап кара.

Каюм Насыйри: Русларның “леший” шикелле бернәрсә. Урманда торалар, ялгыз гына яшәмиләр. Урманда татар очраса, аны кети-кети уйнарга чакыралар. Әгәр

ул күнсә, аны үтергәнче кытыклыйлар. Ләкин, татар алдалый: бер уен тәкъдим итә. Шүрәле надан була. Бүрәнә ярыгына бармагын кыстыра. Исемен сорагач: “Мин Былтыр,” – дип исемен әйтеп, алдап калдыра. Шүрәле: “ Былтыр кысты, аты Былтыр”, - дип кычкыра-кычкыра йөри. Иптәшләре килеп: “Былтыргы елны каян эзлисең, табып буламени аны,” – дип әйтәләр икән.

1 укучы: Г.Тукайның Шүрәлесен кем генә белми икән? Шагыйрь бу әкиятен халык мифларына нигезләнеп язган да инде. Аның Шүрәлесе – әдәби әсәр герое. Бик уңган герой ул. Дөньяны әйләнеп, аркылыга-буйга узып йөрде. Фәрит абый Яруллин көй язган “Шүрәле” балеты дөньяның бик күп урыннарында булып, татар дөньясы белән таныштырып кайтты.

2 укучы: Әкиятләрдәге Шүрәлеләр
Кырлаеңда яши бүген дә.
Шигырь чишмәләрең җырга күчеп,
Яши сандугачлар телендә.

Ничә буын сине иң кадерле
Бер кешесе итеп сагына.
син остаз да, мөгаллим дә булып
Яшисең күк туган ягыңда.

3 укучы: Заман башка, әмма халкы аның
Сөйләшә гел синең телеңдә.
Җырлап яши синең җырларыңны
Юк белмәгән сине илендә.

Алып баручы: Тукайның Шүрәлесе бервакытта да картаймас. Яңадан-яңа әсәрләр туар, чыгышларның төп геройлары да Тукайдан алыныр, Тукайга ияреп язылыр.

Ә хәзер сезнең игътибарыгызга “Шүрәлеләр үч алмый” дигән сценарий тәкъдим итәбез.

II өлеш

Авыл өе. Баскыч төбендә әби оекбаш бәйли, аның оныгы Гөлзифа китап укып утыра. Көн кичкә авышкан. Бик тын. Шушы тынлыкны бүлеп, радиодан “Кырлай” поэмасын укыган диктор тавышы ишетелә.

Гөлзифа: Әбекәй, дим, әбекәй, Шүрәлеләр булганмы? Хәзер дә бармы икән?

Әбекәй: Булгандыр, кызым, китапта булмаганны язмаслар. Китап та, халык та дөресен генә сөйли.

Гөлзифа: Әкият кенә ул, әбекәй. Менә Тукай бабай да әкият дип язган. Әкият, димәк чын түгел дигән сүз.

Әбекәй: Алай димә, кызым. Әкиятләр барысы да чынга аша. Элекке әкиятләрдәге оча торган паласларга хәзер сез утырып очасыз.

Гөлзифа: Паласка?

Әбекәй: Самолет дибез инде. Тиз йөрешле итекләр машинага әйләнде.

Гөлзифа: Ә менә Шүрәлеләр юктыр инде. Булса, берәр вакыт килеп чыгарлар иде.

Әбекәй: Килгән ул авылга, кызым. Тик кешеләр аны рәнҗеткәннәр, бик каты рәнҗеткәннәр.

(Койма артында Зурмөгез белән Шайтанның башлары күренеп китә)

Гөлзифа: Әбекәй, син боларны кайдан беләсең? Сөйлә әле.

Әбекәй: Мин дөньяда 95 ел яшим. Миңа да әбекәй сөйләп калдырды. Тик бүлдермә. Минем карт фикерләремне чуалтырсың.

Гөлзифа: Мыш та итмичә утырам, тик сөйлә генә.

Әбекәй: Тыңла алайса. Кайчандыр безнең авыл бик зур булган. Халкы да күп булган: иген иккән, мал асраган. Атларны яраткан. Төнгелеккә саклауга җибәргәннәр. Көннәрдән беркөнне берсенең аты иртә белән бик йончыган булган. Икенче көнне тагын шул хәл кабатланган. Аптыраган инде бу.

Гөлзифа: Әбекәй, Шүрәле турында сөйлә инде.

Әбекәй: Бүлдермә дидем бит инде. Фикерләрем чуала башлады менә.

Гөлзифа: Ат саклаучылар дигән идең.

Әбекәй: И-и, ул ат саклаучылар учакягып, көлгә бәрәңге тәгәрәтәләр. Әкиятләр тыңлыйлар…

Гөлзифа: Әбекәй, аты йончыган дип калган идең.

Әбекәй: Ә-ә, шуннан берсе әйтә: "Син күрше, атыңның сыртына сумала сөрт, ди. Әйткән сүз – аткан ук. Нәкъ шулай эшлиләр дә. Иртәгесен барып карасалар…Исләре китә. Ат өстенә тәне йон белән капланган, озын бармаклы, маңгаенда бер мөгезле әкәмәт ябышкан була. Аны тамаша кылырга бөтен авыл җыела. Кыйнаганнар, ди. Шүрәле бик ялынган: "Үтермәгез, зинһар! Урманда кечкенә балам калган иде."- ди икән. Кешеләр аны тыңламаганнар. Утта яндырганнар. Рәнҗегән Шүрәле. Шуңа безнең авыл бер дә артмый инде.

(Аларның сүзләрен тыңлап торган Шайтан белән Зурмөгез сүз көрәштерәләр)

Шайтан: Менә, аңладыңмы инде. Ул синең бабаң була инде. Ә бер туганыңынң бармагын бүрәнә ярыгына "Шалт!". Менә, белдеңме инде, урман сарыгы. Ә син кешеләр әйбәт, авылга барыйк, дисең.

Зурмөгез: Нишләп мин урман сарыгы булыйм, ди. Минем бит тәпиләрем икәү генә.

Шайтан: Аның каравы мөгезең бар. Ха-ха-ха (эчен тотып көлә)

Зурмөгез: Ә синең койргың бар. Син – сарык.

Шайтан: Бирермен мин сиңа сарыкны. Мин аңа файдага, ә ул… (үпкәләп китә)

Зурмөгез: Я, ярый, син матур. Мин дә матур.

Шайтан: Мату-ур… Бик инде. Әле җитмәсә, куркак. (Хи-хи) Шул кешеләрдән үч алырга кирәк, ә ул, ул курка.

Зурмөгез: Шүрәлеләр үч алмый ул.

(югалалар)

Гөлзифа: Әбекәй, кемнәр ул? Быдыр-быдыр сөйләшәләр. Тавышлары ямьсез. Әйдә, өйгә керик. (кереп китәләр)

(Зурмөгез белән Шайтан алгы планга чыгалар)

Зурмөгез: Ничек инде үч аласың? Әбисе ничек ягымлы, ә кызы…кызы чибәр әллә-лә.

Шайтан: Нәрсә җебеп төштең, бәрәңге боламыгы. Чибәр дигән буласың. Бик, инде. Койрыгы да юк. Бите шоп-шома. Әйдә, киттек кире урманга, күзең төште ахрысы. Я, гашыйк булырсың.

Урман аланы. Төп өстендә, башын тотып, Дию утыра.

Дию: У-у-у. Уйлар басты башкаемны. Көн туса – кайгы, кич җитсә – хәсрәт.

Себеркегә атланып, сәләмә киемле убыр килеп җитә.

Убырлы: Мин килдем, мин!

Дию: Син? Мин сине чакырмадым. Синнән нинди файда? Зыян булмаса инде.

Убырлы: Килгәч, килдем инде менә. Чакырмагач та киләләр аны.

Дию: Килгәч, әйдә утыр яныма. (Убырлы утыра, Дию аның җилкәсенә кулын сала.)

Убырлы: Кит эле, кочаклыйсың бит. Кеше көләр.

Дию: Их, дөньялар…Бар иде бит элекке чаклар. (Уйга калып утыра)

Кәрлә керә.

Кәрлә: Шылдыр-мылдыр, кырлыкар ( боргалана-боргалана бии, яшьләр биюен башкара).

Убырлы: Монысы да юләрләнгән.

Кәрлә: Ычкынган, диген.

Убырлы: Ычкынган?! Кая?

Кәрлә: Хәзер шулай сөйләшәләр…Модно!

Убырлы: (шаккатып карап тора) Барысы да исәрләнгән.

(Шайтан белән Зурмөгез килеп керәләр)

Шайтан: Кем исәрләнгән? Син үзең нишләгән?

Убырлы: Дию Кәрләне мәктәпкә бирәм, ди.

Зурмөгез: Без авылда булдык. Авыл матур! Кызлары да матур. Мин дә барам.

Шайтан: Күзең төштеме әллә? Син дә барасың? Мәктәпкәме? Син карт бит инде, тешләрең дә коелган. Бар, бар! Бармагыңны кыстырырлар, менә күрерсең!

Зурмөгез: Синең койрыгыңны өзәргә җитә әле ул. Әйдә, Кәрлә, киттек.

Шайтан: Барыгыз, бар. Көтәләр сезне анда.

Зурмөгез: Кешеләр бик әйбәт. Алар безгә тимиләр. (Китәләр)

Убырлы: Барыгыз, бар. Ничек кайтканыгызны сизмәссез әле.

Шайтан: Шүрәлеләр дә кешеләрчә яши башласалар, безнең явызлыгыбыз калмый бит, беләсезме шуны?

Убырлы: Берәр явызлык эшләргә иде.

Шайтан: Әллә ничек күңелсез булып китте әле. Әллә авылга миңа да барырга инде.

Убырлы: Барыгыз, берегез дә калмагыз (тузынып, чыгып китә)

Авыл урамы. Кулларына чәчәкләр, портфельләр тоткан Гөлзифа белән Былтыр мәктәпкә баралар. Аларга Кәрлә белән Зурмөгез очрый.

Дию: Әй, сез, кая барасыз?

Былтыр: Исәнмесез, бабай!

Гөлзифа: Тәрбиясезләр, исәнләшә дә белмиләр.

Дию: Миңа баш мәктәп кирәк иде.

Былтыр: Ә, директор абыйммы?

Дию: Шулдыр. Менә минем улым да мәктәпкә барам, ди.

(Кәрлә төрлечә кылана. Гөлзифаның чәчәген тарта. Гөлзифа телен чыгарып күрсәтә.)

Кәрлә: Кара, үртәшә…

Дию: Улым, акыллы гына бул.

Гөлзифа: Бабай, улыгызның исеме ничек?

Кәрлә: Кәрлә, ә юк, Кәримулла.

Былтыр: Кәрим инде алай булгач (Гөлзифага). Бик сәер кешеләр болар. Үзләре дә ,киемнәре дә әллә ничек. Әллә террористлар микән…

Гөлзифа: Белмәгән кешеләр хакында алай димә. (Убырлы белән Шайтан киләләр.) Әйдә, Кәрим, соңга калабыз.

Убырлы: Нинди Кәрим? Кәрлә ич ул. Кәрлә! Сез аларны белмисез әле. Алар үч алырга килделәр.

Гөлзифа: Үч? Нинди үч? Ни өчен? Кемнәр?

Убырлы: Синең бабаң, Былтыр, Шүрәленең бармагын кыстырган, Диюнең башын “кых” иткән (күрсәтә). Үч алачаклар, үч.

Зурмөгез: Син ни сөйлисең? Убырлы, юкны лыгырдама. Күп телеңә салынсаң…(Убырлы янына килә) Убырлы кача. Шайтан, Сиңа да кирәкме?

Шайтан: Юк, минем дә мәктәпкә барасым килә. Мине гел начар яктан гына искә алалар (елый).

Гөлзифа: Я, ярый, елама. Әйдәгез, киттек, соңга калабыз бит. (Кыңгырау тавышы килә)

Зурмөгез: Шүрәлеләр үч алмый ул.

Барысы бергә “Шүрәле” җырын җырлыйлар.

*З.Хөснияр сүзләре* *З. Гыйбадуллин муз.*

Ачуланган, турсайган,
Шүрәлене күр әле!
Онытырга вакыт инде
Былтыргы үпкәләрне.
Куш. Әй, Шүрәле, Шүрәле,
Безнең янга кил әле.
Син яхшы бит, син әйбәт бит
Теге хәлне сөйлә әле.
Бигрәк озын кулларың,
Күзләрең йөреп тора.
Килеш-килбәтеңне күргәч,
Көләсе килеп тора.

Алып баручы: Халык моңы – синең моңың булды,
Халык күңеле – синең күңелең.
Ил гомере – халык гомере кебек
Озын булсын, шагыйрь, гомерең.

Әдәбият:


1. К.Насыйри. Казан татарларының ышанулары, 52 бит.
2. Г.Гыйльманов. Татар мифлары, Беренче китап, 148 бит.
3. Т.Миңнуллин. Кәрлә- мәктәп баласы.


## Татарларны татарча укытыргамы?


**Борһанова Гөлназ Шәйхенур кызы,**
*Менделеевск шәһәре*
*4нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең*

Туган тел! Һәркем өчен дә газиз сүз бу. Чөнки иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштырмый торган “эти” , “әни”, “әби”, “бабай” сүзләрен туган телдә әйтәбез. Туган – үскән илнең якынлыгын, Ватанның газизлеген тоярга да безгә туган тел ярдәм итә.

Һәр милләт өчен иң моңлы көй – милли көй, иң матур тел – милли тел. Әнә шуны тоеп, ләззәтләнеп яшәгәндә кеше эшләргә һәм укырга сәләтлерәк, бәхетлерәк була. Шундый бәхетне югалтмас өчен генә дә без ана телен камил белергә һәм балаларыбызга өйрәтергә тиешбез.

Туган тел үзенең яңгырашы белән колакны назласа, ягымлылыгы белән исә күңелне юата, кешедә изгелек хисләре уята. Ягымлы ана теле – бигрәк тә балаларга аң – белем һәм тәрбия бирү өчен иң шифалы чишмә. Милләт – халыкның яшәү формасы . Милләтнең төп күрке – тел һәм моң.

Тел милләт белән бергә туа, үсә һәм аның иң ышанычлы һәм кадерле сердәше, юлдашы һәм юанычы булып яши. Күп гасырлар буе телебез үсеп, шомарып килгән һәм шул процесста сүзләр кыскара, җыйнаклана төшкән. Нәтиҗәдә сүзләрнең күпчелеге бер генә иҗекле булып калган (Ә андый сүзләр телебездә бик күп.).

“Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул”, - дигән телебезне үстерүгә гаять зур өлеш керткән Каюм Насыйри.

Сүзләрнең кыскалыгына, җыйнаклыгына, камиллегенә карагандa татар теле нык шомарган бик борынгы тел.

Телдәге сүзләр һәм терминнар ни хәтле кыскарак һәм җыйнаграк булса, төгәл фәннәрне укыту дә шул хәтле җиңел бара. Бу факт киләчәктә тел галимнәрен генә түгел, бәлки башка фән укытучыларын да кызыксындырыр дип уйларга кирәк.

Татар теленең мондый үзенчәлеген белмәгән һәм ике телдә дә төгәл фәннәрне укытып карамаган кайбер галимнәр телебезне төгәл фәннәрне укытырга яраксыз дип исәплиләр. Шуңа күрә татар мәктәпләрендә төгәл фәннәрне русча гына укыту ягында торалар. Бу уңай белән мин шуны әйтер идем : мондый позициянең дөресме – түгелме икәнлеген ачыклау өчен, беренчедән, кимендә ике телне дә тигез дәрәҗәдә бик яхшы белергә кирәк ; икенчедән, бу ике телдә дә физика һәм математика фәннәрен мәктәптә һәм югары уку йортларында укытып карарга кирәк.

15-20 ел элек югары уку йортларында төгәл фәннәрне татар телендә укытып булмый дигән ялгыш фикер халык мәгарифе җитәкчеләренә дә барып җитте. Ә алар исә шул карашны фән кушуыдыр дип кабул иттеләр һәм нәтиҗәдә югары

уку йортларында татар төркемнәренең бетерелүенә китерде, аннары мәктәпләр, балалар бакчалары шул хәлгә дучар булды. Тора-бара бу ялгыш караш ата-аналарга да көчләп тагылды. Шулай итеп, байтак ата-ана һәм әби-бабайлар, бала-оныкларын ике телне өйрәтеп җәфаланмыйк дип, ватып-җимереп булса да, алар белән русча гына сөйләшүгә күчтеләр.

Ә хәзерге көндә югары уку йортларында татар телендә укыту ни хәлдә? Татарлар татарча укыймы?

11нче сыйныфны тәмамлаучы кызым белән Казан шәһәренә ачык ишекләр көненә баргач, берничә югары уку йортында булырга туры килде.

Бүген Татарстанда югары уку йортларында татарча укыту КФУ, Россия Ислам институтында алып барыла.

КДАТУ (Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты) каршындагы Төзелеш институты ел саен бер татар төркеме кабул итә икән. Татар төркемнәрендә белем алучы студентлар 23 фәнне татар телендә үзләштерә. Лекция, имтиханнар – барысы да татарча. III курсның икенче яртысыннан, төгәлрәге, 6 нчы семестрдан, белем бирү тулысынча русчага күчә. Чыгарылыш имтиханнары һәм диплом эшләре рус телендә тапшырыла. Татар төркемнәрендә 13-15 кеше белем ала.

Университетта татарча укытуны оештыручыларның берсе – педагогика фәннәре докторы, физика-математика фәннәре кандидаты, профессор Наил Туктамышев. Ул уку йортында әле дә математика укыта. “Ике телне дә яхшы белгән белгечләр әзерләү мөһим. Татар халкын цивилизацияле халыклар арасына чыгарырга тиешбез. Шундый максат бар. Ул бүген фантастик булып яңгырыйдыр, бәлки. Ләкин зур максат юк икән, кечкенә эшне дә башкарып булмый. Бүгенге көндә русча, татарча, инглизчә дә белем алу мөмкинлеге булу – ул бөтен Татарстан, ә бәлки бөтен Россия өчен үрнәк дип саныйм. Бу – безнең киләчәк өчен кирәк “, - ди галим журналист Зилә Сафинага биргән интервьюсында

Наил Туктамышев чит илләрдә конференцияләрдә еш катнаша. Бразилиянең Сан-Паулу шәһәрендә узган халыкара конференция аның хәтерендә уелып калган. Анда 40-50 илдән вәкилләр җыелган. Галимнең чагышыннан соң, Татарстан белән кызыксынучылар күп булган икән. “Бездә математиканың югары уку йортында татарча укытылуына шаккаттылар. Папуа-Яңа Гвинеядән галимнәр бар иде. Алар математиканы үз телләрендә өйрәнә башлаган. Папуа телендә терминнар булдыралар. Бүген дүртенче сыйныфка кадәр үз телләрендә математиканы өйрәнәләр”, - дип яза математик.

Наил Туктамышев үз телләрендә фәнни дәреслекләр булмаган халыкның шушы юнәлештә эшләвен искәртеп, татарларның булган югары белемнән баш тартуына гаҗәпләнүен белдерә.

Әй кадерле ата-аналар һәм дәү эти-дәү әниләр! Баланың башында ике тел өчен генә түгел, ә өч-дүрт һәм аннан да күбрәк телләр өчен дә урын җитәрлек.

Балаларыгызны шулай ук милли телдән мәхрүм итмәгез. Күп телләр белү балага авырлык китерми, бары тик аның белемгә омтылышын гына арттыра. Бүгенге фән-техника үсеше заманында һәркемгә ике генә түгел, күбрәк тел белү дә бик кирәк.

Дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә: милләт милләт буларак сакланып калсын өчен, мәгариф системасы түгәрәк цикл булып эшләргә тиеш. Балалар бакчасы – мәктәп – югары уку йорты. Бакча, мәктәптән соң, югары уку йортында да татарча белем алу мөмкинлеге тудырылган икән, бу – телнең тулы канлы кулланылышын күрсәтә торган бер дәлил.

Кешенең хисләре, кичерешләре эти-әни, әби-бабай,туган телгә мәхәббәттән, туган-үскән җирләрне сагынудан, үз урманнарың белән кырларыңны яратудан башлана. Бу исә алар турында кайгыртып яшәргә, һәр адымда шулар өчен җаваплы булырга дигән сүз.

**Кулланылган әдәбият**


1. Атна вакыйгалары. №4, 2017
2. Н. Дәүли. Мин җирдә калам. - Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980
3. Ф.С. Сафиуллина, М.З.Зәкиев. Хәзерге татар әдәби теле.- Казан : Мәгариф нәшрияты, 2002
4. Ф.С. Сафиуллина, Г.Б.Ибраһимов. Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел. – Казан : Мәгариф нәшрияты, 1998
5. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан : Татарстан китап нәшрияты, 1987


## «Использование метода «кроссенс» на уроках родного языка и родной литературы как средство развития логического и творческого мышления учащихся» (Мастер-класс)


**Васильева Татьяна Ивановна,**
*учитель родного языка и литературы,*
*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение*

*«Средняя общеобразовательная школа №3*
*им. Героя Российской Федерации А.Н.Епанешникова»*
*Елабужского муниципального района*
*Республики Татарстан*

**Цель:** Продемонстрировать использование метода «кроссенс» на уроках родного языка и литературы как средство развития логического и творческого мышления учащихся.

Сегодня мы встречаем всё больше технологий, которые позволяют сделать учебный процесс интересным для учащихся.

Использование нетрадиционных методов и приемов обучения дают положительный результат. Их использование способствует повышению мотивации к изучению предмета, развивает наглядно-образное мышление, вербальные коммуникативные навыки обучающихся, формирует навыки работы с информацией.

Метод развивающей технологии «кроссенс» способствует на основе деятельностного подхода формированию креативности, сотрудничества, коммуникации и критического мышления обучающихся.

Слово "кроссенс" означает "пересечение смыслов" и этот метод разработан нашими соотечественниками Сергеем Фединым - писателем, педагогом, математиком и Владимиром Бусленко – доктором технических наук, художником и философом. Слово «кроссенс» придумано авторами по аналогии со словом «кроссворд», которое в переводе с английского означает «пересечение слов».Первыми о кроссенсе узнали читатели журнала «Наука и жизнь» в 2002 году.

Основной смысл создания кроссенса – это загадка, головоломка, ребус, задание, которое предназначено для определённой аудитории. Именно в этом качестве оно интересно нам, педагогам. В первую очередь, как нетрадиционная форма проверки знаний по предмету. Когда образы на изображениях просты и логичны, для разгадки кроссенса нужно лишь знание фактов. В этом случае правильный ответ один и тематика конкретна.

Кроссенс представляет собой ассоциативную цепочку, замкнутую в поле из 9 квадратиков, в которых помещены изображения. Каждое изображение связано с предыдущим и последующим по смыслу,а центральная объединяет по смыслу сразу несколько. Связи могут быть как поверхностными, так и глубинными.

Задача учащихся – объяснить кроссенс, составить рассказ – ассоциативную цепочку, посредством взаимосвязи изображений. Читать кроссенс нужно сверху вниз и слева направо, далее двигаться только вперед и заканчивать на центральном 9 квадрате, таким образом, получается цепочка, завернутая «улиткой». Начать можно как с первой, так и с любой узнаваемой картинки. Центральным является квадрат с номером 9. По желанию автора, он может быть связан по смыслу со всеми изображениями в кроссенсе. Обычно же нужно установить связи по периметру между квадратами 1–2, 2–3, 3–4, 4–5, 5–6, 6–7, 7–8, 8–9, а также по центральному кресту между квадратами 2–9, 6–9.

| | | |
|---|---|---|
| *1* | *2* | *3* |
| *8* | *9* | *4* |
| *7* | *6* | *5* |

Проблема, с которой часто сталкиваются авторы кроссенсов, - это трактовка изображений, которые могут быть не очень понятны. В таком случае можно дать текстовую подсказку – кто или что изображено на каждой картинке, а задание - найти связи между соседними изображениями или дать название кроссенсу.



Алгоритм создания кроссенса:

1. Определить тематику, общую идею.
2. Выделить 8-9 элементов, имеющих отношение к теме.
3. Сконцентрировать смысл в одном элементе (крест, основа).
4. Выделить отличительные черты каждого элемента.
5. Подобрать изображения, иллюстрирующие элементы.
6. Замена прямых образов символическими.
7. Построить ассоциативную связь между образами.
8. Выйти на новый уровень.

Подобранные в определённой логике образы могут быть использованы на любом этапе урока:

- проверка домашнего задания (с помощью кроссенса рассказать о материале прошлого урока, функция опорной образной схемы);
- формулировка темы урока, постановка цели урока (найдите связь между изображениями и определите тему урока);
- раскрытие информационного блока темы, поиск проблемы (виды, причины, черты, последствия чего – либо в образах и символах);
- обобщение материала, закрепление (кроссенс может состоять из изображений, которые появлялись в ходе урока на разных этапах, учащиеся по ним обобщают материал, делают вывод);
- организация групповой работы (составление кроссенса на заданную тему из предложенных изображений, сравнение кроссенсов групп);
- творческое домашнее задание (составление кроссенса в печатном или электронном виде на заданную тему);
- построение структуры урока (девять элементов кроссенса могут содержать в себе последовательное отражение структуры урока с именем, целью или проблемой в середине).

Пример кроссенса по теме «Басня» (7 класс) на этапе формулировки темы урока, постановки цели урока (найдите связь между изображениями и определите тему урока).

| | | |
|---|---|---|
|  |  |  |
|  | ? |  |
|  |  |  |

«Читаем кроссенс»: 1.Нечто древнее, возникшее в Древней Греции; 2. Древнегреческий баснописец Эзоп; 3. Героями данного жанра являются животные, реже предметы; 4.Например, басня «Ворон и лисица»; 5.Басни писал и Иван Андреевич Крылов; 6,7. Басни И.Крылова, сюжет которых позаимствован у Эзопа; 8. Габулла Тукай писал басни на татарском языке; 9. О каком жанре идет речь? Особенности данного жанра?

Пример кроссенса по теме «Театр кукол» (7 класс), который может быть использован как обобщение материала, закрепление (кроссенс состоит из изображений, которые появлялись на разных этапах урока, ученики обобщают материал и делают выводы).

| | | |
|---|---|---|
|  |  |  |
|  |  |  |
|  |  |  |

Связь между изображениями: 1. Вертеп; 2.Петрушка; 3.Марионетки; 4. Верховые куклы; 5. Низовые куклы; 6. Ростовые куклы; 7. Кукловоды; 8. Театр кукол «Экият»; 9. Занавес.

Кроссенс основывается на ассоциациях понятий, событий, явлений и процессов с образами. Этот прием позволяет организовать работу с текстом, рисунками, символами, картами, диаграммами.

Такой прием позволяет создать разноуровневые обучающие задачи и дает возможность продвигаться от одного уровня к другому. Например, на первой ступени учащиеся определяют заданную тему, на второй – решают кроссенс, находя ассоциации между соседними изображениями, на третьей ступени – находят не только соседние ассоциации, но и перекрёстные, на чревёртой – определяют объединяющую все образы ассоциацию, на пятой – создают свой кроссенс.

Работа с кроссенсом отражает глубину понимания обучающимися изучаемой темы. Его применение на уроках способствует:

- развитию логического, образного, ассоциативного мышления, воображения;
- проявлению креативности;
- развитию коммуникативных и регулятивных умений;
- формированию навыков работы с информацией;
- повышению интереса к предмету.

Таким образом, кроссенс – методический приём, который позволяет на практике

воплотить в деятельности учителя смену приоритетов, продиктованных целями современного образования – не научить, а создать условия для самостоятельного творческого поиска ученика.

## **«Приёмы активизации деятельности учащихся на уроках литературы»** (Мастер класс)

**Галкина Е.В.,**
*МБОУ «Ижевская СОШ» ММР РТ*
*учитель русского языка и литературы*
*высшей квалификационной категории категории*

Каждый учитель хочет, чтобы его ученики хорошо учились, с интересом и желанием занимались в школе, активно принимали участие в изучении учебного материала. Но подчас нам приходится с сожалением констатировать: «не хочет учиться», «мог бы прекрасно заниматься, а желания нет», «ребёнок просто отсиживает урок».

Как же помочь детям? Как облегчить восприятие теоретического материала, научить учащихся самостоятельно рассуждать, делать выводы?

Свою роль учителя вижу в том, чтобы помочь учащимся активизировать свою деятельность, формировать умение использовать теоретические сведения в практике.

### **Урок литературы в 11 классе по рассказу Л.Петрушевской «Страна»**

Основная задача урока литературы– научить жизни. Можно услышать резонное замечание, что научить этому невозможно. Научить, может, и нет, но в наших силах создать условия, продемонстрировать примеры и заставить задуматься: как правильно поступить в той или иной ситуации. А ситуация выбора и поиски правильного решения – это и есть проекция нашей жизни. Поэтому для мастер-класса я выбрала урок внеклассного чтения в 11 классе по небольшому, но, на мой взгляд, необычайно содержательному и полемичному произведению Л.С.Петрушевской «Страна». Этот текст не входит в обязательный минимум содержания литературного образования. Но я считаю, что его целесообразно демонстрировать 11-классникам для подготовки к ЕГЭ, т.к. сюжет происходит в наше время, и проблемы эти актуальны именно сегодня.

Автор этого произведения Л.С.Петрушевская известна детям по мультфильму «Ежик в тумане», в котором она является автором сценария. Также для воспитательной работы на классных часах, с целью профилактики наркомании, алкоголизма и табакокурения, мы читаем и анализируем ее рассказ «Глюк». Воспитанию милосердия, отзывчивости, искренности, ответственности за свои поступки, которых так не хватает в нашей жизни, способствует рассказ «Свой круг». Эти рассказы позволяют задуматься о том, как не очерстветь в нашей

жизни, не остаться равнодушным к людям. Их можно взять и для подготовки к ЕГЭ, как привлечение аргументационного материала.

**ЦЕЛЬ МАСТЕР-КЛАССА:**
трансляция педагогического опыта по формированию УУД на уроке внеклассного чтения по рассказу Л.Петрушевской «Страна.

**ЗАДАЧИ:**
*Личностные*: воспитание нравственных качеств самосознания, ответственности, отзывчивости, сочувствия.

*Развивающие*:совершенствовать навыки коммуникабельности.

*Познавательные*: формирование навыков анализа текста через чтение и письмо; , формирование критического мышления; умения анализировать, выделять главное, обобщать и делать выводы и создавать собственные тексты.

*Регулятивные*: продемонстрировать связь между критическим прочтением авторского текста и созданием собственного; показать эффективность использования рассказа Петрушевской в рамках воспитательной работы и подготовки к итоговой аттестации выпускников; повышение интереса к чтению произведений Л.Петрушевской.

**Тип урока:** работа с художественным текстом

**Технология:** развитие критического мышления через чтение и письмо

**Приемы:** чтение с остановками, обращение к личному опыту учащихся, прогнозирование по названию, древо предсказаний, кластер, синквейн, использование «тонких» и «толстых» вопросов, эссе

**ОБОРУДОВАНИЕ**: тексты рассказа «Страна» по 1 шт. на каждого человека, фото страны, рисунок-иллюстрация к рассказу (мать с дочерью).

**Ход мастер-класса**

**Знакомство аудитории с текстом «Страна» Л.Петрушевской**.

Вызов – Предлагается синквейн без первой строчки

1. -----------
2. тоскующий, разочаровавшийся
3. забыт, печалится, замкнулся
4. он ушел ото всех
5. чувство

Вопрос:- Определите первое слово синквейна? ( Одиночество)

- Сегодня мы поговорим об одиночестве.
- Как вы думаете, актуальна ли сейчас тема одиночества? Почему?
- Запишите в тетради, как вы понимаете слово ОДИНОЧЕСТВО, и подумайте, что

может, на ваш взгляд, служить причиной этого явления

-Скажите, а всегда ли одиночество – это плохое явление. (Иногда люди мечтают об

одиночестве. Это те моменты в жизни, когда они хотят побыть одни, подумать,

остановиться, найти правильный путь дальше.)

- А может ли одиночество быть стимулом чего-либо. (Да, люди уходят , чтобы творить, создавать произведения искусства. В эти минуты им никто не нужен и они счастливы)

-Значит одиночество может дарить и счастливые минуты жизни, и самые горькие. Оно может быть и ловушкой, попав в которую, сложно найти выход, а может быть панацеей от всех бед.


-Какова же будет тогда цель урока, на ваш взгляд? (Определить, что такое одиночество)

- Сегодня мы познакомимся с рассказом Л, Петрушевской «Страна».

- Как вы думаете, о чем может быть это произведение? (Фиксирует на доске ответы учащихся)

Какие ассоциации возникают при слове «СТРАНА»?

**Составление кластера**




**Вывод:** Страна – государство, имеющее свои границы, землю, с расположенными на ней городами, селами и проживающим на ее территории народом.

1. **Знакомство с текстом через чтение и интерпретацию.** Приемы:

- **«Чтение с остановками»** (чтение осуществляется по частям, каждая часть анализируется и делаются прогнозы о дальнейшем содержании. Отвечая на вопросы дети делают предположения о содержании, рассказывают о своих ассоциациях, чувствах, ожиданиях, о том, что подтвердилось из предположений, а что – нети объясняют свои ответы.

**Первая часть текста:**

**Людмила Петрушевская**

**Страна**

Кто скажет, как живет тихая, пьющая женщина со своим ребенком, никому не видимая в однокомнатной квартире. Как она каждый вечер, как бы ни была

пьяной, складывает вещички своей дочери для детского сада, чтобы утром все было под рукой.Она сама со следами былой красоты на лице — брови дугами, нос тонкий, а вот дочь вялая, белая, крупная девочка, даже и на отца не похожая, потому что отец ее яркий блондин с ярко-красными губами. Дочь обычно тихо играет на полу, пока мать пьет за столом или лежа на тахте. Потом они обе укладываются спать, гасят свет, а утром встают как ни в чем не бывало и бегут по морозу, в темноте, в детский сад.


<u>Вопросы:</u> - Как живет эта женщина?


- Как вы думаете, как складывалась раньше жизнь женщины с такой внешностью?
- Какова внешность дочери? Как внешность девочки помогает раскрыть её характер?
- Что мы узнаем об отцы? Какое чувство вызывает у вас описание его внешности?
- Как вы считаете, как относятся к женщине окружающие? Есть ли у неё друзья?
- Почему они живут именно так?
- А как, на ваш взгляд, жила раньше эта женщина?
- Как вы считаете, о чем мечтают мать и дочь?
- Как вы думаете, любит ли девочка ходить в садик? Где ей лучше: дома или в садике?


-*Итак, перед нами главная героиня: одинокая, пьющая со следами былой красоты, никому не видимая, с вялой дочкой на руках замкнулась в своей однообразной повседневной жизни. А жизнь в большом городе идет своим чередом и мимо, не замечая ее.*

-*Пофантазируйте, что будет дальше?*

Задание: - Составьте кластер – описание матери и дочери






**Читаем 2 фрагмент.**

Несколько раз в году мать с дочерью выбираются в гости, сидят за столом, и тогда мать оживляется, громко начинает разговаривать и подпирает подбородок одной рукой и оборачивается, то есть делает вид, что она тут своя. Она и была тут своей, пока блондин ходил у ней в мужьях, а потом все схлынуло, вся прошлая жизнь и все прошлые знакомые. Теперь приходится выбирать те дома и те дни, в которые яркий блондин не ходит в гости со своей новой женой, женщиной, говорят, жесткого склада, которая не спускает никому ничего.И вот мать, у которой дочь от блондина, осторожно звонит и поздравляет кого-то с днем рождения, тянет,

мямлит, спрашивает, как жизнь складывается, однако сама не говорит, что придет: ждет. Ждет, пока все не решится там у них, на том конце телефонного провода, и наконец кладет трубку и бежит в гастроном за очередной бутылкой, а потом в детский сад за дочкой.

Вопросы:

- Что нового узнаём мы о женщине и её дочери?
- Так чего же ждет женщина? Какое место в её жизни занимают эти посещения?

Почему?

-Опишите новую жену блондина? Расскажите, как живется ему теперь? Счастлив ли

он? Изменилось ли у вас отношение к нему? Почему?

-Как ведет себя женщина в гостях? Как к ней относятся окружающие? Являются ли

они её друзьями?

- Зачем она ходит в гости?
- Как вы думаете, как относится автор к своей героине?

Задание: Дополните кластер характеристики героев (желтые ячейки)

-*Все-таки женщина ждет, надеется, что все изменится, она пытается вернуться в ту жизнь, но большой город не принимает ее, молчит. И тогда безысходность и снова «в гастроном за бутылкой»*

**Читаем 3 часть.**

Раньше бывало так, что, пока дочь не засыпала, ни о какой бутылке не было речи, а потом все опростилось, все пошло само собой, потому что не все ли равно девочке, чай ли пьет мать или лекарство. Девочке и впрямь все равно, она тихо играет на полу в свои старые игрушки, и никто на свете не знает, как они живут вдвоем и как мать все обсчитывает, рассчитывает и решает, что ущерба в том нет, если то самое количество денег, которое уходило бы на обед, будет уходить на вино — девочка сыта в детском саду, а ей самой не надо ничего.

Вопросы:

- Как вы считаете, девочке на самом деле все равно, что делает мать?

-Кто виноват в том, что мать и дочь так живут?

-Можно ли что-то изменить ещё?

-Будет ли мать что-то менять? Дочь?

Задание: Доделайте кластер (синие ячейки)

-*Мы попытались заглянуть в сумерки сердца нашей героини.*

-*Что произошло за такой короткий период ?*

-*Что особенно пугает?*

-*К чему может привести такой образ жизни?*

-*Насколько актуальна эта проблема?*

-*Это проблема нашего современного общества, неслучайно она поднимается в современном кинематографе.*

-*Подобные события могли произойти где угодно и с кем угодно. Однако, как сказал один римский философ Сенека «пока человек жив, он никогда не должен терять надежды»*

-*Как, по вашему мнению, закончится рассказ?*

**Читаем 4 фрагмент.**

И они экономят, гасят свет, ложатся спать в девять часов, и никто не знает, какие божественные сны снятся дочери и матери, никто не знает, как они касаются головой подушки и тут же засыпают, чтобы вернуться в ту страну, которую они покинут опять рано утром, чтобы бежать по темной, морозной улице куда-то и зачем-то, в то время как нужно было бы никогда не просыпаться.

Вопросы:

-Какие сны снятся девочке и матери?
-Почему они не хотят просыпаться?
-С чем ассоциируется слово сон в этом тексте?
-Рассказ начинается и заканчивается одним и тем же событием, почему?
-Как, по вашему мнению, сложится жизнь этих людей дальше?
- О какой же стране шла речь в заглавии?
-Считаете ли вы удачным название рассказа? Почему?

Задание: дополните кластер (розовые ячейки)

-*Финальная часть повторяет начало, кольцевая композиция – создает эффект бесконечности такой жизни.*

- **«Толстые и тонкие вопросы» -** приемы, развивающие умения задавать вопросы. («тонкие» вопросы – вопросы репродуктивного плана, требующие однословного ответа, «толстые» вопросы – вопросы, требующие размышления, привлечения дополнительных знаний, умения анализировать);

Класс делится на группы (дифференцированный подход) и в зависимости от состава и уровня группы ребятам предлагается составить вопросы для одноклассников, направленные на дальнейшую работу с текстом и его осмысление.

| «Тонкие» вопросы | «Толстые» вопросы |
|---|---|
| Кто…? (Кто героиня рассказа?<br>Что…?<br>Когда…? (происходят события)<br>Как звать…? | Почему пьет эта женщина?<br>Как можно быть «никому не видимой»?<br>Почему вещи названы вещички?<br>Для чего повторы «прошлая», «прошлые»?<br>Зачем упоминание о новой жене яркого блондина?<br>Слово «бежит» привлекает внимание. Куда спешит эта женщина? |

- **Ключевые слова +формулируем проблемы+ищем позицию автора (для ЕГЭ)**


Мать, дочь, бутылка, прошлая жизнь, сны – проблемы одиночества, ответственности, зависимости от вредных привычек, ненужности, забытости, маленького человека – позиция автора: Как она каждый вечер, какой бы ни была пьяной, складывает вещички своей дочери для детского сада…

**4. Итоги. Составление итогового кластера и сравнение с первым:**

- Давайте вернемся к началу урока. Что может скрываться под заголовком «страна» сейчас, когда текст прочитан нами? О какой стране идет речь в рассказе? Для героев рассказа такой страной оказался сон.

С- (страдание)
Т- (тоска, тревога)
Р- (радость, равнодушие, ревность)
А- (апатия, алкоголь, абсурд)
Н- (нужда, несчастье, надежда)
А- (ад, аномалия)

Ассоциации на слово страна после прочтения рассказа. Страна – это мой мир (метафора).




**5. Рефлексия.**

- *Сделайте вывод о жизни матери и дочери. ( Они очень одинокие и несчастные люди, они мечтают о другой жизни, но не могут выбраться из своего одиночества, потому что у них нет друзей. Они создали страну, в которой счастливы, и уже не хотят из неё возвращаться. А это самое страшное. У них потерян смысл жизни.)*

-*Что творится в вашем сердце сейчас, после прочтения?*

-Скажите, а всегда ли одиночество – это плохое явление. ( Иногда люди мечтают об одиночестве. Это те моменты в жизни, когда они хотят побыть одни, подумать, остановиться, найти правильный путь дальше.)

-А может ли одиночество быть стимулом чего-либо. (Да, люди уходят , чтобы творить, создавать произведения искусства. В эти минуты им никто не нужен и они счастливы.)

- О каком понимании одиночества идет речь в данном рассказе? ( Об одиночестве забытых всеми людей)

-Можем ли мы что-то сделать, чтобы таких людей было как можно меньше? (Быть внимательными к людям, понимать их проблемы и видеть пути выхода из них)

-В чем главная проблема героев этого рассказа? ( У них не было друзей, к ним все были равнодушны. А равнодушие окружающих может привести к гибели всего человечества, ведь даже животные заботятся друг о друге)

**Задание** - Составьте синквейн - свое понимание слова одиночество

Возможно, мы сегодня ответили не на все вопросы. Но хорошо уже то, что мы задумались над серьезными проблемами. Для каждого из нас своя страна, свой мир начинается с дома.

**Домашнее задание - творческая интерпретация текста:**

- **Написание творческой работы «Год спустя».** Представьте себя писателями и напишите продолжение рассказа, что стало с героями год спустя.
- **Написание эссе «Что бы я хотела изменить в стране, в которой живут герои рассказа?» «Чего заслуживает героиня: справедливости или милосердия?»**
- **Письмо по кругу** (предполагает групповую форму работы. У каждого члена группы – тетрадь и ручка, каждый записывает несколько предложений на заданную тему, затем каждый передает тетрадь соседу, который должен продолжить его размышления, тетради передаются до тех пор, пока каждая тетрадь не вернется к своему хозяину).

## <u>Туган телем – иркә гөлем</u>

*(Рус мәктәбенең 4 сыйныфы татар төркеме өчен дәрес конспекты)*

**Ганиева Алсу Сәхиулла кызы,**
**Кәлимуллина Асия Хәйдәр кызы**
*Менделеевск шәһәре*
*1 нче урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Максат: Укучыларның тел турында алган мәгълүматларын системага салу; телнең әһәмиятен, әдәбиятта кулланылышын ассызыклау һәм тел турында мәгълүмат җыеп яклый белү; туган телебезгә карата хөрмәт һәм горурлану хисләре уяту.

Җиһазлау: мультимедиа проекторы, экран, презентация, лэпбуклар.

Дәрес тибы: белем һәм күнекмәләрне ныгыту, системага салу.

Дәрес барышы:

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.

Дәресне оештыру. Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

II. Өй эшен тикшерү. Укучылар, сезгә туган телебез турында табышмаклар, мәкальләр, шигырьләр туплап килергә кирәк иде. Дәрестә без аларны кулланырбыз, лэпбуклар төзербез.

III. Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.

- Балалар, игътибар итик әле.

Ачыдан ачырак, татлыдан татлырак,
Усалдан усалрак, дөрестән дөресрәк
Нәрсә бар дөньяда? (Тел)

- Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез? (Тел турында)
- Дәресебезнең темасын ничек атарбыз? (Минем туган телем... Туган тел...)
- Дәреснең максаты нинди булыр? Без дәрестә нишләрбез? (Тел турында белемнәрне искә төшерербез, яңалык алырбыз, кулланырга өйрәнербез)
- Сез нинди телләр өйрәнәсез? Ә илебездә нинди телләр бар?
- Телләр белән бәйле нинди бәйрәмнәр беләсез? (Әлифба бәйрәме, 21 нче февраль – телләр көне....)
- Тел кешегә ни өчен кирәк? (Аралашу өчен, хат язу өчен, чит илләргә чыгу өчен...)
- Без кемнәр белән аралашабыз? (Гаиләдә, дуслар белән ...)
- Тел сүзенең бер хәрефен алыштырып фигыль ясагыз әле. (Бел) Тел бел!

Бүген татар теле турында нәрсәләр белүебезне ачыкларбыз.(Төсле карандашлар таратып, шул төсләр буенча төркемнәргә бүлү)

IV. Белемнәрне актуальләштерү. Өйдә ятланган тел сүзе белән бәйле табышмакларны чиратлап, төркемнәр арасында әйтешү. Шуларның җавабын рәсемнәр арасыннан табып күрсәтү.

1. Теле юк – үзе аңлата. (Китап)
2. Күрешергә кулы юк,
Сөйләшергә теле юк.
Аның белән күрешмәгән,
Киңәшмәгән кеше юк. (Китап)
3. Теле юк, теләсә кем белән сөйләшә,
Гәүдәсе юк, кәгазьдән күлмәк кия. (Хат)
4. Телләре бар – сөйләми,
Көйләре бар – теләмәсә, көйләми (Гармун)
5. Авызы бар – теле юк,
Тавышы бар – сүзе юк. (Курай)
6. Авызы юк – кычкыра,
Теле юк – чакыра. (Быргы)
7. Ап-ак йөзле,
Унике күзле,
Ике телле,
Өйрәтә һәркемне. (Сәгать)
8. Үзе сөйли, үзе җырлый,
Ә үзенең теле юк. (Радио)
9. Сөйләп бирә тел белән,
Сүзе китә юл белән,
Юлы агач башында. (Телефон)

- Укучылар, эшегезне бәяләргә онытмагыз. Дөрес җавапка өстәл өстендәге сары түгәрәккә ак бит-таҗларны ябыштыра барыгыз.
- Мәкальләрнең башы бар, ахыры юк, шуларны дәвам итәргә кирәк.

1. Акылы кысканың теле .... (озын)

2. Ана баланы ике кат тудыра:
Бер кат – тән биреп!
Икенче кат – ..... (тел биреп)
3. Татлы тел тимер .....(капканы ачар)
4. Иле барның ..... (теле бар)
5. Телең ни әйтсә, колагың .... (шуны ишетер)
6. Телләр белгән – ....... (илләр белгән, гизгән )
7. Тел ташны .... (эретә)
8. Теле татлының дусы ..... ( күп)
9. Иң татлы тел – туган тел,
Анаң сөйләп ..... (торган тел)
10. Туган телен кадерләгән халык ..... (кадерле булыр)
- Дөрес җавапка шулай ук ромашка таҗларын ябыштырабыз.

V. Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану.

1. Шигырьләрне укыгыз, аларның исемен һәм авторын атагыз.

Еракта да син
Йөрәккә якын;
Торган җир – көмеш,
Туган җир – алтын,
Туган җир якын!
Туган тел якын! ( “Туган җир алтын” Хәсән Туфан)

Җирдә миңа ни кирәк?
Әллүкиле көй кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Тукай туган тел кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәгән өй кирәк! (“Җирдә миңа ни кирәк?” Шәүкәт Галиев)

2. Шигырь юлларын дөрес итеп урнаштырырга һәм укып бирергә.

Урысча да яхшы бел.
Татарча да яхшы бел,
Иң кирәкле затлы тел.
Икесе дә – безнең өчен (Шәйхи Маннур)

Ул – минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур ил
Ул – минем туган телем.
Дөньяда иң-иң матур тел (Энҗе Мөэминова)

- Дөреслеген тикшерәбез! Эшләрегезне бәяләргә онытмагыз.

VI. Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.

Өстәлегездәге әзерләнгән материалларны системага салып, лэпбукның макетын төзибез. Милли бизәкләр, бәйрәмнәр, шагыйрьләрнең фотосурәтләрен кулланырга мөмкин. (Укучылар макет төзиләр)

VII. Үзләштерү дәрәҗәсен ачыклау. Җибәрелгән хаталар буенча фикер алышу һәм төзәтмәләр кертү.

Укучылар үзләренең төзегән макетларын яклап, чыгыш ясыйлар.

- Ә хәзер, укучылар, тел сүзенә синквейн төзергә кирәк. Тел – 2 сыйфат – 3 фигыль – 4 сүздән торган фраза – синонимы.

Тел
Бай, матур
Сөйләтә, уйлата, аралаштыра
Туган тел, матур тел
Аралашу чарасы.

Тел турында бергә синквейн төзедек.

- Ә Тукай бабабыз моннан 100 еллар элек тел турында нинди матур шигырь язып калдырган? Халык аны көйгә салган. Җырлыйк әле. (“Туган тел” җырын җырлау)
- Тапкырлар һәм зирәкләр өчен кызыклы табышмаклар да бар әле.

Һәркемдә бар. Ул нәрсә?
Бер тавык – тавык, ике тавык нәрсә?
Нинди сүздә алты “Н” бар?
К3 – нинди сүз язылган?

VIII. Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.

Мәҗбүри: вакытлы матбугаттан тел сүзе кергән биш җөмлә язарга.
Ярым иҗади: табышмак уйларга.
Иҗади: тел турында кечкенә хикәя яки шигырь язарга.

IX. Рефлексия (дәрескә йомгак ясау). Без дәрестә нәрсә эшләргә тиеш идек?

Ничек эшләдек? (чишү юллары искә төшерелә);
Нинди нәтиҗәгә килдек? дигән сорауларга җавап бирү.
Өстәлегездә нинди рәсем килеп чыкты? Ап-ак ромашка рәсеме. Мин туган телебезнең, ак ромашка кебек, чиста, камил, саф булуын телим.

Тел ачылгач әйтә алсаң: “Әни!” – дип,
Тел ачылгач әйтә алсаң: “Әти!” – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле ул булмас.
Соң минутта әйтә алсаң: “Әни!” – дип,
Соң минутта әйтә алсаң: “Әти!” – дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр. (Зөлфәт)

Туган телебезне саклыйк, баетыйк, укучылар!

## **Катнаш никахның милләт язмышына йогынтысы**

***Гиззатуллина Айгөл Ильфак кызы,***
***Яр Чаллы шәһәренең 41 нче урта мәктәбенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Милләт язмышы – бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе. Татар милләтенең киләчәге бармы? Телебез югалмасмы? Бу сораулар безнең һәркайсыбызны борчый.

Минем тикшеренү эшемнең **максаты:**

- туган телемнең бүгенге көндәге ролен ачык чагылдыру;
- милли телебезне саклау һәм киләчәк буынга әдәби мирасыбызны түкми-чәчми җиткерү;

Бүгенге көндә мине борчыган иң төп сорауларның берсе – катнаш никахларның арта баруы. Әйе, инде 20 нче йөз башында ук татар әдипләре Г.Тукай, Г.Исхакый бу проблеманы күтәрәләр, милләт язмышы аларның әсәрләрендә төп урынны алып тора. Ә милләт язмышы ул – тел язмышы. Катнаш гаиләләр арта бара, татарны үз эченә йота бара.

Милләт – шулай ук олы бер гаилә. Әгәр дә без милләтебезне зур бер гаилә, татарның чын мәгънәсендә тату, дус, гореф-гадәтләрен онытмаган олы гаиләсе дәрәҗәсенә күтәрә алабыз икән, берсүзсез, аның ныклыгын арттырачакбыз. Мондый милләт инде чын мәгънәсендә тулы канлы тормыш белән яшәргә лаеклы милләт, бу милләтнең гомере озын булыр дип әйтергә була. Ә дәүләтнең вазифасы нидән гыйбарәт? Дәүләт ул – шушы “милләт” дип аталган зур гаиләнең йорты. Ә йортта һәрвакыт тәртип булырга тиеш. Дәүләт шушы тәртипне урнаштырып, законнарга таянып, карарлары, тоткан юнәлеше, программалары белән милләткә яшәү өчен шартлар тудыра. Әгәр дә инде дәүләт аягында нык басып тормый икән, билгеле, аның мөмкинлекләре дә зур була алмый. Бүген милли гаиләнең – милләтнең яши торган йорты – дәүләте бөтен яктан корылып бетмәгән. Шуңа күрә дәүләтнең кайбер вазифаларын гаилә һәм милләт үзенә алырга тиеш була. Менә шунлыктан безнең гаиләгә – татар гаиләсенә – дәүләте булган гаиләгә караганда йөк күбрәк төшә.

Газета битләрендә әледән-әле катнаш никах, тел, милләт турында мәкаләләр басылып тора. Аларда кайберәүләр катнаш никахны мактап, икенчеләре тәнкыйть күзлегеннән чыгып, үз фикерен белдерә. Күпме генә бәхәсләшсәләр дә, уртак фикергә килеп, мәсьәләнең асылына төшенеп, моңа этәргән сәбәпләрне ачып салмыйлар һәм нәтиҗә дә ясамыйлар. Мин дә бүгенге чыгышым аша үз фикеремне, күргән-ишеткәннәрем аша кайбер татар егет-кызларына дөньяга аек акыл белән карап, тормышта үз парларын сайлауда булышлык итеп, ялгыш адымнан алып калырга ярдәм итә алсам, бик шат булыр идем.

Татар балаларының үз милләтен, телен, кыйбласын югалта башлавы балалар бакчасына беренче адымын ясаган көннән башлана да инде.. Юньләп русча да белмәгән ата-ана вата-җимерә бөек телне өйрәтеп, бала күңеленә маңкортлык орлыклары сала һәм бала әби-бабалары, әти-әниләре сөйләшкән телне бернигә дә ярамый дип инанып үсә. Туган телем көнем, яшәешем өчен кирәк дип, бишек җыры белән балаларның каннарына сеңеп үссә, һичшиксез, киләчәктә татар теле бетәр дип уйлыйсы да булмас иде.

Ачыктан-ачык үз көнеңә, динеңә, халкыңа каршы баруны хыянәт юлы дип саныйм һәм бу бернинди дә хөрмәткә лаек түгел.

Рәсми саннарга караганда, Татарстанда катнаш никахтагылар азрак аерылыша икән. ЗАГС идарәсе катнаш никахлар арта баруны да әйтә. Аерылышулар гомум кушылучыларның яртысын тәшкил итсә, катнаш никахтагылар 25% ны гына.

Гаиләләр ныклы булганга күрә, милләт бүгенгә кадәр көчен югалтмады. Гаиләнең ныклыгы безнең милләтне бүгенгә кадәр исән-сау китерде. Йә рәсми, йә дини никах белән генә торырга ярамый. Бик нык уйланганнан соң гына өйләнешергә кирәк. Элек гаиләләр зур булган. Хәзер инде әби-бабайларның роле гаиләдә юк кебек, элек гореф-гадәтне алар саклап торган. Кешелек кыйммәтләре кими барган саен, андый очраклар да арта.

Барлык милләт кешеләре белән дус яшәргә кирәк. Әмма дин, милләткә килгәндә, ашы ашка, урыны башка булырга тиеш. Егетләребез, кызларыбыз тормышларында дөрес юл сайлап, милләтебезне үстерер, ныгытыр, дип ышанам. Татар кызлары үзебезнең егетләргә чыксын иде. Безнең халык хисабына башка милләт вәкилләрен арттырмасыннар иде. Үз татарыңа, үз каныңа җитәме соң?

Бүген минем өчен төп сыйфат билгесе – гаиләм, нәселем, туган-тумачаларым. Аннан соң – милләт. Хатын-кызларыбыз башка милләткә
кияүгә чыга икән, милләтебез югалачак.

Алдагы ел белән чагыштырганда безнең районда катнаш никахларның саны 6 процентка арткан. Былтырның бу чорында 21 процент булса, хәзер 27 процент.

Без сөйләргә яратабыз, фәлән җирдә фәләнчә татар яши, дип. Ләкин әнә шул 70-80 яшьлек картлар, аларның 50-60 яшьлек балалары үлеп бетсә, алар урынына кем кала?

Дәүләтебез дә, динебез дә бар, ә телебез бетеп бара – чаң сугарга вакыт җитмәдеме? Бар нәрсәбез дә беткәч, соң булмасмы?

Әти-әниләр барсы да балаларының бәхетле булуын тели. Шуңа күрә иң элек аларга ислам тәрбиясе бирергә кирәк. Бер вәгазьдә: "Балаларыбызның катнаш никахына булдыра алган кадәр каршы торырга кирәк" диелгән. Бүген күпчелек яшьләребезнең гаиләсен, бигрәк тә катнаш гаиләне, ислам кануннары буенча алып барырлык белеме дә, сәләте дә юк. Күп очракта алар агымга эләккән йомычка кебек кенә. Шул агым аларны ярга чыгарып атканчы агып баралар.

Татар милләтен ирекле итеп күрү Г.Исхакыйның төп хыялы булган. Ул үзенең иҗатында татар милләтенең язмышы өчен борчылып кына калмыйча, ничек милләт буларак сакланып калырга икәнлеген дә күрсәтә. Әдипнең милли рух белән сугарылган “Җан Баевич”, “Зөләйха” пьесалары татар драматургиясендә зур роль алып торалар. Зөләйха үзенең намусына тугрылыклы булса, “Җан Баевич” комедиясенең төп герое Шакирҗаннар милләтебезгә хыянәт итәргә торалар. Корсак кануннары буенча яшәүчеләргә Ватан ни дә, туган тел ни – барыбер. Җан Баевичның үз – үзен тотышы да кайбер бүгенге маңкортларга охшый. Алар да исемнәрен үзгәртеп, вата – җимерә урысча сөйләшеп, үзен бик югары культуралы санап, үзенең милли яшәешеннән баш тартучылар юк түгел.

**Нәтиҗә:** Татарда Исхакыйдай белемле, замана белән бергә атлаучы зыялы яшьләр, акыл – нәсихәт бирә алырдай әдипләребез аз түгел. Аларның әсәрләре безгә, яшь буынга эш сөючән, кунакчыл, белемгә омтылучы, туган төбәгебезне, халкыбызны яратучы, үз халкыбыз белән горурланучы бала булып тәрбияләнергә мөмкинлек бирә. Милли рухлы яшьләребез булганда, аларда

гаиләдә үк нигез салынган милли тәрбия, милли үзаң булса, татар дәүләте әле яшәячәк.

И туган телем, син яшәсәң генә татар милләте яшәр, тормышның яме – тәме артыр.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**


1. “Аҗаган” газетасы, 2011, сентябрь, 3 б.
2. Ә.Кәримуллин “Тел – милләтнең сакчысы” – Казан: татар китап нәшрияте, 1997, 196 б.
3. Гомәр Саттар Мулилле “Без кемнәр?”, Мирас, 1998, № 2.-76 б.;
4. Г.Саттаров “Туган тел гаме”, Татарстан журналы, июнь, 2007,

43 – 45 б.

5. М.Лотфуллин “Телне саклау калу – халыкны саклау ул” –Казан: Мәгариф, 1998, № 9.

78 -79 б.


## <u>Ф.Хөсни “Сөйләнмәгән хикәя”</u>

***(8нче сыйныф, татар төркеме)***


**Гомәрова Альбина Мөнир кызы,**

*Зәй муниципаль районы*

*“Зәй шәһәре 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең*

*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*


**Максат**

1) Теманы аңлау һәм уңышка ирешү өчен җирлек тудыру; фикерләү сәләтен үстерү эшен дәвам итү.

2) Кеше бәхете” төшенчәсенең мәгънәсен аңлау өчен шартлар тудыру;

герой кылган гамәлләрне анализлау аша образны аңларга ярдәм итү.

3) Әхлакый мәсьәләләрне аерып чыгарып, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр асылына бәя бирергә ярдәм итү.

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **1) Метапредмет:**<br>**Танып-белү:**<br>Белемнәрне структуралау, ягъни өлеш –кисәкләренең эчке төзелешен тәртипкә салу.<br>**Коммуникатив:**<br>Әдәбият дәресе грамматикасының нормаларына туры китереп монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булу;<br>**Регулятив:**<br>Билгеле һәм билгеле булмаганны чагыштырып, хәл ителергә тиешле уку бурычын кую.<br>Бирелгән үрнәктән тайпылыш һәм аермалык булу-булмавын ачыклау өчен, эш алымын һәм аның нәтиҗәсен бирелгән эталон-үрнәк белән чагыштыру<br>**2) Предмет:**<br>Фатих Хөснинең “Сөйләнмәгән хикәя” әсәрен өйрәнү, тема турында төшенчә формалаштыру.<br>**3) Шәхси:**<br>Җаваплылык хисе, һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү теләге тәрбияләү. | | |
| **Дәреснең тибы** | Яңа белемнәрне үзләштерү дәресе | | |
| **Төп төшенчәләр** | Фатих Хөснинең “Сөйләнмәгән хикәя” әсәрен өйрәнү, тема турында төшенчә формалаштыру. | | |
| **Предметара бәйләнеш** | Рус теле | | |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, төркемдә, парларда, индивидуаль. | | |
| **Чыганаклар** | Дәреслек, сүзлекләр, әдәбият дәфтәрләре, методик әсбаплар | | |
| **Җиһазлау** | Ноутбук, , экран (такта), Ф.Хөснинең портреты , “Сөйләнмәгән хикәя”әсәре. | | |
| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **УУГ** |
| **<u>1) Мотивлаштыру</u>**<br><br>Максат: уңай психологик халәт тудыру. | Укучыларны уку эшчәнлегенә тарту<br>Исәнләшү<br>Дежур укучы белән әңгәмә. | Дәрестә төркемнәрдә эшләү кагыйдәләрен искә төшерәләр: башкаларны тыңла, үз фикереңне ачык әйт, игътибарлы бул. | **Шәхси:** әдәп-әхлак кагыйдәләрен искә төшерү, бер-берсенә уңышлар теләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **2) Актуальләштерү**<br><br>Максат: яңа белем алуга әзерлекне тикшерү, аның темасын формалаштыру.<br>Өй эшен тикшерү. | Үткән дәрестә өйрәнелгән темаларны искә төшерү.<br>-С.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатын искә төшерү.<br>- “Җырларымда телим”, “Клиндерләр эзлим”шигырьләрен сәнгабле итеп ятлап килергә кушылган иде.<br>- Таблица тутыру. | -С.Хәкимнең тормыш юлы, иҗатын һәм<br>- “Җырларымда телим”, “Клиндерләр эзлим”шигырьләрен сөйлиләр.<br>- Укытучы биргән таблицаны тутыралар.<br>Фатих Хөсни һәм аның “Сөйләнмәгән хикәя”буенча язылган җөмләләрнең дөрес, дөрес түгел сүзләре янына үзләренең тамгаларын куялар. | **Регулятив:**<br>Билгеле һәм билгеле булмаганны чагыштырып, хәл ителергә тиешле уку бурычын кую. |
| 3**) Проблемалы сорауны ачыклау өчен сынап карау этабы (пробный этап).**<br><br>Максат: <u>укучының нинди авырлык белән очрашуын билгеләү</u> | Проблема тудыра.<br>- Укучылар, бу таблицаны тутырганда нинди авырлык белән очраштыгыз?<br>-Маһруй җиңги, Биктимер турында язылган җөмләләргә нишләп үзегезнең тамгаларыгызны куймадыгыз?<br>-Фатих Хөсни турында каян белдегез?<br>-Таблицада бирелгән“Биктимернең бәхете озакка бармый”дигән | -Без Маһруй җиңги, Биктимер исемле геройлар турында белмибез.<br>-Без шушы геройлар катнашкан хикәяне укырга тиеш.<br>-Фатих Хөсни турында 7 нче сыйныфта укыдык.<br>-Бәхет- ул сәламәтлек, әти-әниең исән –сау булу,бишлегә уку, дусларың булу, | **Коммуникатив:** информация не эзләү һәм туплауда инициативалы хезмәттәшлек**.** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җөмләгә игътибар итегез.<br>-Нәрсә ул бәхет, сез аны ничек аңлыйсыз?<br>-Дәреслектә Фатих Хөснинең нинди әсәре бирелгән?<br>-Димәк, без бүгенге дәрестә нинди әсәр белән танышачакбыз? | олимпиадаларда урын алу.<br>-Дәреслектә Фатих Хөснинең “Сөйләнмәгән хикәя” әсәре бирелгән.<br>-Без Фатих Хөснинең “Сөйләнмәгән хикәя”әсәре белән танышачакбыз. | |
| **<u>4) Кыенлыктан чыгу планы. </u>(яңа белемнәрне куллану).**<br><br>Максат: кыенлыктан чыгу юлларын ачыклау | Укучыларны проблеманы хәл итүгә оештыру.<br>Әйе,безнең бүгенге темабыз<br>Фатих Хөснинең “Сөйләнмәгән хикәя” әсәрендә бәхет мәсьәләсенең чагылышы. | | **Коммуникатив:**проблеманы ачыклау, тәңгәлләштерү, аны хәл итүнең альтернатив юлларын эзләү һәм бәяләү. |
| **<u>5) Планны тормышка ашыру/яңа белемне куллану.</u>**<br>Максат: Теманы аңлау һәм уңышка ирешү өчен җирлек тудыру; фикерләү сәләтен үстерү эшен дәвам итү. | -Укучылар,дәресебезнең максатына ирешү өчен без ниләр эшләргә тиеш?<br><br>-Укучылар, әсәрдә искергән, бүгенге көндә кулланышта булмаган сүзләр очраячак.<br>-Әйдәгез бирелгән сүзләр белән танышып китик.<br><br>-Хәзер әсәрне эчтән укыйбыз. | -Әсәрне укырга, аның эчтәлеген аңларга, сорауларга җавап бирергә, текстның эчтәлеген бергәләп ачарга тиеш.<br>-Теле кычыту-сөйләргә теләү<br>-мәлҗерәү – җебеп төшү<br>-сырлы бәләк – яссы агач тукмакчык. | **Танып-белү:** Кирәкле информация не эзләп табу;<br>**Коммуникатив:** карар кабул итү һәм аны тормышка ашыру. |
| | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Ял минуты** | | | |
| **<u>6) Беренчел ныгыту</u>**<br><br>Максат: яңа белемнәрне биремнәрдә куллану/тышкы сөйләмдә әйтеп күрсәтү | - Укучылар, әсәр ошадымы,барыгыз да аңладымы? Әйдәгез әле шуны тикшерер өчен сорауларга җавап бирик. | -1. Әсәрдә бирелгән вакыйганың төп герое кем?<br>2. Вакыйганы кем сөйли?<br>3.Малай нинди гаиләдән? Моны кайсы сүзләр яки җөмләләрдән белеп була?<br>4.Тау шуучы малайлар янына җиткәнче, ул ничек бара, ничек кайта?<br>5.Малайны өйдә ничек каршылыйлар?<br>6. Ни өчен Биктимерне әтисе ачуланмый? | **Танып белү:** Белемнәрне структуралау , ягъни өлеш - кисәкләрнең эчке төзелешен тәртипкә салу**.**<br>**Коммуникатив:** Аралашу максатына һәм шартларына туры китереп, үз фикереңне җитәрлек дәрәҗәдә тулы һәм төгәл итеп әйтә белү; |
| **<u>7) Үз-үзеңне тикшерү өчен мөстәкыйль эш.</u>**<br><br>Максат: үзләштерелгән белемнәр буенча нәтиҗә ясау. | -Укучылар, хәзер әсәрне өлешләргә бүлеп сөйлибез.Әйдәгез өлешләргә исем бирик. | 1 нче өлеш:<br>энинең камыры кабара.<br>2 нче өлеш: Биктимер- иң бәхетле кеше.<br>3 нче өлеш:<br>ата-ананың борчылуы. | **Танып белү:** уй- фикерне сөйләмдә һәм язма формада аңлап һәм ирекле оештыру.<br><br>**Коммуникатив:** Әдәбият дәресенең грамматикасының нормаларына туры китереп монолог төзү һәм диалогта |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | катнашу осталыгына ия булу; |
| **<u>8) Белемнәрне системага салу.</u>**<br><br>Максат: алган белемнәрне куллану һәм ныгыту. | -Ә хәзер беренче төркем икенчегә, икенче төркем өченчегә, өченче төркем беренчегә текстка кагылышлы сораулар бирә. | -Төркемнәрдә эшлиләр.<br>Укучылар, дәреслек, сүзлекләрне кулланып, сораулар бирәләр<br>1.Малайның әнисе нәрсә пешерә?<br>2. Биктимер ни өчен табага утырып шуа?<br>3.Ни өчен Биктимерне әтисе ачуланмый? | **Регулятив:** үзләштерелгән һәм үзләштереләсе белемнәрне аера белү һәм төшенү, үзләштерелгәннең сыйфатын һәм белү дәрәҗәсен аңлау.<br>**Коммуникатив:**<br>Әдәбият дәресенең грамматикасы нормаларына туры китереп монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булу; |
| **<u>9) Рефлексия</u>**<br><br>Максат: үз эшчәнлегеңә кире кайтып бәя бирү. | Үз эшеңне бәяләүгә юнәлтелгән сораулар куела.<br>-Бүгенге дәрестә без нәрсә турында сөйләштек, сиңа дәрес ошадымы, кирәкле информация ала алдыңмы?<br>-Әти-әниеңнең сүзен тыңлау ни өчен зур бәхеткә китерер. | Һәр төркемнең эшенә һәм индивидуаль чыгышларга, үз эшләренә укучылар бәя бирәләр, билге куялар. | **Танып белү**: эш – хәрәкәтләрнең алымнарын һәм шартларын , эшчәнлекнең барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп бару һәм бәяләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2.Ни өчен гаиләдә берүзең генә бәхетле булып булмый.<br>Укытучы укучылар белән берлектә эшкә йомгак ясый.<br>Өй эше бирү һәм аңлату. | | |

**«Приемы работы с текстом на уроках русского языка при написании сочинения 15.3 ОГЭ по русскому языку»**
**(Мастер-класс)**

**Жетыбаева Т.Ж., Сунгатова Р.И.,**

*учителя русского языка и литературы,*

*МБОУ «СОШ№3»*

**Цель:** обмен опытом педагогической деятельности по организации системы работы с текстом на уроках русского языка и литературы как одной из форм эффективной подготовки к сдаче ОГЭ и ЕГЭ.

**Задачи:**

- продемонстрировать коллегам приемы работы с текстом;
- прокомментировать эффективность применения данных приемов;
- отработать приемы работы с текстом на деятельностной основе (работа в группах).

**ОБОРУДОВАНИЕ:**

- мультимедийное оборудование и электронная презентация мастер-класса.

**ОСНОВНЫЕ ЭТАПЫ МАСТЕР-КЛАССА**:

1. Мотивация учения.
2. Постановка педагогической проблемы.
3. Практическая демонстрация приемов. Комментарий к приему.
4. Подведение итогов мастер-класса.

1.Очень важно на уроках русского языка рассматривать такие важные понятия как человечность, доброта, отзывчивость, сострадание. Именно рассуждение над этими понятиями и является темой сочинения 15.3 ОГЭ по русскому языку. Сегодня мы с вами и порассуждаем на эту тему, и поработаем над подготовкой учащихся к написанию сочинения-рассуждения в рамках подготовки к ОГЭ по русскому языку.

2.Основной вопрос нашего мастер-класса «Как сделать так, чтобы работа с текстом стала для учащихся не непосильным трудом, а решаемой задачей?» Для решения этого вопроса мы используем современные педагогические технологии. Это и комментированное чтение, и ряд техник и методов сингапурской системы обучения. Предлагаем поработать над сочинением «Что такое сострадание?» Для начала разделим класс на команды по 4 человека.

3.

3.1 ТЕХНИКА 1:

«***Составление карты-схемы сочинения-рассуждения»***

Перед вами на столах лежат таблицы, которые нужно заполнять в течение всей работы с текстом. В конце урока у вас должны быть заполнены все графы. Если вы все сделаете правильно, то к концу занятия у вас буде готовая схема для написания сочинения. Которое станет вашим домашним заданием.

| | |
|---|---|
| тезис+комментарий | |
| Арг.№1 (из текста) | |
| Арг.№2 (из жиз. или чит. | |
| Вывод | |

3.2 ТЕХНИКА 2: Мыслительный прием

***«Перекрестная наметка идей»***

Команда работает вместе на листе, который разделен 16 ячеек (участник №1 складывает лист формата А4 в определенном порядке, чтобы получилась таблица). В самом верху листа пишется начало предложения «Сострадание- это...» Каждый участник команды по очереди вписывает в свободную ячейку ассоциацию, связанную с этим понятием.



68

| Сострадание-это… | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

3.3 ТЕХНИКА 3: Структура ***«Тик-Тэк-Тоу»***

Составить СПП, используя все слова «Перекрестной наметки идей» по горизонтали/диагонали. Таким образом, мы даем определение понятию «сострадание». Запишите его в свою карту-схему. Это определение-первый абзац нашего сочинения. В этом же абзаце мы даем комментарий к данному определению. Это может быть рассуждение о том, на кого может быть направлено сострадание, каких обстоятельствах оно может быть проявлено, что может послужить причиной равнодушия и т. д.

3.4 ТЕХНИКА 4: ***«Комментированное чтение текста»***

Готовясь к сочинению-рассуждению, мы будем говорить о сострадании в разных его проявлениях. Для анализа возьмем отрывок из повести Н.Г.Гарина-Михайловского «Детство Темы». Читаем текст и ищем ответы на вопросы:

Какова основная мысль текста?

Почему Тема спускается в колодец?

Что движет им в этот момент?

Какие чувства он испытывает при этом?

Ответы на эти вопросы и станут первым аргументом, который вы должны внести во вторую строку карты-схемы. Для составления второго аргумента мы заполним интеллект-карту. Используя структуру «Финкин Мэпс».


3.5 ТЕХНИКА 5: Структура ***«Финкин Мэпс»***

Данная карта дает возможность проработать не только аргументы по одному данному понятию, но и дает возможность проработать смежные или противоположные понятия. Теперь можно составить второй аргумент и внести его в нашу карту-схему. Плюс данной работы в том, что учащиеся могут подобрать аргументы из читательского опыта, которые могут пригодиться не только при написании сочинения 15.3 ОГЭ в 9 классе, но и итогового сочинения в 11 классе и сочинения ЕГЭ по русскому языку в 11 классе.



69

Подводя итог рассуждению, делаем вывод, подтверждающий тезис из нашей карты-схемы. Без него наше рассуждение будет незаконченным. Вывод по смыслу должен быть связан с тезисом. Записываем вывод в карту-схему.




3.6 ТЕХНИКА 6: Структура ***«700 рублей Самэри»***

Домашнее задание: используя карту-схему, написать сочинение «Что такое сострадание?», используя структуру «700 рублей Самэри» (70 слов, 10 рублей одно слово).

70

4. Подведение итогов мастер-класса.

- Представленные приемы работы с текстом позволяют решать такие речевые задачи:

- учить видеть, слышать и чувствовать текст;

- пополнять речевую память учащегося;
- обогащать словарный запас;
- продуктивно усваивать учебный материал;
- прививать эстетический вкус;
- формировать собственное мнение, высказывать и аргументировать его.

Необходимо помнить, что на уроке анализа текста главным всегда остается работа с текстом, а ИКТ лишь разнообразят методы, приемы и формы работы, развивающие разные стороны личности ученика.

Тем не менее ИКТ на уроке способствуют:

- экономии времени;
- глубине погружения в учебный материал;
- повышению мотивации обучения;
- расширению возможностей урока;
- интегративному подходу в преподавании.
- возможности одновременного использования аудио-, видео-, мультимедиа-материалов.

71

(1)Няня, где Жучка? – спрашивает Тёма.

– (2)Жучку в старый колодец бросил какой-то ирод, – отвечает няня. – (3)Весь день, говорят, визжала, сердечная...

(4)Мальчик с ужасом вслушивается в слова няни, и мысли роем теснятся в его голове. (5)У него мелькает масса планов, как спасти Жучку, он переходит от одного невероятного проекта к другому и незаметно для себя засыпает. (6)Он просыпается от какого-то толчка среди прерванного сна, в котором он всё вытаскивал Жучку, но она срывалась и вновь падала на дно колодца.

(7)Решив немедленно идти спасать свою любимицу, Тёма на цыпочках подходит к стеклянной двери и тихо, чтобы не произвести шума, выходит на террасу. (8)На дворе светает.

(9)Подбежав к отверстию колодца, он вполголоса зовёт:

– (10)Жучка, Жучка!

(11)Жучка, узнав голос хозяина, радостно и жалобно визжит.

– (12)Я сейчас тебя вызволю! – кричит он, точно собака понимает его.

(13)Фонарь и два шеста с перекладиной внизу, на которой лежала петля, начали медленно спускаться в колодец. (14)Но этот так хорошо обдуманный план неожиданно лопнул: как

только приспособление достигло дна, собака сделала попытку схватиться за него, но, потеряв равновесие, свалилась в грязь.

(15)Мысль, что он ухудшил положение дела, что Жучку можно было ещё спасти и теперь он сам виноват в том, что она погибнет, заставляет Тёму решиться на выполнение второй части сна – самому спуститься в колодец.
(16)Он привязывает верёвку к одной из стоек, поддерживающих перекладину, и лезет в колодец. (17)Он сознаёт только одно: времени терять нельзя ни секунды.

(18)На мгновенье в душу закрадывается страх, как бы не задохнуться, но он вспоминает, что Жучка сидит там уже целые сутки. (19)Это успокаивает его, и он спускается дальше.

(20)Жучка, опять усевшаяся на прежнее место, успокоилась и весёлым попискиванием выражает сочувствие безумному предприятию. (21)Это спокойствие и твёрдая уверенность Жучки передаются мальчику, и он благополучно достигает дна.

(22)Не теряя времени, Тёма обвязывает вожжами собаку, затем поспешно карабкается наверх. (23)Но подниматься труднее, чем спускаться! (24)Нужен воздух, нужны силы, а того и другого у Тёмы уже мало. (25)Страх охватывает его, но он подбадривает себя дрожащим от ужаса голосом:

– (26)Не надо бояться, не надо бояться! (27)Стыдно бояться! (28)Трусы только боятся! (29)Кто делает дурное – боится, а я дурного не делаю, я Жучку вытаскиваю, меня мама с папой за это похвалят.

(30)Тёма улыбается и снова спокойно ждёт прилива сил. (31)Таким образом, незаметно его голова высовывается наконец над верхним срубом колодца. (32)Сделав последнее усилие, он выбирается сам и вытаскивает Жучку. (33)Но теперь, когда дело сделано, силы быстро оставляют его, и он падает в обморок.

(По Н. Гарину-Михайловскому)*

***Гарин-Михайловский Николай Георгиевич** (1852–1906) – русский писатель. Самым известным его произведением стала повесть «Детство Тёмы», с которой он начал своё литературное творчество.*

## Татар телен тирәнтен өйрәнүдә системалы педагогик эшчәнлеккә нигезләнү

**Җиһангәрәева Тәнзилә Рәхимҗан кызы,**
**Шәйхетдинова Әлфия Билал кызы,**

*Әгерҗе муниципаль районы*

*Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбенең*

*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Соңгы елларда уку-укыту процессына күп яңа технологияләр тәкъдим ителде. Тәкъдим ителгәннәрдән үзебезгә кирәген сайлаганда, педагогик эшчәнлегебезгә ике бурыч билгеләдек: 1) яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын үзләштерүнең иң уңышлы

вариантын кулланып эшләү; 2) нинди алым-ысуллар белән, нинди генә инновацияләрне файдаланып эшләсәк тә, эшебезнең нәтиҗәсе бер – укучы бала татар телен тиешле дәрәҗәдә үзләштерергә, яхшы белергә,ягъни, белемле булырга тиеш. Моннан тыш, татар телен туган тел буларак укыту эшчәнлегебез өч төрле мөһим аспектны исәпкә алып системага салынган: үстерелешле укыту, эшне укучының кызыксынулары һәм шәхси мөмкинлекләрен искә алып планлаштыру, ныклы белем бирү.

Хәзерге заманның информацион бай мәгълүматлы, коммуникатив шартларында үстерелешле укыту алымнарын кулланып эшләү уңай нәтиҗәләр бирә. Әмма моны укучы шәхесенең мөмкинлекләре белән яраштырып эшләү мөһимлеген аңлап эш итәбез. Эш барышында, уртача үзләштерүче баланың, халык сүзе белән әйткәндә, “канаты салынмаслык” булырга, шул ук вакытта, теманы тирәнтен үзләштерергә әзер бала да стимулсыз калмаска тиеш. 8нче сыйныфта татар теле дәресендә гади генә күнегү мисалында карап үтик. Мәкальләргә нигезләнгән күнегү сыйныфтагы берничә укучыга катлаулы булып тоелды, күпчелеге эшне тагын да дәвам итү теләген белдерде. Дәрестә беренче төркемдәге азчылыкка икенче төркем балалар мәкальләргә салынган күчерелмә мәгънәләрне аңлата алды. Өй эше итеп, мәкальләр тупларга бирелде. Эшне бар укучы да үтәгән. Ә бер бала аерым бер тематикага караган мәкальләр җыйган. Дәрестә эшләнгән гади генә бер күнегүне шәхси мөмкинлекләрне искә алып оештырылган үстерелешле укыту алымы кулланып катлауландыруның нәтиҗәләре күркәм булды. *Ут* сүзе кергән мәкальләр туплап килгән укучының мисалларын тыңлангач, алдагы дәрестә балаларга татар милли лингвокультурологиясе белән бәйләп, ут сүзенең мәгънәви төсмерләре хакында аңлатылды. Һәм без шул укучы белән бу темага эшләүне дәвам иттек. *“Татар телендә* ***“ут”*** *сүзе кергән мәкальләр”* дигән фәнни эш укучы өчен бик кадерле хезмәт булды. Ул республика конференциясендә чыгыш ясап, диплом белән бүләкләнде.

Яңача эшләргә омтылу - уңай күренеш. Шәхсән үзебез, максатка ирешү өчен, иң элек теге яки бу яңа системаның концепциясен һәм теориясен өйрәнәбез. Әлеге система турында махсус мәкаләләр, хезмәтләр белән танышабыз, шул системада

эшләүче укытучылар белән фикерләшәбез, аларның эш тәҗрибәсен күзәтәбез. Үзебез өйрәнеп, системага салып, уңышлы гына башкарып килә торган эшләрнең берсе – проект эшчәнлеге. Проект эшчәнлеге максаты – укучыларның шәхси үсешенә, уңышлы аралашуларына ирешү, аларны һәртөрле эшчәнлеккә иҗади якын килергә өйрәтү.

Проект эшчәнлеге укучыларда да, укытучыда да зур кызыксыну тудыра. Ул фикерләүне, сөйләмне, үз уйларыңны формалаштыра белү сәләтен үстерә. Укучыларны теоретик һәм гамәли эзләнүләргә этәрә торган эш. Проект эшчәнлеге барышында укучы коллективта эшләргә, үзенә бирелгән эшкә җаваплы карарга, куелган сорауларга җавап табарга өйрәнә. 5нче сыйныфтан ук башланган системалы эшнең уңай яклары күп. Укучыларның хезмәте дә, укытучы эшчәнлеге дә эзлекле үстерелештә бара.

Проект эшчәнлеген түбәндәге тәртиптә оештырабыз.

1. Проект биреме укытучы тарафыннан әзерләнә. Әмма монда теманы әзер итеп бирү бик отышлы булмаячак. Теманы укучылар кызыксындырырлык итеп, биремнәр аша ачыклау уңышлы булачак. Укучыны кызыксынырга этәрү, кызыктыра алу “хәйлә”сен куллану зарур. Бу алым Бердәм Дәүләт стандартлары буенча (ФГОС) әзерләнгән дәресләргә максат куюда да кулланыла.
2. Эшнең максатын билгеләү эше укучылар белән бергә башкарыла. “Нәрсәләр эшли алабыз?”, “Ничек күзаллыйсыз?” кебек сорауларга җаваплар тыңлана.
3. Эшнең темасы һәм максаты ачыклангач, эш тәртибен планлаштыру башлана. Проектлауның тәртибе белән танышу, укучылардан план төзетү, ул планнарны тыңлау һәм берләштерелгән план кабул итү кебек эшләр үтәлә.
4. Эзләнү-тикшерү этабында материаллар җыела, чыганаклар өйрәнелә. Бу этапта күзәтүләребездән чыгып, ассызыклап әйтәсе килгән проблема шунда: бала ничек кенә кызыксынмасын, эзләнү-тикшерү этабында укытучы аның эшчәнлеген күзәтеп, контрольгә алып, әйдәп торырга тиеш. Тәҗрибәдән күренгәнчә, бу этапны мөстәкыйльлеккә калдырырга ярамый. Балага гарантия дә биреп бетереп булмый, я, ул онытылып китә, стимуллаштырып тормаган очракта, сүрелеп тә китәргә мөмкин... Эзләнү-тикшеренү этабында укытучы

процессны күзәтә, киңәшләр бирә. Җыелган материалны системага салырга өйрәтә, төзәтмәләр кертә.

5. Проектны яклауга әзерләү. Балалар проектка куелган таләпләрне өйрәнәләр. Материал текст формасына кертелә. Укытучы проект яклау тәртибен аңлата. Чыгыш әзерләнә. Чыгыштан соң тыңлаучылар тарафыннан туарга мөмкин сораулар тикшерелә. Әлбәттә, 5-6нчы сыйныф укучылары фәнни текстны үзләре төзи алмый, бергәләп эшләү кирәк. 7-8нче сыйныфларда укучылар үзләре эшли алалар, әмма, аларда фәннилек җитеп бетми. Югары сыйныфка таба барганда, проектлау эше дәвамында фәнни стиль таләпләренә җавап бирерлек итеп эшләргә өйрәтү мөһим.

6. Проект яклау. Төркемләп эшләгәндә проектны һәр бала яклап карый. Сораулар бирелә. Чыгыш ясау авырлыгын, җаваплылыгын укучылар үзләре тоеп карарга өйрәнәләр. Үзтәнкыйть, башка укучылар фикере тыңланыла. Киңәшләр бирелә. Проектны камилләштерү эше башкарыла. Укытучы проект эшенә бәя бирә.

Үзара тәҗрибә туплаган укучыларыбыз мәктәп, район, республика конкурс-конференциядә катнаштылар. Бала үзе генә бер проектны уңышлы башкарып чыккан очрак булды. 5нче сыйныфтан 8нче сыйныфкача бер проект өстендә эшләп, аны камилләштереп әзерләделәр. Бер теманың төрле тармаклары буенча тикшерүләр үткәргән балалар фәнни конференцияләрдә катнаштылар. Әлеге система белән эшләнгән эшләребезнең, укучыларыбыз катнашкан бәйгеләрнең нәтиҗәләре зур куанычлар китерде. Мисалга, шундый проектларыбыз республика һәм Бөтенрәсәй бәйгеләрендә призлы урыннарны алдылар. Ә иң мөһиме – укучыларыбыз үз эшләреннән тәм табалар, тагын да күбрәк өйрәнүләргә омтылалар, үзләренең яңа идеяләре барлыкка килә. Бу эшләрдән эти-әниләр дә читтә калмый, ярдәм итәләр. Монысы да бик уңай йогынты – ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый.

Сүз башында телгә алынган системалылык, укучыларны белемле, кызыксынучан, максатчан итүгә юнәлтелгән эш алымнары – проектлар технологиясенең аерылгысыз өлешләре. Проектлау барышында педагогик юнәлешебез итеп

алынган үстерелешле укыту, эшне укучының кызыксынулары һәм шәхси мөмкинлекләрен искә алып планлаштыру, ныклы белем бирү аспектлары да тулысынча үтәлә.

## <u>Ю.Ермолаевның «Ике пирожный» әсәрендәге образларга бәя бирү</u>

*(5 нче сыйныфның рус төркеме өчен дәрес эшкәртмәсе)*

**Забурдаева Раушания Риф кызы,**
*Зәй муниципаль районы*
*"Зәй шәһәре 2 нче урта гомуми белем мәктәбе"*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*

Максат:
1. Ермолаевның "Ике пирожный" әсәре өстендә эшне дәвам итү, балаларны татарча үз фикерләрен әйтә белергә, геройларга бәя бирергә өйрәтү.
2. Укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну тудыру; тормышта рус телле балаларның татарча сөйләшә белүенә ирешү; укучыларның логик фикерләү сәләтен үстерү өчен шартлар тудыру, кызыксынучанлык, коллективта эшли белергә өйрәтү. Балаларга мөстәкыйль рәвештә максат куеп, нәтиҗәгә килергә ярдәм итү.
3. Укучыларны әти-әнигә булышырга, аларны хөрмәт итәргә; укучылар арасында үзара ярдәмчел мөнәсәбәт тәрбияләү.

Бурыч:
Укучыларның иҗади фикерләү сәләтен, аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыруга йогынты ясау.
Планлаштырылган нәтиҗәләр
П р е д м е т
Ю.Ермолаевның «Ике пирожный» әсәрендәге образларга бәя бирү
Метапредмет
Регулятив:
- укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү;
- кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;

Танып белү:
- тиешле мәгълүматны табу, билгеләү;
- үз фикерләрен дәлилли белү;
- нәтиҗә ясау;

Коммуникатив:
- хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү;
- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү;
- Рус әдәбияты белән бәйләп укучыларның хәтерен, игътибарлылыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү

Шәхескәкагылышлы

- Укучыларны дус, тату яшәргә өйрәтү,
- әти - әнигә һәрвакыт булышырга, ярдәмгә килергә кирәклеген төшендерү;
- матур яшәү өчен дуслаша белү сыйфатларын тәрбияләү;
- укучылар арасында үзара мөнәсәбәтләрдә ярдәмчел булу иң мөһим сыйфатларның берсе булуына ышаныч тәрбияләү.

Җиһазлау: ноутбук, экран, проектор, карточкалар, дәрес картасы, презентация, колонкалар, үз белемнәрен бәяләү өчен түгәрәкләр.

Материал: Р.З. Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова. Татар теле. 5 нчесыйныф: Рус телендә төп гомуми белеем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: “Татармультфильм” нәшрияты, 2014.

Методлар: белемнәрне системалаштыру, анализ, проблемалы укыту.

Алымнар: карточка белән эшләү, дәрес картасы белән эшләү, дәреслек белән эшләү, укытучы сөйләме, сорау-җавап әңгәмәсе, рефлексия, критик фикер йөртү.

Форма: группаларда эш, парларда эш.

Дәрес тибы: белемнәрне системалаштыру

Предметара бәйләнеш:география, татар әдәбияты, рус әдәбияты

I. Оештыру-мотивлаштыру.

Укучылар белән исәнләшү.

- Хәерле көн, укучылар!
- Кәефләрегез ничек?
-Сез дәрескә әзерме?

Кизү укучы белән әңгәмә.

-Сыйныфта кемнәр юк?
- Бүген ничәсе?
- Атнаның нинди көне?
- Һава торышы нинди?
- Дәрестә игътибар белән тыңларга, бер-берегезне бүлдермәскә, тулы җавап бирергә, үз фикереңне әйтергә кирәк.

II.Актуальләштерү

Укучылар белән диалог үткәрү, үтелгән тема буенча алган белемнәрне искә төшерү.

Тактада сораулар. Тиз генә шушы сорауларга җавап биреп, өйрәнгән хикәяне искә төшереп китәбез.

«Акыл штурмы».

1.Кызларның әниләре кухняда нәрсә пешерә?
2. Оля белән Наташа нишлиләр?
3.Әниләренә кем ярдәм итте?
4. Пирожныйны кем ашады?

III. Уку мәсьәләсен кую.

Дәреснең темасы буенча проблемалы сорау кую, аңа җавап табу.

“Идеяләр кәрҗине”

Өстәлдә кәрҗин. Сезнең алда кәгазьләр. Шушы кәгазьләргә кешеләрнең холкын чагылдырган сыйфатларны язып салырга кирәк. Бер укучы 1 генә сыйфат яза. Кәрҗингә салганда укып сала. Бергә тәрҗемәсен әйтәләр.

Тактада җаваплар күренә. Сыйфатларны яңадан кабатлаыйлар.

Тырыш-прилежный
ярдәмчел -отзывчивый
усал-злой
ялкау-лентяй
эшчән-трудолюбивый
уңган
акыллы-умный
тәрбияле-воспитанный
тәрбиясез-невоспитанный

Укучылар, сез кеше холкын белдерүче сыйфатлар яздыгыз. Әйтегез әле, бу сыйфатлар безгә ни өчен кирәк булыр? Әйдәгез әле, дәресебезнең темасын ачыклап китик.

Укучылар, сез бүген иртәнге ашны ашадыгызмы? Ә табак-савытны кем юды? Нәрсә турында сөйләшәчәкбез? Димәк, бүгенге дәресебезнең максатыбыз нинди булыр?

Укучыларның җаваплары. Җаваплар тыңлангач, укытучы үзе куйган максатлар белән таныштыра

IV.Уку мәсьәләсен чишү.
Ә хәзер төркемнәрдә эшләп алырбыз.
1 нче төркем: Оля нишли? дигән сорауга җавап яза. Бер укучы 1 генә сүз яза.
Оля рәсем ясый, булыша, савыт-саба юа, пирожный ашый.
2 нче төркем: Наташа нишли? дигән сорауга җавап яза.
Наташа китап укый, сәяхәт итә, әнисенә булышмый.
3 нче төркем: кәрҗиндәге сыйфатларны уңай һәм тискәре сыйфатларга аерып язалар.
Уңай сыйфатлар (положительные черты характера):
тырыш
ярдәмчел
эшчән
уңган
акыллы
тәрбияле
Тискәре сыйфатлар (отрицательные черты):
тәрбиясез
усал
ялкау
тыңлаусыз
хәйләкәр
V. Яңа белемнәрне үзләштерүне тикшерү.
Укучылар, әйтегез әле, бу сыйфатларның кайсы Оляга, ә кайсы Наташага карый?
Җавап. Уңай сыйфатлар-Оляның, ә тискәре сыйфатлар Наташаның холкын күрсәтә
VI. Яңа белемнәрне ныгыту
1.Кызларга бәя бирү. Парларда эш.
1. *Кызлар нинди, ни өчен?*

Оля ... , чөнки ... .
Наташа ... , чөнки ... .
2. *Кызларга киңәш бирегез (дайте совет).*
*(Раунд Тэйбл структурасын куллану)*
Оляны яхшы булган өчен макта. Әнигә ярдәм итәргә кирәк, дип,
Наташага киңәш бир.
2.Ә тормышта кешеләр нинди булырга тиеш? Ни өчен?
Укучылар үзләренең фикерләрен әйтәләр:
тырыш
ярдәмчел
эшчән
уңган
акыллы
тәрбияле
Әйе, укучылар, кешеләр тырыш, тәрбияле, ярдәмчел булганда гына илебездә тынычлык, күк йөзе аяз булыр.
Ә хәзер әйдәгез бер-беребезгә бәя биреп карыйк. 2 нче төркемнең бер укучысына 1 нче һәм 3 нче төркем укучылары бәя бирә.
VII.Рефлексия
1. Дәрес башында куйган максатыбызга ирештекме? Нәрсәләр турында сөйләштек?
2.Өй эше. 62 нче бит, 8 нче күнегү-дөрес раслауны дәфтәрегезгә языгыз.
3. Хәзер үзегезнең җавапларыгызны бәяләгез.

## “Китап безне кеше итә...”
## (Мастер-класс)

**Закирова Г.И.,**
*Әгерҗе шәһәре, гимназия №1*

*Максат*: туган тел һәм әдәбият укытуда проблемалы укыту технологиясенең нәтиҗәлелегенә төшендерү. профессиональ әңгәмә өчен шарт тудыру, укытучыларның профессиональ үсешенә уңай йогынты ясау.

Юлдан барам. Алларымда
Әллә ничә такыр сукмак
Кайсысыннан китәргә соң-
Юл чатында калдым туктап
Бер өн килде: “Вакытыңның
Кадерен бел - торма туктап.
Туры юлга алып чыксын
Үзең салган яңа сукмак”.
Әйдәгез, әнә шул сукмакны бүген бергәләп осталык дәресендә салыйк.
-Кайсы гына чорны алмыйк, мәгариф системасы укытучыга бер үк таләпләр куя. Максатыбыз: белемне мөстәкыйль рәвештә эзләп табарга; тормышта очрый

торган төрле проблемаларны чишкәндә алган белеменнән файдалана белергә сәләтле, иҗади фикерләүче шәхес тәрбияләү.

-Мондый шәхесне тәрбияләргә сәләтле укытучы нинди соң ул (җаваплар)(иҗади фикер йөртүче, үз сукмагын салучы укытучы) "Китап безне кеше итә" мастер-классы кысаларында, мин дә проблемалаы укыту техногоясенә нигезләнгән эш тәҗрибәм белән уртаклашырга телим. Бу технология яңалардан булмаса да, милләттәшебез Мирза Мәхмүтов үз хезмәтләрендә укучыларның интеллектуаль мөмкинлекләре үсешендә бу технологиянең нәтиҗәлелеген раслаган, үз эшемдә мин дә моңа инандым.

Федераль дәүләт стандартлары бездән стандарт булмаган фикер йөртүче, иҗади шәхес тәрбияләүне максат итеп куя. Ә проблемалы укыту технологиясен иҗади эшчәнлекнең башлангычы дип атыйлар. Без дәрестә проблема куеп, укучылардан төрле чишү юлларын таба белергә өйрәтергә тиеш. Дөрес чишү юлларын табу, фикереңне дәлилләп, аның дөреслегенә башкаларны инандыра белә - ул үзе бөек иҗат. Теләсә кайсы фән дәресендә укучы, галим позициясен алып, үзе өчен яңа белемнәр ача белергә өйрәнә. Шулай итеп, укучыга белем бирү нигезендә фәнни иҗат ята. Ул дүрт звеноны үз эченә ала. Барысы да проблемалы ситуация тудырудан башлана: укучы каршылык белән очраша һәм теге яки бу мәсьәләне хәл иткәндә авырлыкларга очрый, гаҗәпләнү, аптырау, гаҗизләнү хисләре кичерә. Проблеманы кую - иҗатның беренче звеносы. Аны чишү юлларын эзләү, гипотезаны дәлилләү этаплары нәтиҗәгә китерә. Проблеманы чишү барышында укучылар яңа белемнәрне үзләштерәләр,мәгълүмат алалар. Проблемалы укыту технологиясен гамәлгә ашыру өчен, иң үткен мәсьәләләрне сайлап алу, укытуның проблема тудыруга корылган моделен төзү, укытучының осталыгы, укучыны активлаштыра алуы кирәк.

*Гамәли эшчәнлек*. Сезнең алдыгызда текстлар ята. Шул текстны укып, мәкаләдә күтәрелгән проблеманы формалаштыру өчен фактлар табыгыз, аннан проблеманы формалаштырыгыз. ( вариантлар тыңлана, уртак бер проблема чыгарыла).

Бүген укучылар китап укымый, компьютер китапны бала тормышыннан кысрыклап чыгара .

-Телчеләр буларак, бу проблеманы ничек чишәсез Нишләргә??(проблеманы чишү юлларын тәкъдим итү). Гипотеза

*Әгәр дә, ...*

*Бәлки...*

*Шулай булса...*кебек сүзләре белән башлана ала(укытучыларның фикерләре тыңлана)

-Хәзер мин сезгә үз фикеремне әйтергә телим. Әгәр дә укучыларны кызыксындырсак, китап белән дуслаштыра алыр идек. Фикерене дәлилләп, сезгә үзем куллана торган бер алым тәкъдим итәм.Мин өләшкән карточкаларда тормышның төрле өлкәләре буенча текстлар бирелгән. Шуларны укып, биремнәрне үтәгәннән соң, яңа өйрәнеләчәк әсәр күзалланырга тиеш. (төркемнәргә биремнәр бирелә) Җаваплар тактага беркетелеп бара.

1. *Текстта нәрсә турында сүз бара?*

Россиядә көчемсез милеккә салымны күп балалы гаиләләр өчен түләү авыр. Дәүләт Думасы депутатлары андый гаиләләрне мөлкәткә салымнан азат итү тәкъдиме турында закон проектын тәкъдим иткән. Депутат Тамара Плетнева фикеренчә, закон проектын кабул иткән очракта миллионнан артык күп балалы гаилә физик затларга каралган милеккә салымнан азат ителәчәк. Закон проектын тормышка ашыруга 6,395 миллиард сумга кадәр акча китәргә мөмкин. Россиядә 1,249 миллионнан артык өч һәм аннан да күбрәк балалы йорт хуҗалыгы санала.(вакытлы матбугаттан) *(сәясәт)*

*2. Төшеп калган сүзне тап.*

Рудольф Нуриев исемендәге халыкара фестиваль – ___________ сәнгате буенча иң эре, Россиядәге иң озын гомерле фестивальләрнең берсе. 1987 елдан башлап ел саен май аенда Муса Җәлил исемендәге татар академия дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә үтә. Театральләштерелгән, сәхнәләштерелгән музыка белән баетылган бию күренешләре - югары сәнгать әсәре, шәхеснең дәвамы, йөрәк тибеше, күңел кайтавазы ул.*(балет)*

3. Г. Әпсәләмов романының батыр каһарманы исеме, рухы чиста, тәне көчле дигәнне аңлата.(*Газинур)*

4. Бу өзек нәрсәне тасвирлый?

............. – яшь бия. Бөтен җире ут янып торган җирән төстә. Аяк-тояклары ак оекбаш кигән кебек ап-ак. Аннары маңгаенда кечкенә генә ак табы бар. Әкияттәге атларныкы кебек. Күзләре мөлдерәмә куе коңгырт. Ә яллары… Ялы озын түгел әле, көяз кызлар чәче кебек кабарып кына тора. Аяклары нәзек кенә.Тик торганда да дерелди. *(байтал)*

5. Ярыш сүзенең синонимнарын тап *(чабыш)*

6. Тукай нинди вакыйганы исенә төшерә?

Мине иртүк уятып, кулыма янчык дәрәҗәсеннән аз гына үткән кечкенә бер капчык тоттырдылар. Мин, шул капчыкны тотып, авыл буенча киттем. Авыл халкы тегеләй дә иртә торучан булса да, бүген бигрәк тә иртә торганнар вә һәр өйдә, һәркемдә көләч йөз, тәмле сүз иде. Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, минем ятим калган мулла баласы икәнемә игътибар, миңа, башка малайларга биргән кеби, конфет, бер-ике перәннек кенә бирмичә, һәр йорт иясе дә буяган күкәй бирәләр иде. Шунлыктан, минем капчыгым буяган күкәйләр илә бик тиз тулып, өйгә дә кайтып кердем. (Г.Тукай "Исемдә калганнар") *(сабантуй)*

7. Сөйләп бирүгә нигезләнгән, катлаулы булмаган вакыйгаларны, күп очракта тормыш-көнкүрешнең бер эпизодын, кеше характерының, психологиясенең бер сыйфатын, чалымын сурәтләнгән кечкенә күләмле эпик әсәр.- *(хикәя)*

(җаваплар тактага беркетелә)

-Бу сүзләрне нәрсә берләштерә? Кызыксындырдымы? Ни өчен? (Төрле темаларга караган сүзләр бер әсәрдә тупланган. Нәрсә турында икән ул? Беләселәре килә.) Нинди әсәр турында сүз бара?(Н. Харисованың "Сәяси хата"). Беренчедән, укучыларны үзбезнең мәктәп укытучысы иҗат иткән хикәя белән кызыксындырдык, икенчедән, нинди зур лексик эш башкарылды, яңа мәгълүмат алынды. Өй эше итеп текстны укырга биргәндә, әсәрнең Г.Ибраһимов язган "Алмачуар" хикәясе белән охшаш һәм аермалы якларын табарга дигән бирем бирелә.

Әлеге хикәяне укымаган булсагыз, үзегезгә дә, укучыларыгызга да укырга тәкъдим итәм.

Димәк, нинди нәтиҗә ясыйбыз?

*Иҗади эш.* Проблемалы укыту – иҗади эшчәнлекнең юл башы дигән идем. Менә сезгә ясалма телефоннар. 2 мин эчендә шушы телефон аша укучыгызга смс хәбәр җибәрегез. Программага кермәгән, соңгы вакытта үзегез яратып укыган бер әдәби әсәрне укучыгызга оста һәм кыска итеп тәкъдим итегез. (иҗади эш)

*Йомгак*. Проблемалы укыту технологиясе – проблема табу гына түгел, ә проблеманы чишүнең иң кулай юлларын табуны күздә тота. Проблема чишү – яңа белем алу ул.

Дәресләрдә проблемалы укыту технологиясен куллану 21 гасырда кирәкме? Сезнең фикерләрне ишетәсем килә. Уңай яклары? Тискәре фикерләр. (тыңлана)

Һич тә күңелем ачылмаслык эчем пошса
Үз-үземне күралмыйча, рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны
Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә:
Хәсрәт соңра, хәсрәт килеп алмаш-алмаш
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса
Хәзер генә сыгылып-сыгылып елаган яшь
Шул вакытта мин кулыма китап алам...

## Кеше язмышы кем кулында?

*(9нчы сыйныфта “Бибинур” фильмы буенча үткәрелгән дәрес эшкәртмәсе)*

**Закирова Роза Ахмедовна,**

**Муллагалиева Халидә Миннесаяфовна**

*татар теле һәм әдәбияты укытучылары,*

*МБОУ “Гимназия №1”, Менделеевск шәһәре*

**Максат:** Әдәбиятның образлы дөньясын кино сәнгате күренеше буларак аңлау, әдәби әсәрнең эстетик ягын кабул итү; татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен якынайту; әдәбиятны тарих, җәмгыять белеме предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру, татар киносына кызыксыну уяту.

**Дәрес формасы:** “Йолдыз сәгате” уены.

**Техник чаралар:** проектор

**Дәрес барышы:**

**I. Оештыру, ориентлашу.**

Хәерле көн, укучылар. Узган дәрестә без сезнең белән "Бибинур" фильмын карадык. Бу кино берегезне дә битараф калдырмады, күңелләрегездә каршылыклы хисләр уятты дигән фикергә килдек. Шуңа күрә без сезнең белән бүген тагын бер тапкыр каралган вакыйгаларга әйләнеп кайтып, бер-беребез белән аралашып алырбыз. Дәресебез үзенчәлекле – уен формасында узачак. Шуңа күрә дә без сезне ике командага бүлдек. Сезнең максат – караганнарны искә төшереп, мөмкин кадәр сорауларга дөрес җавап бирү. Һәр дөрес өчен командага фишкалар бирелә. Дәрес ахырында фишкалар санына карап, җиңүчеләр ачыкланачак. Шулай итеп, уеныбызны башлыйбыз.

**II. Уку мәсьәләсен чишү этабы.**

**1. "Бибинур" фильмы буенча кереш сораулар.**

1.1. Фильм ничәнче елда төшерелгән? (2009)

1.2. Фильмның режиссёры кем? (Юрий Фетинг)

1.3. Өлкән Бибинурны кайсы артист уйный? (Фирдәвес Әхтәмова)

1.4. Руслан Мустафин нинди персонажны уйный? (Мансур)

1.5. Фирдәвес Әхтәмова - нинди театр артисты? (Г. Камал)

1.6. Фильм нинди конкурста ике бүләккә лаек була? (6 халыкара мөселман киносы фестивалендә)

1.7. Фильм нинди киностудиядә төшерелә? (Сабантуй)

1.8. Фильмда Бибинур ролен ничә кеше уйный? (3)

1.9. Фильм нинди әсәргә нигезләнеп төшерелгән? (Аяз Гыйләҗевның "Җомга көн кич белән...")

1.10. Җиһангир ролен кем уйный? (Эрнест Тимерханов)

**2. Бер атналык тормыш.**

2.1. Фильм нинди күренештән башлана? (Бибинурның төшеннән)

2.2. Төшендә Бибинурга Вәли нәрсә бирә? (шырпы)

2.3. Бибинур иртән нәрсә көтүенә очрый? (сарык)

2.4. Мансур туңдырманы ничә сумга сата? (12)

2.5. Бибинур почта аша посылкада малаена нәрсә җибәрергә тели? (кильки, карабодай ярмасы, алма)

2.6. Телеграммага нинди сүзләр яздырырга тели? (җомга көн кич белән үләм, кайт)

2.7. Этнең кушаматы ничек? (Кызылбай)

2.8. Балаларны Ленинградка җибәрмәс өчен, Бибинур печәтле кәгазьне нишләтә? (ашый)

2.9. Бибинур почтага посылка җибәрергә атнаның кайсы көнендә бара? (сишәмбе)

2.10. Җиһангир бөтен җирләрен кемгә калдыра? (Мансурга)

**3. Кем сүзләре?**

3.1.“Шырпы – ут, ут – үлем” (Вәли)

3.2. “Америкага ризык җибәрергә ярамый” (почтальон кыз)

3.3. “Нәрсә, ничәмә еллар буе миңа җиңел булдымы әллә? Мин бит гел синең турында гына уйладым” (Мирзаһит)

3.4. “Барысы да Аллаһ кулында” (Бибинур)

3.5. “Бездырам мин сезне. Барыбер минемчә булачак” (Зөһрә)

3.6. “Бүгеннән башлап бөтен җырләр – Маркиз Карабасныкы” (Җиһангир)

3.7. “Мин барыбер җиңәм. Минем тавышым үзенчәлекле” (Мансур)

3.8. “Шикләнмә, Ленинградта балаларга рәхәт булыр” (Зәмирә)

3.9. “Әти, сиңа кылыч бирәләрме?” (Нәҗип)

3.10. “Син нәрсә инде, Бибинур, Мин бит сугышка китмим” (Габдулла)

**4. “Театр нурга илтә...”**

Ике команда да өчәр минутлык кино буенча сәхнәләштерелгән өзек әзерләргә тиеш иде. Хәзер шуларны карап китәбез.

**5.Финал.**

Фильм төшерелгән киностудия исеменнән, ягъни САБАНТУЙ сүзендәге хәрефләрдән мөмкин кадәр күбрәк сүзләр төзергә кирәк (ата, ана, саба, туй, ант, тай ...)

III. **Рефлексия.**

Укучылар, сезгә фильм ошадымы? Тагын татар фильмнарын карарга теләгегез бармы? Нинди темаларга карыйсыгыз килә?

Әйдәгез, дәрес башында куйган сорауга җавап биреп карыйк әле: чыннан да, кеше язмышы кем кулында соң? (фикерләр тыңланыла)

Уен тәмам. Җиңүчеләр билгеле. Барыгызга да уңышлар телибез!

## <u>“Мин чисталык яратам”</u>

*(Методик эшкәртмә)*

**Зарипова Ф. Н.,**
*Менделеевск муниципаль районы*
*3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Максат**:

1. “Мин чисталык яратам” темасы буенча өйрәнелгән лексикага нигезләнеп, кеше әгъзалары исемнәренең тартым белән төрләнешен ныгыту; авырый, авырта, авыртмый фигыльләренең сөйләмдә кулланышын камилләштерү;
2. Балаларның танып белү активлыгын үстерү, укучыларның диалогик , монологик сөйләмен үстерү.

3. Укучыларда чисталык, пөхтәлек кебек сыйфатлар тәрбияләү, татарча сөйләмне аңлауга кызыксыну уяту.

Җиһазлау: Р.З. Хәйдәрова, 2 сыйныф дәреслеге, методик кулланма, компьютер, проектор , Белмәмеш рәсеме, кулдан ясалган градусник, биремнәр салынган конверт, Белмәмеш эшләпәсе, медиклар башлыгы.

**Дәрес тибы : кабатлау дәресе.**

**Дәрес барышы:**

I. Оештыру өлеше.

Исәнләшү. Уңай халәт тудыру.

Кизү укучының рапортын тыңлау.

- Бүген нинди число?
- Атнаның көне нинди?
- Һава торышы нинди?

-Дәрестә кем юк?

II. Актуальләштерү.

1 слайд. Фонетик күнегү. Максат: авазларны, сүзләрне дөрес итеп әйтү.

| | |
|---|---|
| [ә],[ө], [ү], [и], [э̆] | [а°], [о̆], [у], [ы̆] |
| сөлге [сөлгé ] | сабын [са°бы̆́н] |
| пөхтә [ пөхтә̆́ ] | авырый [а°wы̆ры̆́й] |
| бирде [бирдә̆́] | тамак [та°мáк,] |

- Ни өчен сүзләрне ике баганага бүлдем?
- Нәтиҗә: татар телендә сүзләр я нечкә, я калын булалар.

1) Өй эшен тикшерү.

Өй эше – сүзләр белән җөмләләр төзү иде.

- Хәзер җөмләләрне тикшерербез, игътибарлы булыгыз. Җөмләләрне кем укырга тели?
- Көтелгән җаваплар.(Алсуга зәңгәр сөлге кирәк. Катя Илшатка сабын бирде. Сөт файдалы.һ.б.)
- Балалар, кем өй эшен яхшы эшләгән?

Нәтиҗә ясау.

III. Кабатлау.

1. Слайд №1-8, бирем “Пирамиданы җый!”

- Балалар, бүген безгә кунакка Белмәмеш килде. Бирем алып килде. Бергәләп укыйк әле.

Укучылар кычкырып укыйлар.

- Пирамиданы җый !
- Пирамиданы җыйсак, дәреснең темасын белербез. Уйлыйк әле,

нинди сүз килеп чыкты?

- Гигиена.
- Нәрсә ул гигиена? Ул безгә ни өчен кирәк?

Көтелгән җаваплар ( гигиена ул - чисталык)

-Димәк, бүгенге дәреснең темасы нинди?

- Көтелгән җавап: “Мин чисталык яратам.”Слайд №9.

-Дөрес. Бүген гигиена, чисталык турында сөйләшербез,тема буенча сүзләрне, сүзтезмәләрне кабатларбыз, бер- беребезгә сораулар бирербез, җавапларны тыңларбыз, җөмләләр, диалоглар төзербез.

-Балалар, хәзер “Кизү укучы” уенын уйнарга әзерләнербез. Кизү укучылар сыйныфташларыгызның тән әгъзалары чисталыгын тикшерерләр.

-Әйдәгез тән әгъзаларының исемнәрен искә төшерик әле.

3) Слайд №10-22. Тән әгъзалары рәсемнәре (баш, чәч, бит, борын, күз, ирен, колак, авыз, муен, кул, бармак, аяк)

- Бу – нәрсә?
- Бу – баш
- Бу кемнең башы?
- Бу минем баш + ым.
- Бу- нәрсә ?
- Бу күз.
- Бу кемнең күзе?
- Бу синең күз + ең. Һ.б.

Слайд №23. Укучылар сүзләрне күмәк кабатлыйлар һәм алдагы биремне башкарганда файдаланалар.

| | | |
|---|---|---|
| Минем | Синең | Аның |
| Башым | Күзең | Муены |
| Чәчем | Иренең | Кулы |
| Битем | Колагың | Бармагы |
| Борыным | Авызың | Аягы |

- Кизү укучы булып уйнаганда, дусларыгызга нинди сораулар бирерсез?

Көтелгән җаваплар: (Синең кулың чистамы ? Синең кульяулыгың бармы? һ.б.

4) Парларда эш. Уен “Кизү укучы”.

1-3 парны тыңлау.

5) - Сез бүген барыгыз да чиста һәм матур. Әйдәгез бер-беребезгә комплимент әйтик.

Комплимент әйтү (чылбыр рәвешендә)

Көтелгән җаваплар.

- Коля, синең кулың чиста.Син яхшы малай.
- Катя, синең бантигың матур! Син пөхтә кыз. һ.б.

6) Төркемнәрдә эш ( Балаларны өч төркемгә бүлү)

Максат. Чиста, пөхтә булу өчен безгә нинди әйберләр кирәк? соравына җавап алу.

- Кайсы төркем дөрес һәм тизрәк эшләр?

Һәр төркемгә конверт һәм кәгазь бите таратыла. Конверт эчендә сабын, сөлге, теш пастасы, теш щёткасы, тарак, курчак,туп, китап, дәфтәр рәсемнәре. Гигиена әйберләрен сайлап алырга һәм кәгазь битенә ябыштырырга. Кәгазь битендә җөмлә калыбы бирелгән: Чиста, пөхтә булу өчен безгә ... кирәк.

7). Җавапларны тыңлау. Нәтиҗә. Үзбәя.

8).Дәреслек белән эш. Дәреслекнең 70 нче битен ачыгыз, 4 нче күнегүне табыгыз.

Максат. Буталганны төзәтү.

- Әйдәгез Белмәмешкә булышыйк.

Җөмләләрне дөрес итеп укырга кирәк.

Җавапланы тыңлау. Үзбәя.

9**)** Слайд №24. Физминут.

Без инде хәзер зурлар.
Күп эшли безнең куллар.
Без идән дә юабыз.
Без керләр дә уабыз.
Гөлләргә су сибәбез.
Без бераз арыдык,
Ял итәргә уйладык

Башны иябез алга,
Ә аннары- артка.
Уңга-сулга борабыз.
Күзләрне йомабыз, ачабыз,
Аннан карап торабыз.
Кулларны биетәбез.
Аякларны сикертәбез,
Күңелле ял итәбез.

– Балалар, ни өчен Белмәмеш безнең белән зарядка ясамады? Аңа ни булган?
- Ул авырый. (Слайд №25 Белмәмеш рәсеме)

10.Слайд № 26-27.Ә хәзер шундый бирем. Дөрес тәрҗемәне тап**.**

Максат. Бу сүзләр ситуатив күнегү өчен кирәк булыр.

Болеет (Нишли? Что делает?)

А) авырта Б ) авырды В) авырый

Болит(Нишли? Что делает?)

А) авырды Б ) авыртмый В) авырта

Измерь температуру (Нишлә? Что сделай?)

А) температураңны кара Б) температураңны әйт В) температураңны үлчә

IV. 1 Слайд №28. Ситуатив күнегү. Белмәмеш авырый.

Как скажешь о том,что:
- Незнайка заболел
- у него болит голова
- Незнайка, измерь температуру?

2.Белмәмеш табибка бара**.**

Какой диалог произойдёт между Незнайкой и доктором?

3. Слайд №29 . Парларда эш. “Табибта” темасы буенча сөйләшү.

“Табибта”

-Исәнмесез. Керергә ярыймы?
- Исәнмесез. Утыр. Кай җиреӊ авырта?
- Башым, тамагым авырта.
- Температураң бармы?
- 39 градус
- Сиңа салкын тигән. Дару эч.
- Рәхмәт. Сау булыгыз.

1-2 парны тыңлау

3. Безнең Белмәмеш сәламәтләнде. Как он скажет, что у него не болитголова, горло?
- Давайте вспомним**,** какие окончания помогают нам сказать ,что действия не происходят.

Көтелгән җавап: -мый, -ми кушымчалары. (Слайд №30)

Ситуатив күнегүне башкару. Көтелгән җаваплар.(Минем башым авыртмый. Минем тамагым авыртмый.)

4. Дәреслек белән эш. 9 нчы күнегү, 71 нче бит

Хәзер дәреслекләрне ачабыз. Биремне укыйбыз.
Как скажешь о том, что у тебя не болит рука,( нога, палец,ухо )?
5. Хәзер эш дәфтәрәләрен ачабыз, 43 нче биттә 9 нчы күнегүне табабыз. Биремне укыйбыз. Бу күнегүдә табиб киңәшләре язылган. Әйдәгез аларны Белмәмешкә укыйк. Белмәмеш кабат авырмасын.
Көтелгән җаваплар:Белмәмеш, зарядка яса! Йөгер!Саф һавада йөр! Һ.б
Слайд №31. Белмәмеш укучылар белән саубуллаша.
V. Тест. Кушымта № 3
VI.Рефлексив йомгаклау.
1.Әңгәмә.
Балалар, без бүген нинди теманы өйрәндек?
- Нәрсәне искә төшердек?
- Грамматикадан нәрсә кабатладык?
2.Гомуми бәяне чыгару.
3. Өй эшен бирү : №9, 43 нче бит (эш дәфтәре): бирем буенча рәсем ясарга Һәм Белмәмешкә чыныгып өчен киңәшләр язарга

## “Татарстан сувенирлары”

(Сыйныфтан тыш чара)

**Заһидуллина Э.Г.**

*Менделеевск муниципаль районы*

*3нче урта гомуми белем бирү мәктәбе,*

*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

***Максат:*** Һәрьяклы үсешкә ия шәхес формалаштыру, республикабызда яшәүче халыкларның милли-мәдәни мирасын яшь буынга сеңдерү; мәрхәмәтле күршелек мөнәсәбәтләре булдыру һәм тәрбияләү.

***Бурычлар:***

1. Республикабызда яшәүче төрле милләт халыкларының тарихын өйрәнүгә кызыксыну уяту,гореф-гадәтләренә игътибарлы булу.
2. Милли кыйммәтләргә, этник үзенчәлекләргә карата хөрмәт хисе тәрбияләү
3. Укучыларга, төрле булсалар да, һәрберсенең шәхес булуларын төшендерү

**Җиһазлау:** мультимедиа-проектор, презентация; эшне башкару өчен төрле кораллар, рәсемнәр, тәлинкәләр.

*Чараның барышы:*

1. Оештыру этабы

1.1.Сәламләшү

Укучыларга ишектән кергәндә үк төсле кәгазләр бирәм һәм өстәл артына шул карточкалар буенча урнаштырам . 1өстәл-кызыл, 2- зәңгәр, 3-яшел, 4-сары, 5- кызгылт.

-Исәнмесез, укучылар. Бүген без сезнең белән сыйныфтан тыш чарада катнашабыз. Без сезнең белән шул кадәр төрлеләр: озын, кыска буйлылар, ябык, кечкенә, сары, кара, җирән чәчле, зәңгәр, кара, коңгырт күзле һ.б. Милләтләребез, дини карашларыбыз төрле. Ләкин без барыбыз да Җир дип аталган уртак планетада яшибез.

1.2. Темага кертү. Материаллар һәм кораллар.

(Чит ил кунаклары)

-Укучылар, карагыз әле безгә кемнәр килгән. (Кунаклар белән сәламләшкәннән соң аларны урнаштырам) Ә сезнең белән эшебезне дәвам итик.

-Ничек уйлыйсыз, безнең чарабызның темасы нинди булыр? (укучыларның җаваплары)

-Бик дөрес, әлбәттә “Без бергә”. Безнең 5 команда барлыкка килде. Ә хәзер әйдәгез һәр команда кулга-кул тотынып “Без бергә!” дип әйтик әле. Яхшы. Менә хәзер командаларның нинди тату икәнлеге күренә, чөнки эшнең уңышы сезнең бердәмлектән тора.

-Ничек уйлыйсыз, республикабызда нинди милләт вәкилләре яши? (укучыларның җаваплары)

- Бик яхшы. Дөрес, Республика халкын өлге итеп куярлык. Гомер-гомергә республикабызда татарлар, руслар, марилар, удмуртлар һәм башка милләт вәкилләре якын дуслар, туганнар булып бер-берләренә ярдәмләшеп яшиләр.

-Укучылар ничек уйлыйсыз республикабызга ел саен кунакка, сәяхәткә, экскурсияләргә күпме кеше килә ?

(укучыларның җаваплары)

-Әйе, бик дөрес. Чөнки Мәскәү һәм һәм Петербург шәһәрләреннән соң илебездә 3 нче мактаулы урында республикабызның башкаласы Казан шәһәре тора. 2017нче елда Казанда 2 млн. 750 мең турист булган. Аларның 200 меңе Германия, Төркия, Чили, Кытайдан.

Төп этап.

2.1. Сувенир төрләре.

- Төрле җирләргә сәяхәт иткәндә без истәлеккә нинди дә булса сувенирлар алып кайтабыз. Мәсәлән магнитлар, төрле эшләнмәләр, шәһәр рәсеме төшкән төрле декоратив тәлинкәләр.

-Без дә бүген башкалабыз, шәһәребез күренешләре сурәтләнгән шундый тәлинкәнең макетын ясап карарбыз. Әйтегез әле чит ил кунаклары республикабызда кайларда булалар, аларны нинди истәлекле урыннар кызыксындырыр икән? Ничек уйлыйсыз? (укучыларның җаваплары)

-Бик яхшы. Республикабызны ничек әйбәт беләсез икән? Казанның иң популяр урыннарын әйтегез әле миңа? (укучыларның җаваплары)

- Ә Бауман , Тукай, Сәйдәшев, Толстой урамнары кемнәр хөрмәтенә аталган? Кем ул Бауман, Сәйдәшев, кем белә? (Бауман-революционер, Сәйдәшев - композитор, Тукай, Толстой -язучылар)

2.2. Декупаж техникасы үзенчәлекләре

-Яхшы. Хәзер без сезнең белән «Татарстан Сувенирлары» проекты буенча декоратив тәлинкә макеты ясап карарбыз. Ә эшне декупаж техникасы белән башкарырбыз. Декупаж, ә нәрсә соң ул? (презентациянең слайдлары буенча техника белән таныштырам.)

-Укучылар, аңлашылдымы? Сезнең өстәлләрегездә Татарстан, Казан күренешләрен сурәтләүче картиналар, тәлинкәләр һәм эш кирәк –яраклары ята. Хәзер командагыз белән киңәшеп, нинди күренешләрне, нинди эзлеклелектә тәлинкәләргә урнаштыруны хәл итәрсез. Эшләрне шулай ук рәсем өстәп ясау һәм язу белән дә тулыландырырга мөмкин.(чиста тәлинкәдә эш тәртибен күрсәтәм)

2.3. Эшне этаплап башкару.

- Шулай итеп, укучылар, эшне башлыйбыз. (араларында йөреп аңлатам, булышам) Эшне тәмамлаган командалар сингапур технологиясе буенча феервейрк ясый.

Укучыларның мөстәкыйль эшләүләре.

2. Йомгаклау этабы.

3.1. Эшләнмәләрдән күргәзмә ясау.

-Сез нинди булдыклылар. Нинди фантазия. Тәлинкәләр берсеннән-берсе матур килеп чыкты. Чит ил кунакларына да истәлеккә Татарстан турында берәр сувенир бүләк итик. (кунакларга берничә тәлинкә бүләк итәбез һәм озатабыз)

3.2. Йомгак ясау.

-Балалар чарабыз азагына якынлашып килә. Әйтегез әле, үзегез өчен нинди яңа белемнәр алдыгыз?

(укучыларның җаваплары)

-Укучылар миңа бүген сезнең белән эшләү бик күңелле булды. Сыйныфтан чыкканда “парковка”га стикерларыгызны беркетеп калдырыгыз. Кызыл - чара ошады, бар нәрсә дә аңлашылды, яшел - чара ошады, әмма бар нәрсә дә аңлашылып бетмәде, сары - чара ошамады

- Рәхмәт. Сау булыгыз.

## <u>«Фигыль. Нишли? Нишлиләр? сорауларына җавап бирүче фигыльләр»</u>

**Заһретдинова Әлфия Назиф кызы,**
*Әгерҗе шәһәре*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*4 нче санлы урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Методик эшкәртмә рус мәктәпләрендәге татар төркемендә укучы 2 нче сыйныф укучылары өчен төзелде. 1 нче сыйныфта укучыларга “Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр” темасын өйрәнгәндә, фигыль сүз төркеме турында төшенчә бирелде. 2 нче сыйныфта “Сүз” бүлеге башында да сүзләрнең эш-хәрәкәтне белдерү мөмкинлеге турында кабатлау күнегүләре үтәлде. Бу дәрестә әлеге сүзләр “Фигыль” төшенчәсе астында өйрәнелә башлый. Дәрес системалы-эшчәнлекле якын килүгә нигезләнә.

Кушымтада дәрес өчен кирәкле дидактик материаллар, өстәмә ресурслар бирелә. Дәреснең презентациясен дә җибәрәм.

| | |
|---|---|
| **Тема** | Фигыль. Нишли? нишлиләр? сорауларына җавап бирүче фигыльләр. |
| **Дәрес тибы** | Яңа уку материалы үзләштерү дәресе. |
| **Эшчәнлек формалары** | Әңгәмә, дәреслек белән эш, парларда һәм төркемнәрдә эш. |
| **Максат** | Фигыль сүз төркеме белән танышуны дәвам итү, фигыль төшенчәсен үзләштерү. |
| **Бурычлар** | Нишли? нишлиләр? сораулары аша фигыльне танырга өйрәнү. |

| | |
|---|---|
| | Фигыльне сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллану күнекмәләрен үстерү, укучыларның фикерләү активлыгын, сөйләм телен баету эшен дәвам итү.<br>Табигатькә сак караш тәрбияләү.<br>Укучыларда УУГ (танып белү, регулятив, коммуникатив, шәхескә кагылышлы) формалаштыру. |
| **Универсаль уку гамәлләре** | *Шәхескә кагылышлы УУГ:*<br>-табигатькә сак караш,<br>*Регулятив УУГ:*<br>- дөрес һәм ялгыш эшләнгән эшләрне аера белү,<br>- үз эшчәнлегеңне бәяләү.<br>*Танып белү УУГ:*<br>- объектларны классификацияләү, чагыштыру.<br>- сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен табу, нәтиҗә чыгару.<br>*Коммуникатив УУГ:*<br>- төркемнәрдә һәм парларда эшли белү,<br>- иптәшеңне тыңлап, фикереңне тулы һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирә белү; |
| **Төп һәм өстәмә ресурслар** | Куллану өчен әсбаплар:<br>1. Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, Е.А. Панова. “Татар теле. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 2нче сыйныфы өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен)”. Казан, “Мәгариф - Вакыт”, 2013.<br>2. Үзбәя өчен карточкалар, фигыльләр язылган карточкалар, тест биремнәре, төркемдә иҗади эш өчен кәгазь битләре.<br>Техник чаралар:компьютер, экран, проектор, “Фигыль” темасы буенча презентация. |
| **Предметара бәйләнеш** | Әдәби уку, татар халык фольклоры. |
| **Төп төшенчәләр** | Фигыль, нишли? нишлиләр? сораулары. |
| **Эшчәнлекне оештыру ысуллары** | Фронталь, мөстәкыйль, парларда, төркемнәрдә. |
| **Укыту методлары** | Проблемалы укыту методы, практик метод, эвристик метод, рефлексив метод, уен методы. |
| **Укыту алымнары** | Проблемалы сорау кую, модельләштерү, дәреслек белән эш, сорауларга җавап бирү, билге һәм чагыштыруларны эзләп табу, нәтиҗә ясау, хезмәттәшлек, иҗат итү. |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Көтелгән нәтиҗә** |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| **1 этап. Оештыру өлеше.**<br>Максат: уңай психологик халәт тудыру. | *-Исәнмесез, укучылар!*<br>*-Хәлләрегез ничек?*<br>*Балалар, мин сезгә уңышлар телим. Дәрестә игътибарлы булыгыз, бер-берегезгә ярдәм итегез, актив катнашыгыз.* | *-Исәнмесез!*<br>*-Әйбәт, рәхмәт!* | Шәхси УУГ: мәктәпкә карата уңай мөнәсәбәт. |
| **2 этап. Актуаль ләштерү, эшкә кызыксыну уяту.**<br>Максат: дәрес эшчәнлегенә керешеп китү ихтыяҗы булдыру өчен шартлар тудыру, дәреснең темасын ачыклау. | *Әйдәгез әле, бергәләшеп кроссворд чишеп алыйк.*<br>1 слайдта кроссворд ачыла.<br>*1. Әрекмәндәй зур колак,*<br>*Аяклары бер колач,*<br>*Борыны җиргә тигән,*<br>*Килгән ул ерак илдән.*<br>*2. Кош түгел оча,*<br>*Ябалактан курка,*<br>*Чикләвекне ярата,*<br>*Сызгырса, урманны яңгырата.*<br>*3. Бакчамда бер кошым бар,*<br>*Кычкыра гел кар да кар.*<br>*4. Тәне тулы тәңкәсе,*<br>*Елга аның әнкәсе.*<br>*5. Нечкә билле,*<br>*Көлтә койрыклы.*<br>ф и л<br>т и е н<br>к а р г а<br>б а л ы к<br>т ө л к е<br>ь | Көтелгән җаваплар (фронталь):<br>*-Фил*<br>*-Тиен*<br>*-Карга*<br>*-Балык*<br>*-Төлке* | Танып-белү УУГ:<br>-билге-нәтиҗә бәйләнешен табу, нәтиҗә чыгару. |
| **3 этап. Уку мәсьәләсен кую.**<br>Максат: яңа белемнәр кабул итүне оештыру һәм үзләштерүгә юнәлеш бирү, дәреснең максатын билгели белү. | *-Укучылар, вертикаль баганада нинди сүз килеп чыкты?*<br>*-Димәк, бүгенге дәрестә без нәрсә өйрәнербез?*<br>*-Укучылар, игътибар итегез, фигыль сүзе нечкәлек хәрефе белән языла.*<br>1 слайдта "Нәрсә ул фигыль?" соравы ачыла.<br>*-Димәк без бүгенге дәрестә нинди сорауга җавап эзләрбез?*<br>*-Дөрес.* (Тактага "Фигыль" дигән карточка эленә). | *-Фигыль*<br>*-Фигыльне өйрәнербез.*<br>*-"Нәрсә ул фигыль?" соравына җавап эзләрбез.* | Танып-белү УУГ: -<br>-проблеманы кую һәм формалаштыру.<br>Коммуникатив УУГ: -<br>-коллектив фикер алышуда катнашу.<br>Регулятив УУГ: |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | -дәреснең максатын билгеләү. |
| **4 этап. Уку мәсьәләсен чишү.**<br>Максат: килеп туган уку мәсьәләсен үзләштерү, укучыларның алган белемнәрен практик кулланырга мөмкинлек тудыру. | **1 нче өлеш. Кроссвордтагы сүзләрне анализлау аша фигыль сүз төркеменең моделен төзү.**<br>*-Укучылар, кроссвордтагы сүзләргә игътибар итик әле. Мин сезгә сораулар бирермен, ә сез парларда фикер алышып җавап бирегез.*<br><br>*-Фил нишли?*<br>*-Тиен нишли?*<br>*-Карга нишли?*<br>*-Балык нишли?*<br>*-Төлке нишли?*<br><br>2 слайдта көтелгән җаваплар ачыла.<br>*-Балалар,сез дөрес җавап биргәнсезме? Карап чыгыгыз әле.*<br>*-Сез әйткән сүзләр нәрсәне белдерә? Парларда уйлап җавап бирегез.*<br>*-Дөрес.* (Тактага “Эш-хәрәкәт”дигән карточка эленә).<br><br>*-Ә алар нинди сорауга җавап бирә?*<br>*-Дөрес.* (Тактага “Нишли?”дигән карточка эленә).<br><br>*-Фил ашый. Ә филләр нишлиләр?*<br>*-Тиеннәр нишлиләр?*<br>*-Каргалар нишлиләр?*<br>*-Балыклар нишлиләр?*<br>*-Төлкеләр нишлиләр?*<br><br>*Тикшерәбез:* 2 слайдта көтелгән җаваплар ачыла.<br>*-Дөрес әйткәнсезме?* | Көтелгән җаваплар: (парларда)<br>*-Фил ашый.*<br>*-Тиен сикерә.*<br>*-Карга оча.*<br>*-Балык йөзә.*<br>*-Төлке йөгерә.*<br><br>*-Әйе, дөрес җавап биргәнбез.*<br><br>*-Бу сүзләр эшне, хәрәкәтне белдерә.*<br><br>*-Алар нишли? соравына җавап бирәләр.*<br><br>Көтелгән җаваплар: (парларда)<br>*-Филләр ашыйлар.* | Танып-белү УУГ:<br>-модельләштерү,<br>-объектларны классификацияләү,<br>нәтиҗә чыгару.<br><br>Коммуникатив УУГ:<br>-парларда эшли белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -*Бу баганадагы сүзләр нинди сорауга җавап бирә?*<br>-*Дөрес.* (Тактага “Нишлиләр?”дигән карточка эленә).<br><br>-*Укучылар, схемага игътибар итегез. Хәзер сез* ***нәрсә ул фигыль*** *соравына җавап бирә аласызмы? Парларда фикер алышыгыз да җавап бирегез.*<br><br>-*Укучылар, бу ике сорау бер-берсеннән ничек аерыла? Парларда фикер алышыгыз да җавап бирегез.*<br><br>-*Дөрес.* (Тактага “1 предметның эш-хәрәкәте” һәм “берничә предметның эш-хәрәкәте “ дигән карточкалар эленә).<br><br>-*Ни өчен ашыйлар сүзендә –лар кушымчасы, ә калган сүзләрдә –ләр кушымчасы?*<br><br>Сорау-җавап барышында тактада карточкалардан фигыль сүз төркеменең шундый моделе төзелә:<br>**Фигыль**<br>↓<br>Эш-хәрәкәт<br>↙ ↘<br>Нишли? Нишлиләр?<br>↓ ↓<br>1 предметның эш-хәрәкәте 2 яки берничә предметның эш-хәрәкәте<br>↓ ↓<br>оча | -*Тиеннәр сикерәләр.*<br>-*Каргалар очалар.*<br>-*Балыклар йөзәләр.*<br>-*Төлкеләр йөгерәләр.*<br><br>-*Әйе, дөрес әйткәнбез.*<br><br>-*Алар нишлиләр? соравына җавап бирәләр.*<br><br>-*Фигыль эш-хәрәкәтне белдерә, нишли? нишлиләр? сорауларына җавап бирә.*<br><br>-*Нишли? соравы 1 предметның эш-хәрәкәтен белдерә, ә нишлиләр? соравы 2 яки берничә предметның эш-хәрәкәтен белдерә.* | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | очалар | *-Нишлиләр соравында -ләр кушымчасы бар.*<br><br>*-Ашый сүзе калын, ә калган сүзләр нечкә.* | |
| | **2 нче өлеш. Модельне дәреслектәге кагыйдә белән чагыштыру.**<br>*-Укучылар, дәреслекнең 84-85 нче битләрендә бер кагыйдә бар. Әйдәгез әле, шуларны укып чыгыйк.*<br>*-Дөрес уйлаганбызмы?*<br><br>*-Сезнең алда **сары** кәгазьләр ята. Анда без ясаган модель. Бу сезгә бүләк, аны югалтмагыз, ул әле сезгә кирәк булыр. Китап эченә тыгып куегыз.* | Кагыйдәне 2 укучы бүлеп укый.<br><br>*-Әйе, дөрес уйлаганбыз.* | Регулятив УУГ<br>-дәреслектә ориентлаша белү. |
| | **3 нче өлеш.**<br>*-Хәзер бергәләшеп бер бирем эшлибез. Сезнең алда фигыль язылган **шәмәхә** карточка ята. Сез сүзне кычкырып укырга, аңа сорау куярга һәм, такта янына чыгып, нишли? яки нишлиләр?соравы астына беркетергә тиеш.*<br><br>Укучыларга җырлый, тыңлый, уйный, пешерә, сөйли, карый, укыйлар, кисәләр, тегәләр, эшлиләр, киләләр, юалар | Укучылар эшне инструкция буенча башкаралар | Шәхси УУГ:<br>-укучының башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру.<br><br>Танып-белү УУГ:<br>-сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен табу, нәтиҗә чыгару, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сүзләре язылган карточкалар таратыла.<br><br>-*Укучылар, хаталар бармы?*<br><br>3 слайдта үзбәя өчен критерийлар ачыла.<br>-*Укучылар, сезнең алдыгызда ал төстә кәгазьләр бар. Кем дөрес эшләгән 1 саны янына түгәрәк ясагыз, ә кем ялгышкан, өчпочмак ясагыз.*<br><br>-*Әйдәгез әле, беренче баганадагы фигыльләрне кычкырып укыйк.*<br>-*Димәк, алар нинди сорауга җавап бирә?*<br>-*2 нче баганадагы фигыльләрне укыгыз.*<br>-*Алар нинди сорауга җавап бирә?* | (мөстәкыйль).<br><br>Хаталар булса төзәтелә, кемнең ялгышканы ачыклана.<br>3 нче слайдта.<br>Үзбәя. Үзбәя өчен критерий:<br>○ дөрес эшләдем<br>△ дөрес эшләмәдем<br><br>Хор белән укыйлар.<br><br>-*Нишли?*<br>Хор белән укыйлар.<br>-*Нишлиләр?* | -объектларны чагыштыру.<br><br>Регулятив УУГ:<br>-көтелгән нәтиҗәдән аермалар килеп чыкканда кирәкле төзәтмәләр кертү,<br>-үз эшчәнлегеңне бәяләү. |
| | **Динамик пауза.**<br>-*Укучылар, ә хәзер бер уен уйныйбыз. Мин сезгә җөмләләр әйтәм. Әгәр җөмлә дөрес булса, сез аны кабатлап әйтәсез, шул ук вакытта хәрәкәтләр белән күрсәтәсез.*<br>-*Очалар, очалар, казлар очалар.*<br>-*Очалар, очалар, аюлар очалар.*<br>-*Йөзәләр, йөзәләр, балыклар йөзәләр.*<br>-*Йөзәләр, йөзәләр, тавыклар йөзәләр.*<br>-*Сикерәләр, сикерәләр, агачлар сикерәләр.* | Укучылар дөрес җөмләләрне кабатлап хәрәкәтләнәләр. | Шәхси УУГ:<br>-татар милли уеннары белән кызыксыну. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -*Сикерәләр, сикерәләр, куяннар сикерәләр.*<br>-*Йөгерәләр, йөгерәләр, китаплар йөгерәләр.*<br>-*Йөгерәләр, йөгерәләр, балалар йөгерәләр.* | | |
| | **4 нче өлеш. Иҗади эш (төркемнәрдә).**<br>-*Укучылар, без хәзер төркемнәрдә эшләрбез. Сезнең өстәлләрдә **ак кәгазь** битләре бар. Анда бер сүз язылган (Куян, Песнәк, Чыршы). Шул сүзләрне кычкырып укыгыз әле.*<br><br>-*Хәзер һәр төркем үзенең темасы буенча бер җөмлә яза, җөмләгездә фигыль кулланырга онытмагыз. Сезгә 1 минут вакыт бирелә.*<br><br>-*Җөмләгезне укыгыз. (Укыячак баланы укытучы билгели).*<br>-*Фигыльне әйтегез.*<br><br>-*Хәзер дәфтәр битләрен алмашыгыз, алдагы җөмләне дәвам итеп, тагын 1 җөмлә языгыз.*<br><br>-*Җөмләгезне укыгыз.*<br>-*Фигыльне әйтегез.*<br><br>-*Тагын алмашыгыз, дәвам итеп, 1 җөмлә языгыз.*<br>-*Җөмләгезне укыгыз.*<br>-*Фигыльне әйтегез.*<br>-*Тагын алмашыгыз.*<br><br>-*Менә хәзер үзегез яза башлаган эш кире урынына әйләнеп кайтты. Нинди текст килеп чыкты микән, таныштырып үтегз.* | Һәр төркем үз сүзен кычкырып укый.<br><br>Укучылар, киңәшеп, 1 җөмлә язалар.<br><br>Җөмләне 1 укучы кычкырып укый.<br><br>Төркемнәр дәфтәр битләрен алмашалар, алдагы җөмләне дәвам итеп, тагын 1 җөмлә язалар, аның белән таныштыра лар | Шәхси УУГ:<br>-табигатькә сак караш.<br>Танып-белү УУГ:<br>-фикер йөртүнең логик чылбырын төзү.<br><br>Коммуникатив УУГ:<br>-төркемнәрдә эшли белү,<br>-башкаларның сөйләмен ишетеп һәм тыңлап, фикереңне тулы һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирә белү,<br>-үз фикерләреңә ышандыра белү.<br><br>Регулятив УУГ:<br>- күтелгән эталоннан аермалар килеп чыкканда кирәкле төзәтмәләр кертү, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -*Игътибар белән тыңлагыз, кирәк булса, төзәтмәләр кертерсез.*<br>-*Булдырдыгыз, балалар, сез бергәләшеп <u>куян, песнәк, чыршы</u> турында бик матур хикәяләр яздыгыз.*<br><br>-*Әйтегез әле, ни өчен мин сезгә шундый темалар бирдем?*<br>4 слайдта Экология елының эмблемасы ачыла.<br><br>5 слайдта үзбәя өчен критерийлар ачыла.<br>-*Хәзер ал кәгазь битләренә үзегезгә бәя куегыз.* | Тагын 1 тапкыр алмашалар, 1 җөмлә язалар, таныштыралар.<br><br>Шуннан соң гына кәгазь бите үз төркеменә әйләнеп кайта.<br><br>1 укучы килеп чыккан текстны кычкырып укый, кирәк булса, төзәтмәләр кертәләр.<br><br>-*Быел Россиядә Экология елы.*<br><br>5 нче слайдта.<br>Үзбәя. Үзбәя өчен критерий:<br>○ - актив эшләдем | -үз эшчәнлегеңне бәяләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | □ бик актив булмадым, ләкин эшкә катнаштым<br>△ - эшләмәдем, тыңлап кына утырдым. | |
| **5 этап. Өй эше бирү**<br>Максат: өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын аңлату. | *Өй эше:* 6 слайдта.<br>*1). 128 нче күнегү.*<br>*2).* 128 күнегүдәге уенны дәвам итәргә.*<br>*3).* Дәрестә үзегез яза башлаган бер хикәяне дәвам итәргә (“Куян”, “Песнәк”, “Чыршы”).* | | Регулятив УУГ:<br>-үз эшчәнлегең белән идарә итү, өй эшен сайлаганда дөрес карар кабул итү белү. |
| | **5 нче өлеш. Фигыль буенча тест эшләү.**<br>-*Укучылар, бүгенге теманы ничек аңладыгыз икән, тикшереп карыйк әле.*<br>Тест биремнәре.<br>1. Фигыль нәрсәне белдерә?<br>а) предметны<br>б) билгене<br>в) эш-хәрәкәтне<br>2. Фигыль нинди сорауларга жавап бирә?<br>а) кем? нәрсә?<br>б) нишли? нишлиләр?<br>в) нинди? кайсы?<br>3. Кайсы рәттәге сүзләр фигыльләр?<br>а) утыра, уйлый, сөйли<br>б) зәңгәр, караңгы, ак<br>в) китап, дәфтәр, өстәл.<br>4. Нокталар урынына тиешле кушымчаны куй.<br>Укучылар дәрестә укый... һәм сөйли... .<br>5. Жырлый фигыле белән 4-5 сүздән торган жөмлә төзе. (алдынгы укучылар өчен) | Укучылар тест биремнәрен мөстәкыйль башкаралар.<br><br>Үз эшләрен тикшерәләр | Танып-белү УУГ:<br>-кирәкле мәгълүматны аерып ала белү.<br><br>Регулятив УУГ:<br>-дөрес һәм ялгыш эшләнгән эшне аера белү,<br>-үз эшчәнлегенне бәяләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -*Хәзер җавапларны тикшерәбез.* 7 слайдта җаваплар чыга:<br>1. эш-хәрәкәтне<br>2. нишли? нишлиләр?<br>3. утыра, уйлый, сөйли<br>4. көләләр<br>5 нче биремне укытучы тикшерә. Дөрес җөмлә өчен укытучы ○ тамгасы куя. | һәм бәялиләр.<br>8 нче слайдта.<br>Үзбәя. Үзбәя өчен критерий:<br>○ - хаталар юк<br>-□ 1 хата бар<br>-△ яки күбрәк хата бар. | |
| **6 этап. Рефлексия. Уку эшчәнлегенә нәтиҗә.**<br>**Максат:** дәрестәге эшчәнлекне анализлау, белемнәрне бәяләү; дәрестә алган белемнәрнең әһәмиятен аңлау, аларны киләчәктә куллана белү. | -*Укучылар, үзбәя кәгазьләрегездәге тамгаларны санагыз. Түгәрәкләр күбрәк булса – 5, квадратлар күбрәк булса 4, өчпочмаклар күбрәк булса 3 куегыз.*<br><br>-*Укучылар, бүген без дәрес башында нәрсәне белергә теләгән идек?*<br><br>-*Белдекме?*<br>-*Бүген син нәрсә өйрәндең?*<br>-*Син нәрсәләр эшләдең?*<br>-*Син нәрсә аңладың?*<br>-*Нәрсәне аңлап бетермәдең?*<br>-*Димәк, бу безнең алдагы дәреснең бурычы булачак.*<br>-*Мин сезгә уңышлар телим!* | Укучылар үзләренә гомуми билге куялар.<br><br>-*Без бүген дәрестә фигыльнең нәрсә икәнен белергә теләгән идек.*<br><br>-*Белдек.* | Коммуникатив УУГ:<br>-бүтәннәрнең сөйләмен тыңлау һәм аңлау;<br>-үз фикерләреңне тулы, төгәл, ачык һәм аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау.<br><br>Регулятив УУГ:<br>-үз эшчәнлекләрен бәяләү. |

**Кулланылган чыганаклар исемлеге:**

1. Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова. “Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле укыту: гомуми программа (татар төркемнәре өчен)”. Казан, 2011.

2. Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, Е.А. Панова. “Татар теле. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 2нче сыйныфы өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен)”. Казан, “Мәгариф - Вакыт”, 2013.
3. Концепция федеральных государственных образовательных стандартов общего образования: проект /Рос. акад. образования; под ред. А. М. Кондакова, А. А. Кузнецова. – М.: Просвещение, 2008.
4. Формирование универсальных учебных действий в основной школе. Система заданий. Под ред. А. Г. Асмолова, О. А. Карабановой. М.: Просвещение, 2010.
5. «Эзләнүләр һәм табышлар » (Иҗади үсеш технологиясен укыту-тәрбия процессында куллану тәҗрибәсеннән) «Иҗат» нәшрияты, Яр Чаллы-2000
6. «Татар теле һәм әдәбиятын системалы укыту: эзләнүләр һәм тәҗрибә» Яр Чаллы- 2006.
7. Профессиональный стандарт педагога, 2014 год

## **“Дәресләрдә яңа мәгълүмати технологияләр һәм актив методлар кулланып, укучыларда телне өйрәнүгә кызыксыну уяту”**

**Зәйнуллина Эльвира Тимерҗан кызы,**
**Хәйбрахманова Ания Әмирҗан кызы**

*Алабуга шәһәренең*
*10нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе,*

*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Без мәгълүматлар чолганышында яшибез һәм яңа мәгълүмати технологияләрдән башка аларны үзләштерә дә, җәмгыять үсеше өчен файдалана да алмаячакбыз. Шуңа күрә, иң беренче чиратта, без шуны үзебез аңларга һәм укучыларыбызга төшендерергә тиешбез: даими рәвештә укып, белемебезне күтәреп торганда гына, заманнан артта калмаска мөмкин. Һәм бу уку-белем алу күп очракта мөстәкыйль, үз белемеңне күтәрү рәвешендә барачак. Нәкъ менә шуңа күрә укучыларга үзлектән белем алу, чыганаклар белән эшләргә өйрәнү күнекмәләре бирү мөһим. Ә рус телле укучыны сөйләмгә алып чыгу, аралашырга өйрәтү, “ватып-җимереп” булса да, үз фикерләрен җиткерә белүләренә ирешү – бүгенге көн таләбе.

Укучыны сөйләмгә, аралашуга ничек алып чыгарга? Дәресләрдә нәрсәләргә игътибар итәргә, нинди яңа алымнар кулланганда, нәтиҗәгә ирешеп була? Үзебез биргән мәгълүматны ничек укучы хәтерендә калдырырга, тормышта, яңа шартларда кулланырга өйрәтергә? Алга таба ул бу белемнәрне кайда кулланачак? Башта үзебезгә шушы сорауларга җавап табарга кирәктер, минемчә.

Дәресләрдә иң кирәкле һәм иң авыр эш төрләрениләр соң?

Әлбәттә, укучыларның игътибарын җәлеп итү (бүгенге ФГОС таләпләре буенча моны мотивлаштыру дип атыйлар);

теманың, җиткерергә теләгән идеябезнең актуальлеген формалаштыру (Б.Н.Алмазов“Тәрбия – котылгысыз конфликт, чөнки ул нәрсә телимгә каршы, нәрсә тиешне, кирәкне эшләргә мәҗбүр итү” дигән. Ягъни без проблемалы ситуация тудырырга, укучыны бу теманың кирәклегенә инандырырга тиешбез);

нәтиҗәне күрергә өйрәтү (максатларны билгеләтү: моны үзләштерсәк, без нәрсәгә ирешәчәкбез, киләчәктә аны ничек кулланачакбыз?);

ниндидер гамәлләр эшләргә теләк уяту.

Боларга ничек ирешергә?

Укучыларның дәрес материалына кереп китүенә кроссвордлар, ребуслар чишү уңышлы гына ярдәм итә. Әсәрдән өзекләр уку, халык авыз иҗатына, бигрәк тә табышмакларга, тизәйткечләргә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Сәнгатьнең башка төрләре булган рәсемнәргә күзәтү, җырлар тыңлау аша да укучыны темага якынайтырга, дәрес материалы кысаларына кертеп җибәрергә мөмкин.

Актив бәяләү методы да өлешчә моңа нигез була ала. Нинди эш өчен укучы нинди белге алачагын белергә тиеш. Язма эшләр, презентация, тест һ.б. буенча, әлбәттә, бу критерийлар эшләнгән. Ә телдән җавап өчен нинди критерийлар булырга тиеш? Моны эшләргә һәм укучыны конкрет таләпләр белән таныштырырга кирәк. Мәсәлән, тема буенча дөрес оештырылган җаваплар санына карап бәяләү: 5 дөрес җөмлә әйтте – “5”ле һ.б. Хаталы җөмлә саналмый.

Яңа информацион технологияләр куллану – заман таләбе. Галимнәр хәтердә калдыру мөмкинлекләре пирамидасын төзегәннәр. Әлеге пирамидадан күренгәнчә, укучылар үзләре укыганның 10% ын гына истә калдыралар, укытучыдан яки башкалардан ишеткәннең 20%ы хәтердә кала; күргән мәгълүматның 30%ы саклана, күрү һәм ишетү аша укучы 50% мәгълүматка ия була; үзе сөйләсә, материалның 80% ы укучы хәтерендә калырга мөмкин. Ә менә 90% ка - укучы үзе эшләгәндә генә ирешеп була икән. Практикада күренгәнчә, презентацияләр ясату, проект эшчәнлегенә тарту, мөстәкыйль биремнәр биреп эшне төркемнәрдә оештыру, дәрестә укучыны төрле рольләргә кертү кебек эшләр шактый нәтиҗәгә ирешергә мөмкинлек бирә.

Проект эшенең формалары: аннотация, рецензия,мәкалә яздыру;көндәлек, журнал, альбом, газета ясату; коллаж,комикс, сценарий яздыру;таблица, тасвирлау, фото-, аудио-, видеоотчетлар ясату;афиша, реклама, күргәзмә эшләтү;программа, брошюра, каталог, сүзлекләр төзетү;электрон презентация ясату һ.б. булырга, аларны татар телен яхшы белүче яки рус телле укучылар белән дә дәрес кысаларында эшләргә, парларда яки төркемнәрдә эшне оештырырга мөмкин.

Компьютер һәм шуның белән бергә мәгълүмати технологияләр куллану, укучыга гына түгел, хәтта укытучының үзенә дә үсәргә киң мөмкинлекләр бирә. Юкка гына белем бирү процессын компьютерлаштыру – мәгариф үсешендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тормый.

Югары сыйныфларда “Мозаика” алымын кулланырга була. Бу очракта укучылар кечкенә төркемнәргә берләшәләр һәм информацион блок тәшкил итәләр. Һәр

төркемнең үз материалы була һәм төркемдәге укучылар башта шуны үзләштереп, иптәшләренә аңлаталар, ягъни һәрберсе укытучы роленә керә. Төркем эчендә эш төгәлләнгәч, башка төркемнәргә күчеп, анда үз материалларын аңлаталар, аларныкын тыңлыйлар. Кире һәрберсе үз төркеменә яңа материал аңлап кайта һәм иптәшләренә аңлата. Вакытны экономияләү максатында сөйләнәчәк материалны өйгә бирергә, класста чыгышларны гына тыңларга да була. Монда укытучының төп эше – чыганаклар (дәреслек, өстәмә әдәбият, сүзлекләр, интернеттагы кирәкле сайтлар) белән тәэмин итү, эш белән җитәкчелек итү. Әлбәттә, мондый дәрестә күп эш эшләп булмый, әмма болай эшләгәндә 90% информация истә кала икәнен исәпләсәк, игътибарга лаек һәм кызыксындыру, укучының үз-үзенә ышанычын арттыру ягыннан да отышлы.

Яңа мәгълүмати технологияләргә нигезләнгәндә, укучы эшчәнлеге продуктив, иҗади, эзләнү характерын ала. Методның нигезендә укучы һәм укытучының диалогы тора. Укытуда актив методларны кертүчеләр дигәндә, без А. М. Матюшкин, Т. В. Кудрявцев, М. И. Махмутов, И. Я Лернер, М. М. Леви һәм башкаларны саный алабыз.

Актив методлар кулланып укыту түбәндәге гомуми дидактик принципларга нигезләнә: укыту методы һәм укытуның эчтәлеге арасында ярашу; метод һәм эчтәлекнең укыту максатларына туры килүе; проблемалылык, «тискәре тәҗрибә», «гадидән авырга» принциплары; коллектив эшчәнлекне оештыру; алгарышлы укыту, уку вакытын экономияләү.

Укытуның актив методлары белем һәм күнекмәләрне үзләштерү вакытын кыскартырга һәм мөстәкыйль эшкә күбрәк вакыт калдырырга мөмкинлек бирә, чөнки яңа белемнәрне үзләштерү практик күнегүләр белән бергә бара. Мәсәлән, теманы аңлау, биремне үтәү, ситуатив күнегүләр башкару, эшлекле уен эшен берләштерергә була. Ягъни укучы укытучыны тыңлап кына утырмый, бергә нindidер күнегү эшли, диалог аша үз фикерен белдерә, нәтиҗә ясый, үзенә бәя бирә.

Мәсәлән, ситуатив күнегүләр (узнай, спроси, предложи, сообщи, попроси, дай совет). Мондый биремнәрне үтәгәндә укучы, өйрәнгән лексик һәм грамматик берәмлекләрне кулланып, үзенең уй-фикерләрен әйтү белән бергә боерык фигыльне, инфинитивны, алмашлыкларның килешләрдә төрләнешен ныгыта (*Дай совет другу, чтобы он не опаздывал на урок литературы)* яки сыйфат фигыль, сорау җөмлә төзелешен кабатлый *(Узнай,в каком классе учится девочка, которая вчера пела на концерте*?)

Бирелгән җөмләгә сораулар кую. Кем күпме сорау куя ала? Бу эшне төркемнәрдә дә эшләтергә мөмкин.

Җөмләләрне дәвам итү (*Дусларың күп булса, ..... Бүгендәресем күп, шуңа күрә .... Минем буш вакытым аз, чөнки ...* .)

Нинди дә булса әхлакый мәсьәлә буенча бер-берсенә киңәшләр бирү (*Китапка сак караш, яхшы уку, табигатьне саклау һ.б.*)

Сөйләмне үстерү өчен, диалогик формадагы эш төрләре дә бик отышлы санала. Әйтик: төшеп калган репликаларны өстәп язу; диалогларны дәвам итү; схема буенча диалог төзү; репликаларны дөрес урнаштыру; рәсем буенча диалог төзү;

диалогтан монолог, монологтан диалог төзү; текстны сәхнәләштерүгә әзерләү һ.б.

Дәресләрдә иҗади эшләргә дә зур урын бирү сорала. Алар шактый ук вакытны алса да, укучыларның фикерләү сәләтен, иҗади потенциалын үстерүдә аеруча зур роль уйный. Мәсәлән, әкиятләр, хикәяләр шигырьләр язу, табышмаклар уйлап чыгару, кроссвордлар, ребуслар ясау – аларны чишү, текстларны анализлау, үзгәртеп сөйләү, үзеңчә дәвам итү, схемалар, таблицалар ясау шактый ук кызыклы эшләр булып тора. Рәсемнәр, иллюстрацияләр ясауны да балалар яраталар.

Имитацион алымнарга конкрет ситуацияне анализлау методы, эшлекле уеннар, рольле уеннар кебек төрләр керә. Проблемалы ситуация тудыруда махсус каршылыкка керергә яки укучы ялгышын да файдаланырга була. Мультимедия чаралары кулланылмаган дәресләр сирәктер хәзер. Нәкъ менә дәрестә укучылар укытучылары җитәкчелегендә үз интеллектларын һәрьяклап үстерү, белем алу һәм тормыш мәсьәләләрен хәл итү өчен мәгълүмат туплау ысулларына ия булу максатында, компьютер технологияләрен кулланырга өйрәнәләр, материаллар, рәсемнәр, схемалар, диаграммалар табалар, үзләре ясыйлар. Компьютер – белем алу өлкәсендәге максатка ирешү, укыту процессын баету, активлаштыру, бала шәхесе һәм укытучының һөнәри осталыгы үсешенә йогынты ясау чарасы ул.

Дәрестә бары тик укытучы сөйләме генә булырга тиеш түгел. Татарча эшләнгән фильмнәр дә сөйләм үрнәкләре белән таныштыруның бер уңышлы чарасы. “Татар телле заман” дискында 50 тема бирелә, теманы сайлап алып, актив кулланышта булган сүзләрне кабатлату һәм шунда ук бирелгән сөйләм үрнәкләрен тыңлату, шуларны кабатлату, рольгә керү аша да укучыларның күп кенгә сөйләм калыпларын истә калдыруларына ирешергә мөмкин. Мәсәлән, “Туган җирем – Татарстан”, “Безнең йорт”, “Милли ризыклар”, “Безнең сәламәтлек”, “Кибеттә”, “Кем булырга?” һ.б. темалары буенча сөйләшүне укучылар аеруча ярата. К.С.Фәтхуллова, А.Ш.Юсупова, Э.Н.Денмөхәммәтоваларның “Татарча сөйләшәбез, укыйбыз,язабыз” рус телендә сөйләшүчеләр өчен 2012 елда “Хәтер” нәшрияты чыгарган татар теле дәреслеге (башлангыч дәрәҗә) үз эченә 18 теманы ала. Һәр тема аралашу ситуацияләренә бәйле тел һәм сөйләм берәмлекләрен гамәли үзләштерүгә кайтып кала. Дәреслектә төрле диалоглар, кечкенә текстлар һәм шигырьләр, коммуникатив биремнәр, рәсемнәр һәм фотолар күп. Шулай ук “Кайтаваз” дискы өлкән сыйныфларда куллану өчен кулай.

Сөйләм үстерүдә яңа сүзне ничек бирү дә зур әһәмияткә ия. Дәрестә яңа сүз өстендә эш ничек алып барылырга тиеш соң? Һәр вакытта да тәрҗемә аша гына бирү уңышлы түгел. Аның төрле юллары бар. Предметны күрсәтеп татарча әйтү, тексттан балалар таныш булмаган сүзләрне табалар,һ.б.

Танып-белү, хәрәкәтле, сюжетлы- рольле уеннар да сөйләмне үстерүдә бик зур ярдәм итә. Уеннар укытучы белән сыйныф арасында аралашу атмосферасы тудыра. Мәсәлән, кечкенә сыйныфларда “Сүзне тап” уенын яраталар, үзләре сүзне уйлыйлар да сүзнең җавабын табу өчен, иптәшләренә этәргеч сораулар бирәләр (Ул бакчада үсә, а хәрефенә башлана һәм бетә һ.б.)

Укучылар дәресләрдә татарча җырларны да яратып өйрәнәләр. Мәсәлән, “Чын дустым”, “Мин яратам сине, Татарстан!”, “Туган як”, “Туган тел” һ.б.

Гомумән, ФГОС шартларында дәресләрне төрләндерү өчен таләпләр дә, мөмкинлекләр дә арта. Бәхеткә, без аңа буш кул белән килмәдек: Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе, А.Г.Яхинның әдәбиятны укытудагы үзенчәлекле системасы белән коралланып, КСО методын, М.Мәхмүтовның проблемалы укыту технологиясен үзләштергән хәлдә керәбез. Инде үз заманында ук бөек әдибебез Галимҗан Ибраһимовның: “Күп белдерүгә караганда аз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысы” дигән сүзләрен искә төшерсәк, татар мәгарифенең шактый ук алдынгы позициядә барганлыгын күрербез.

## Тулы һәм ким җөмләләр

**Ибатуллина Фаниса Анваровна,**

*Менделеевск шәһәре 1 нче урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Аннотация**

Бу татар теле дәресе К.С. Фәтхуллова программасына нигезләнеп төзелде. “Авыл тормышы” дигән циклга кертелгән “Тулы һәм ким җөмләләр” темасы алынды. Бу теманы өйрәнүгә ике сәгать бирелгән. Бүгенге дәрес беренчесе.

**Дәрестә ирешелгән нәтиҗәлелек:**

- формалашкан белем һәм күнекмәләр: тулы һәм ким җөмләләрне аера беләләр; җавап бирә беләләр;
- кулланышка кертелгән фикерләү ысуллары: чагыштыру, гомумиләштерү, эзләү;
- УУД формалаштыру: регулятив (көйләү) - теманы һәм максатны үзләре куя, үзләре нәтиҗә чыгара, үз эшчәнлекләрен үзләре бәяли; танып-белү – модельләштерү, билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау, чагыштыру (ике диалог).; коммуникатив – парларда контакт урнаштыру, тыңлый белү, сорау куя, җавап бирә белү; шәхси – табигатьне сакларга өндәү.

**Дәрес планы**

**Предмет:** татар теле.

**Тема:** Тулы һәм ким җөмләләр.

**Максат:** 1) *Дидактик:* тулы һәм ким җөмләләр турында төшенчә бирү, ким җөмләләрнең кулланылышын һәм диалогик сөйләмдәге әһәмиятен ачыклау.

2) *Үстерешле:* иҗади фикерләү сәләтен, чагыштырып, нәтиҗә ясау күнекмәләрен камилләштерү, диалогик сөйләм телен үстерү.

3) *Тәрбияви:* авыл табигатенең матурлыгына соклана белүне, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

## Предмет буенча:

- тулы һәм ким җөмләләрне аера белү;
- тулы җөмләләрдән ким җөмләләр ясый белү;
- сорауларга тулы һәм ким җөмләләр белән җавап бирә белү;
- ким җөмләләр турында сөйли белү.

**Метапредмет:**

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:**

- дөрес сөйләм булуга омтылыш;

-үз фикереңне әйтә белү;

-парларда килешеп эшли белү;

-фикереңне дәлилли белү;

**Регулятив:**

- -уку бурычларын кую;
- -барлыкка килгән ситуациядә ориентлаша белү;
- -үз фикереңне төгәл җиткерү;
- -таныш арасыннан таныш булмаганны билгели белү;
- -нәтиҗәләр формалаштыру;

**Танып белү:**

- тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу;
- төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итү һәм аңлау;

- тикшерүгә алынган тулы һәм ким җөмләләрнең билгеләрен анализлау;
- өлешләрдән070 бербөтенне төзи белү;
- гомумиләштерү

**Коммуникатив:**

- сөйләмнең диалогик формасы белән эш итә белү;
- сорау куя, җавап бирә белү;
- укытучының сөйләмен тыңлау һәм аңлау.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне өйрәнү һәм беренчел ныгыту.

**Предметара бәйләнешләр:** әдәби уку, рус теле, әйләнә-тирәне өйрәнү

**Җиһазлау:** К.С. Фәтхуллова “Татар теле” 6 класс дәреслеге, проектор, ноутбук, карточкалар, карандашлар.

**Дәрес барышы.**

**I Ориентлаштыру, мотивлаштыру этабы.**

**1 . Оештыру моменты.**

- ( СЛАЙД 1 ) Исәнмесез, укучылар!
- Исәнмесез.
- Утырыгыз. Әйдәгез танышыйк: минем исемем Фәнисә Әнвәр кызы. Менделеевск шәһәре 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Бүгенге татар теле дәресен сезнең белән мин алып барам.

Хәлләрегез ничек?

- Рәхмәт, яхшы.
- Ә кәефләрегезне белер өчен беренче карточкаларны алдык. (СЛАЙД 2) Кәефегез шәп булса, МИН сүзен яшел төскә буягыз, кәефегез уртача булса, зәңгәр төскә, ә кәефегез начар булса, кызыл төскә буягыз. (Эшлиләр). Ә хәзер кәефегез белән партадашыгыз белән бүлешегез. Карточкаларыгызны бер-берегезгә күрсәтегез. (Эшлиләр). Безгә дә күрсәтегез.
- Бер-беребезне сәламлибез һәм дәресебезне башлыйбыз!

- **(СЛАЙД) Бүгенге дәресебезнең девизы:** өйрән, уйла, җавап бир, нәтиҗә яса! Сез килешәсезме? Хор белән кабатлыйк әле!(Кабатлыйлар)
- Рәхмәт.

**2. Фонетик зарядка.**

- 1) Хәзер авазларны кабатлыйбыз. [w] авазы өстендә эшлибез.

( СЛАЙД 3) Кабатлыйбыз: **[w] - [wa] [wы] – [wакыт] [аwыл] [таwык]**

**Алгоритм:** 1) нормаль тавыш белән;

2) пышылдап;

3) кычкырып, эмоциональ.

- Укучылар, сезнең кайтаваз – эхо ишеткәнегез бармы? Әйдәгез сүзләрне эхо формасында кабатлыйк әле. Мәсәлән, вакыыыыт, кыт, кыт, кыт

Молодцы. Рәхмәт.

**3. Уку мәсьәләсен кую.**

- (СЛАЙД 4) Дәвам итәбез. Мин сезгә укучыларымнан сәламнәр алып килдем. Сезнең бурыч – видеороликларны карап, диалогларның бер-берсеннән нәрсә белән аерылуын әйтү.

1 нче видео.

Хор белән: Менделеевск шәһәренең 1 нче мәктәбеннән сезгә сәлам!

- Сәлам, Эльвина!
- Сәлам, Милана!
- Эльвина, син авыл тормышы белән кызыксынасыңмы?
- Әйе, мин авыл тормышы белән кызыксынам.
- Эльвина, синең авылда туганнарың бармы?
- Әйе, минем авылда туганнарым бар.
- Авылыгызның табигате нинди?
- Авылыбызның табигате матур?
- Авылыгызның табигатенә сокланасыңмы?
- Әйе, авылыбызның табигатенә сокланам.
- Рәхмәт.
- Сау бул.

2 нче видео.

- Сәлам, Эльвина!

- Сәлам.

- Эльвина, син авыл тормышы белән кызыксынасыңмы?

- Әйе, кызыксынам.

- Эльвина, синең авылда туганнарың бармы?

- Әйе, бар.

- Авылыгызның табигате нинди?

- Бик матур.

- Авылыгызның табигатенә сокланасыңмы?

- Әйе, бик сокланам.

- Рәхмәт.

- Сау бул.

(видеоларны карау)

- Сорауны кабатлыйм: Диалоглар нәрсә белән аерыла?

- 1 нче видеода җаваплар нинди? (тулы)

- 2 нче видеода җаваплар нинди? (тулы түгел)

(СЛАЙД 5) (Слайдта җаваплар гына)

- Беренче баганадагы һәм икенче баганадагы җөмләләр ничек атала?

(төрле җаваплар?)

Әйтсәләр:

- Җавапларның дөреслеген ребуслар ярдәмендә тикшерәбез.

(СЛАЙД 6) Беренче ребус

(СЛАЙД 7) Икенче ребус.

Әйтмәсәләр:

- Әйтә алмыйбыз. Безгә ребуслар ярдәм итәр. (ребуслар чишү)

- (СЛАЙД 8) (Тулы җөмләләр, ким җөмләләр)

- Димәк, дәресебезнең темасы нинди?

- Тулы һәм ким җөмләләр.

- Сезнең алда кәгазь битләре. Аларны әйләндерегез. Теманы дөрес әйттекме? Дәрес барышында тулы һәм ким җөмләләрнең кыскача моделен төзербез. (СЛАЙД 9)
- Теманы билгеләдек. Хәзер үзебезгә максатлар куйыйк . Дәрестә нишләрбез? Моның өчен безгә дәресебезнең девизы ярдәм итәр! (Девиз белән слайд)
- Җаваплар: тулы һәм ким җөмләләрне өйрәнербез, уйларбыз, сорауларга җаваплар бирербез, нәтиҗә ясарбыз.
- Үзбәя битләрен аласыз, теманы һәм максатны билгеләү буенча үзегезне бәялисез.
- Критерийлар:
- Яшел – теманы һәм максатны билгели алдым;
- Зәңгәр – авырлыклар туды;
- Кызыл – билгели алмадым.

**II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

1. – Дәреслекләрне 120 нче биттә ачабыз, 4 нче күнегү. Биремне ... укып чык әле.

Парларда диалогы укып чыгасыз. (1 пардан укыту)

- Тулы җөмләгә мисаллар китерегез.
- Иртәгә яңгыр булачакмы? Ничә градус җылы булачак? Әйе, радиодан әйттеләр.
- Рәхмәт. Ә хәзер ким җөмләләргә мисаллар китерегез.
- Булачак. Өч.
- (СЛАЙД) (Бер якта тулы җөмләләр, икенче якта ким җөмләле җаваплар)
- Тулы җөмләләр Сезгә аңлашыламы (понятны)?
- Әйе.
- Дөрес. Ә ким җөмләләр алдагы сораусыз, җөмләсез аңлашыламы? (Неполные предложения понятны без вопросов?)
- Юк.
- Димәк, нинди нәтиҗә ясыйбыз?
- Ким җөмләләрнең мәгънәсе алдагы сораулардан башка аңлашылмый .
- Модель битенә язып куябыз. (СЛАЙД) **Мәгънәсе алдагы сораудан, җөмләдән башка аңлашылмый. (1-3 укучыдан укыту)**

- Үзбәя битләрен алабыз. Беренче эшегезгә бәя бирәсез.
- Критерийлар:

Яшел – тулы һәм ким җөмләләрне таба алдым

Зәңгәр – хаталарым булды

Кызыл – таба алмадым

**2. Физкультминут.**

“Дүрт почмак” методы.

Укучылар, хәзер аз гына ял итеп алабыз. Бастык.

Балалар, игътибар итегез әле, сыйныфның дүрт почмагында яшел битләр күрәсез. Анда җөмләләр язылган. Беренчесе - Суларны пычратмагыз! Если вы согласны с этим утверждением потянемся к этому углу. Үләннәрне таптамагыз! Агачларны сындырмагыз! Табигатьне саклагыз!

Татарстанда 2017 нче ел – экология елы. Укучылар, кайда гына булсак та, шәһәрдәме, авыл табигатендәме, бу киңәшләрне һәрвакыт истә тотыйк!

3. Дәвам итәбез. Ике түгәрәк ясап басабыз. Музыка уйный. Сез түгәрәк буенча биисез. Вы танцуете по кругу. Музыка туктый. Кайда туктыйсыз, шул сезнең парыгыз була. Тышкы круг сорау бирә, эчке круг тулы җөмләләр белән җавап бирә. Темасы – авыл тормышы, авыл табигате. Мин сезгә 30 секунд вакыт бирәм. Сорауларыгызны уйлагыз. Башладык. (Эшлиләр)

Икенче тапкыр музыка уйный. Туктый. Эчке круг сорау бирә. Тышкы круг ким җөмләле җаваплар бирә. (Уйныйлар)

(тагын 1-2 тапкыр уйнатырга була)

- Рәхмәт, утырыгыз. Сорау: сез хәзер нишләдегез?
- Сораулар бирдек, аралаштык, сөйләштек.
- Тулы җөмләле җаваплар биргәндә без нишләдек?
- Сорауны кабатладык.

- Нинди җөмләләр белән җавап бирүе җиңелрәк, матуррак, тизрәк, артык кабатлауларсыз (без повторений) иде? (русча аңлату)
- Ким җөмләләр белән.
- Нинди нәтиҗә ясыйбыз?
- Ким җөмләләр сөйләмне матурлыйлар, җиңеләйтәләр.
- Тулы җөмләләрдә сорауны кабатлау бара.
- Модель битенә язып куябыз. (СЛАЙД)
- Үзбәя битләрен алабыз һәм үзебезгә бәя бирәбез.
- Критерий:
- Яшел – сораулар бирдем, тулы җөмләләр белән дә, ким җөмләләр белән дә дөрес җавап бирдем;
- Зәңгәр – хаталарым булды;
- Кызыл – сорау бирә, җавап бирә алмадым.
- Молодцы. Без сезнең белән дәрес башыннан ук диалоглар белән эшлибез. Шулай итеп, ким җөмләләр нинди сөйләмдә, кайда күбрәк кулланыла?
- Диалогик сөйләмдә, диалогларда.
- Ә тормышта ким җөмләләрне сез кайда кулланасыз?
- Вконтакте Социаль челтәрләрендә смс лар язганда.
- Модель битләрегезне аласыз һәм ким җөмләгә тагын бер билге язып куясыз. (СЛАЙД) (1-3 укучыдан укыту)

**4.** Дәвам итәбез. Хәзер уйнап алабыз. Мин сезгә карточкалар өләшәм. Кемгәдер сораулар, кемгәдер җаваплар эләгәчәк. (Кому то попадутся вопросы, кому – то ответы. Музыка уйный, сез биисез. Музыка туктагач, сораулар үзләренең җавапларын, җаваплар сорауларын эзлиләр. После остановки музыки, вопросы свои ответы, ответы свои вопросы будут искать. Когда находите, жмете друг другу руки.

Сораулар:

1. Авылыгыз янында урман бармы?

Авылыбыз янында урман бар.

2. Туганнарыгыз авылда кайда яшиләр?

Туганнарыбыз авылда зур йортта яшиләр.

3. Кырларда язгы кыр эшләре кайчан башлана?

Язын.

4. Авылда тормыш күңеллеме?

Әйе, күңелле.

5. Аланда нәрсәләр сикерә?

Чикерткәләр.

6. Сыер көтүе сәгать ничәдә кайта?

Җидедә.

**III. Рефлексия.**

- 1. Укучылар, без бүген нинди тема өйрәндек?
- Тулы һәм ким җөмләләр.
- Дәрес башында нинди максат куйдык? Нишләргә тиеш идек?
- Тулы һәм ким җөмләләр турында өйрәнергә, кулланырга, нәтиҗә ясарга тиеш идек.
- Нәрсәләр эшләдек?
- Диалогта тулы җөмләдән ким җөмләләр таптык, тулы һәм ким җөмләләр кулланып сораулар һәм җаваплар бирдек.
- Эшебезнең нәтиҗәсе итеп, модель килеп чыкты. Укып чыгыйк әле. (1 – 2 укучы укый. )
- Бер-берегезгә сөйләп карагыз әле. (сөйлиләр)
- Үзбәя битләрен алдык. Үзегезнең дәрестәге эшчәнлегегезгә бәя бирәсез.
- Яшел – модельга карамыйча сөйләдем;
- Зәңгәр – караштырып сөйләдем;
- Кызыл – модельдән карап сөйләдем.

- Укучылар, сез бу теманы өйрәнүне әле алга таба да дәвам итәрсез.
2. Өй эше.

1. Модель буенча ким җөмләләр турында сөйләргә өйрәнергә. (мәҗбүри).

2. Газет-журналлардан ким җөмләләр кергән әсәрдән, мәкаләдән өзек язарга.

3. "Авыл табигате" темасына тулы һәм ким җөмләләрдән торган диалоглар төзергә

3. "Мин" карточкагызның икенче ягын борасыз. Һәм шулай ук дәрес азагындагы кәефегезне билгелисез, тәгәрәкне буйыйсыз. Чыгып киткәндә миңа калдырырсыз.

4. Сезнең белән эшләү миңа бик җиңел булды. Бүгенге дәрестәге тырыш хезмәтегез, активлыгыгыз өчен сезгә бик зур рәхмәт. Мин сезгә укуыгызда уңышлар, сәламәтлек телим.

## Урок родного языка в условиях информационного общества

**Ильина Э.Н.,**
*учитель родного (марийского) языка и литературы*
*МБОУ Бимской СОШ Агрызского муниципального района*
*Республики Татарстан*

Концепция модернизации российского образования определяет цели общего образования следующим образом: «Общеобразовательная школа должна формировать целостную систему универсальных знаний, умений и навыков, а также самостоятельной деятельности и личной ответственности обучающихся за своё развитие». Важнейшими задачами являются «формирование у школьников гражданской ответственности и правового самосознания, духовности и культуры, инициативности, самостоятельности, толерантности, способности к успешной социализации в обществе и активной адаптации на рынке труда».

Требования к уровню подготовки учащихся задаются в деятельностной форме: «знать», «понимать», «уметь», «использовать в практической деятельности и повседневной жизни».

Идет формирование следующих компетентностей:

- к познавательной компетентности относятся умения (разделять процессы на этапы, звенья, периоды; устанавливать причинно-следственные, временные, функциональные связи между частями и целым и определять структуру объекта познания; различать факты, мнения, доказательства, гипотезы и т.д.)
- в области информационно-коммуникативной компетентности учащиеся должны приобрести умения (передавать содержание текста в сжатом и развёрнутом виде; - производить информационно-смысловой анализ текста; использовать различные виды чтения (ознакомительное, просмотровое, поисковое и т.п.); составлять план, тезисы конспекта; владеть монологической речью и т.д.)
- в области социально-мировоззренческой компетенции учащиеся должны овладеть умениями (формулировать свои взгляды; осознанно определять свою национальную, социальную, конфессиональную идентичность; адаптироваться к жизни социума; понимать значение традиций и устоев)

Большинство современных публикаций по теории обучения связано с идеей активизации учебного процесса и учебной деятельности учащихся. Под активизацией имеют ввиду эффективное использование тех приемов и методов обучения, которые известны из традиционной дидактики. Но с информатизацией образования перед учителем ставятся новые задачи активизации образовательного процесса - необходимость использования в своей работе информационно-коммуникационных технологий.

Из психологии известно, что зрительные анализаторы обладают более высокой пропускной способностью, чем слуховые. Глаз способен воспринимать миллионы бит в секунду, ухо - только десятки тысяч. Информация, воспринятая зрительно, более осмыслена, лучше сохраняется в памяти. "Лучше один раз увидеть, чем сто раз услышать", гласит народная мудрость. Учитывая это, я поняла, что надо расширять арсенал зрительных и зрительно-слуховых средств

подачи информации. Взаимодействие должно осуществляется по всем каналам восприятия "текст - звук - видео - цвет". Учитывая это, я стала использовать цифровые образовательные ресурсы (ЦОР) с целью формирования у них информационно-коммуникативных компетенций (ИКК) на своих уроках.

Использование средств мультимедиа в преподавании марийского языка и литературы, как и любого урока, подчиняется общей задаче: наиболее полно, наглядно и просто раскрыть какую-либо тему. Важно отметить, что компьютерные технологии представляют большой интерес, как новое эффективное средство создания принципиально новых наглядных пособий, электронных учебников и систем по проверке знаний. В результате они смогут успешно объединить в себе свойства многих средств и форм обучения.

Для сохранения стиля преподавания и разработанной схемы урока целесообразно использовать отобранный материал электронного учебника для создания собственной мультимедийной презентации в среде Microsoft Power Point.

При подготовке к уроку, мною разрабатывается необходимое количество слайдов, отражающих основное содержание урока, готовится необходимый видео- и звукоряд, выполняющий иллюстративную функцию.

Представление информации в различных анимационных, видео-, аудио-формах активизирует внимание учеников. Учитель эффективно использует время урока, сосредоточив внимание на наиболее сложных дидактических или иных вопросах. Технология презентации создает широкие возможности для реализации дидактического принципа наглядности:

-демонстрация карт, иллюстраций исторических событий, портретов писателей, поэтов, деятелей искусств и науки, государственных деятелей, художественных образов, картин;

-демонстрация звукового и видео - материалов (кадры из исторических документальных и художественных фильмов, мультфильмов).

Предварительная подготовка информации позволяет выполнить этот фрагмент процесса обучения на более высоком методическом уровне, нежели подготовка школьной доски.

Четкая структура урока, определяемая порядком слайдов, повышает системность, логичность изложения материала. Текст, представленный на экране для класса, в то же время является опорным конспектом для самого учителя.

Усвоение материала будет более качественным, если возникает потребность в знаниях, когда каждый ученик становится активным участником своего обучения. Создание собственного компьютерного проекта позволяет активизировать познавательные способности, развивает творческие возможности, учитывает интересы учащихся. Цель проектного метода - индивидуализировать процесс обучения, дать возможность каждому ученику обучаться в удобном для него режиме.

Внедрение информационно-коммуникативных технологий в преподавании любого предмета дает возможность перехода на качественно иной уровень образования, значительно активизирует учебный процесс и учебную деятельность учащихся.

Наряду с информационными технологиями в основе процесса обучения лежат технологии личностно-ориентированного, рефлексивного обучения, современные методы психолого-педагогической диагностики. Эффективно сочетаются традиционные методы и инновационные технологии обучения.

Особое внимание в формировании личности должно быть обращено на воспитание патриотического отношения к родному краю, его природным богатствам.

Объектом изучения школьников становится родная школа, традиции национальной культуры, история села, района, края, близкое им и родное. Каждому подростку необходимо самому сделать открытие. А задача педагога - поддержать эту попытку, дать в руки учащегося - умения исследовать и пройти со своим воспитанником путь познания, начиная с наблюдения и заканчивая постановкой новой проблемы.

Сочетание урочной и внеурочной формы работы позволяет сконцентрировать усилия, направленные на формирование и закрепление знаний краеведческого

характера, многостороннего развития личности, осуществить комплексный подход к изучению родного края

Открытие в знакомом окружении незнакомого, поиск (в процессе выполнения учебных познавательно-проблемных заданий) в привычной для ребенка среде новых сведений – увлекательный процесс познания, способствующий формированию учебной мотивации школьников.

Обосновывая уместность цифровых образовательных ресурсов и средств в учебно-воспитательном процессе на своих уроках систематически использую имеющиеся информационные ресурсы, дополняю уже имеющиеся, совместно с детьми создаем новые.

Используемые в работе технологии дифференцированного и личностно-ориентированного обучения, здоровьесберегающие технологии позволяют добиваться благоприятного эмоционально-психологического климата в классе, на уроках, здоровьесберегающего стиля общения, наличие эмоциональных разрядок, содействует формированию у обучающихся адекватной самооценки, индивидуальный подход к обучающимся способствуют сохранению и укреплению психологического здоровья обучающихся, воспитанников.

В среднем звене используются следующие технологии (урок- путешествие, урок – суд, урок – экскурсия, урок – погружение и т. д.) Наличие цифровых образовательных ресурсов позволяет сделать восприятие материала ярким, красочным, наглядным.

В старших классах учащиеся создают презентации, используют на уроках информацию полученную в Интернете (для них это очень близко), пытаются воссоздавать картину событий читаемых произведений (инсценировать), занимаясь поисковой и исследовательской деятельностью.

Учитывая разный уровень педагогического восприятия учащихся, производится разноуровневая работа с одаренными и отстающими учениками. Учащимся раздают разноплановые задания – от простого до задания повышенной сложности. Для создания оптимального психологического климата в коллективе использую игровые моменты и творческие работы.

Разрабатываю механизмы учета индивидуальных достижений талантливых обучающихся. С одаренными детьми провожу индивидуальную работу, используя задания повышенной сложности, разбираю с ними различные олимпиадные задания. Предоставляю им различный дополнительный материал, тем самым стимулирую их интерес к предмету. Учащиеся постоянно принимают участие в различных олимпиадах, конкурсах, научно-практических конференциях и социальных проектах, тем самым повышая свою мотивацию к изучению предмета.

## Проблема сохранения и развития родного русского языка и литературы


**Каишева Татьяна Михайловна,**

*учитель русского языка и литературы*
*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение*
*«Большешурнякская средняя общеобразовательная школа»*
*Елабужского муниципального района Республики Татарстан*


Я как учитель - предметник ставлю перед собой цель: прививать учащимся интерес к изучению русского литературного языка; освоение его грамматических, орфографических, орфоэпических и пунктуационных норм, воспитание интереса и бережного отношения к языковой культуре своего народа. В связи с этими задачами преподавания родного (русского) языка я считаю следующими: погружение в язык, овладение знаниями о культуре, истории, традициях и обычаях народа.

Успешное изучение родного русского языка и литературы невозможно без глубокого интереса к нему. Поэтому стремлюсь раскрывать перед своими учениками красоту, богатство родного языка, показывать его многообразные возможности, пробуждать у ребят постоянное желание узнавать новое о родном языке, его развитии, приучать их вдумчиво относиться к слову, обращаться к словарям, справочникам, бороться за культуру речи. Лишь так можно сформировать у ребят осознанные и прочные языковые знания и умения, научить владеть всеми сокровищами родного языка, по-настоящему полюбить этот непростой предмет.

Большую роль в этом направлении играют уроки литературы. На этих уроках обучаю учащихся пользоваться всеми средствами литературного языка, развивать словарный запас учащихся, формирование умений выражать свои

мысли. Именно на этих уроках, изучая произведения русской литературы и литературы родного края, осуществляется воспитание нравственных начал.

На первом уроке рассказываю о социально-историческом значении русского народного костюма, его символике, части одежды, видах. Костюм - это наследие культуры. Учащиеся выполняют эскиз костюма, его деталирование, сравнивают с костюмами других народов.

Большую возможность в изучении особенностей нашего народа дает внеклассная работа по предмету. Возможностей стало больше, потому что у меня есть внеурочная деятельность. И также это День родного языка, предметная неделя, юбилейные даты писателей. Большое внимание уделяется патриотическому воспитанию школьников. Создана воспитательная программа.

В наше время исключительную актуальность приобретает приобщение подрастающего поколения к своей национальной культуре, национальному искусству, ведь не зная истоки своей культуры, невозможно изучать культуру другого народа.

Школа является единственным материальным возрождающим фактором, реализующая культурное образование, не только является государственно-общественной ценностью, но и выступает гарантом выживания и возрождения утерянного.Задача школы - помочь учащимся обрести уважение к чести и достоинству каждого народа, доказать, что нет народа лучше или хуже другого. Главное в каждом человеке – личностные качества, а не национальная принадлежность.

Не растерять, сохранить то богатство, каким испокон веков владел каждый народ, приобщить детей к народному творчеству – одна из задач современного обучения и воспитания. Только усвоив свои национальные культурные ценности, можно понять идеалы других времен и народов.

В «Концепции модернизации российского образования в период до 2010 года» сказано, что «многонациональной российской школе предстоит проявить свою значимость в деле сохранения и развития национальных культур народов России, повышение ценности русского и родного языков, формирование российского самосознания»

Проблема сохранения языка очень важна в наши дни.

Язык человека и народа в целом играет важнейшую роль в нашей жизни. На языке люди мыслят, общаются, выражают свои эмоции и свой менталитет. Д.С.Лихачев - советский филолог, поднимает проблему ценности языка, вся сознательная жизнь человека связана с родным ему языком. Все наши чувства, переживания, мысли передаются через язык.

Благодаря языку, на котором говорит человек, можно понять его характер.

Язык-знак культуры и темперамента человека.

В современном мире появляется много нового в языке. И не все приобретения полезны. Многие ученые пытаются донести до читателя, что все составляющие языка должны использоваться разумно.
Язык, как отражение нашей души, должен быть красив и чист. К сожалению, в современном мире об этом все чаще забывают. С каждым днём русский язык все больше засоряется, и многие слова теряют своё изначальное значение и красоту. Такая ситуация может привести к плачевным последствиям в будущем. Поэтому нужно беречь язык и стараться не допустить его падения. В литературе существует множество произведений, где поднимается проблема сохранения языка. Этот вопрос давно интересовал людей. Многие великие умы задумывались над ним. И до сих пор он не утратил своей важности. В стихотворении в прозе И.С Тургенева "Русский язык" говорится, что русский язык это надежда и опора для народа. Автор называет его великим и могучим. Стихотворение доносит до читателя простую истину: русский язык помогает выжить в дни тяжёлых испытаний: «Во дни сомнений, во дни тягостных раздумий о судьбах моей родины, ты один мне поддержка и опора, о великий, могучий, правдивый и свободный русский язык!». И именно поэтому нужно сохранять и оберегать его.

Сейчас люди разрушают величественный язык своими же руками, при том не задумываясь, что постепенно отбирают сами у себя главную возможность - широко мыслить, говорить, более того, обмениваться информацией.

Видим, насколько уникален наш язык - "Он живет для будущего". Действительно, какой еще народ может похвастаться живостью и пластичностью языка, на котором говорит? Не могу не согласиться с мыслями писателя - к сожалению, в повседневной жизни нам приходится постоянно сталкиваться со всевозможными жаргонизмами, отнюдь не украшающими язык.

Данная проблема особо чувствуется в молодежной среде. Использование сленга, сокращений и просто неправильного написания слов, несомненно, отрицательно сказывается на развитии молодежи. Таким образом, ко всему сказанному нужно добавить, что люди должны следить за "экологией" русской речи и беречь ее многообразие, во-первых, для собственного будущего. Для того чтобы не утратить способность излагать свои мысли и саморазвиваться.

Молодежные каналы вносят свою лепту: дикторы и ведущие уподобляются нашим героям с улицы, говорят на их языке, а возможно, уже не могут иначе.

Или в погоне за сомнительным рейтингом забыли о главном предназначении СМИ: не только нести новую информацию, но и воспитывать аудиторию. А ведь совсем недавно неправильно произнесенное в передаче слово считалось скандалом, грозящим диктору серьезными неприятностями, вплоть до увольнения. Сегодня же в эфире можно заменить литературный язык сленгом, в академической науке обсуждается вопрос о двойном ударении.

Казалось бы, ничего страшного, но вспомните, как трепетно относились к чистоте языка наши классики, в частности, Анна Ахматова: «В моей жизни всего было по два: две войны, две разрухи, два голода, два постановления – но двойного ударения я не переживу!» А сейчас пришло время двойных стандартов: двойная жизнь наших политиков и олигархов, жизнь наших детей в школе и на улице, двойное ударение. В стихотворении А. Ахматовой "Мужество" показано, что важнее все сохранить русский язык. Устами лирических героев автор говорит, что, несмотря на все испытания, родная речь не будет потеряна: «Не страшно под пулями мертвыми лечь, не горько остаться без крова, и мы сохраним тебя, русская речь, Великое русское слово». Все стихотворение проникнуто любовью к своему языку. В нем дано самое важное обещанием: сохранить язык и передать его потомкам. Итак, язык несёт в себе культурное наследие народа. Поэтому нельзя допустить его засорения и последующего вырождения. Нужно беречь язык, не только охраняя, но и приумножая его несметные богатства.

Одним из признаков серьезной болезни языка является засилье иностранных слов, из двух синонимов выживает заимствованный. Посмотрим экономические новости. Бартер, брокер, ваучер, грант, дебитор, дивиденды, инвестор, легитимный, лизинг, пролонгировать... А ведь можно сказать и по-другому. Неужели в нашей промышленности никогда не заключались торговые сделки через посредников или не продлевался срок аренды, не давали отсрочку должникам и не выделяли пособия. Понятия те же, вот только слова другие, нерусские. Как здесь не вспомнить слова В.Г. Белинского: «Употреблять иностранное слово, когда есть равносильное ему русское слово, - значит оскорблять и здравый смысл, и здравый вкус». Язык виртуального пространства – разговор особый. Конечно, радует, что русский занимает второе место по частоте употребления в интернете.

В речи старшеклассников то и дело слышишь: аська, тюбик, банить, баня, вобла, емеля, рама, енот, жаба, мылить… На первый взгляд, обычные русские слова, вот только с русским языком имеют мало общего: образовались от английских морфем. А это еще один признак болезни языка – заканчивается активное словообразование на основе русских корней. Еще одна проблема виртуального общения – смайлики. Действительно, зачем подбирать слова, чтобы признаться

в любви, попросить прощения или высказать благодарность. Послал значок – тебя поняли. Существует даже словарь наиболее распространенных смайликов.

А теперь вернемся в школу. Вы когда-нибудь проходили по школьным коридорам во время урока? Прислушайтесь: там, за дверями классных комнат звучит богатая, красивая русская речь. И неважно, урок литературы или математики, химии или географии. Здесь тот источник, который питает знаниями наше молодое поколение. Здесь дети учатся говорить грамотно, мыслить логически, открывать всю прелесть родного слова. Именно в школе дети постигают всю красоту и богатство русской поэзии, пишут свои первые стихи.

Язык для человека имеет большое значение. Он объединяет людей и помогает им общаться друг с другом. С помощью него мы формируем и выражаем свои мысли. Если в нашей речи присутствует часто нецензурная лексика, то это вряд ли поможет нам найти общий язык с окружающими. А если мы будем говорить спокойно и интеллигентно, то не только легко сможем общаться с другими людьми, но и покажем уровень своей образованности и воспитанности.

Так, например, при устройстве на работу люди проходят собеседование. По тому, как они отвечают на вопросы, определяется уровень их компетентности, степень их психологической уравновешенности. Предпочтение отдается тем людям, кто смог продемонстрировать не только свои знания, но и культуру поведения. Тем самым, благодаря языку человек может получить образование, устроиться на работу и найти своё место в жизни.
Во многих литературных произведениях затрагивается данная проблема. Мне вспоминается роман-эпопея Л.Н.Толстого “Война и мир”. С первых строк произведения мы встречаем французскую речь. Чаще всего на этом языке говорили люди из дворянской аристократии. Через иностранную речь героев автор показывает чуждость светского общества к своему народу. Л.Н. Толстой выражает своё отношение и отношение других героев к французам. Пример с князем Болконским показывает его ненависть ко всему французскому. Старый князь специально коверкал слова, но вскоре Болконский начинает говорить на чистейшем французском языке. Этот контраст дает возможность писателю показать отношение старого князя Болконского к происходящим событиям, в которых участвуют французы. Даже на иностранном языке можно передать своё отношения к разным вещам, людям, проблемам. Данный вопрос также волновал К. Паустовского, который сказал следующее: “По отношению каждого человека к своему языку можно совершенно точно судить не только о его культурном уровне, но и о его гражданской ценности». Истинная любовь к своей стране немыслима без любви к своему языку. Человек, равнодушный к родному языку,- антипатриот. Его безразличие к языку объясняется полнейшим безразличием к

прошлому, настоящему и будущему своего народа. Ещё раз подчеркну, что ценность языка заключается в том, что это способ самовыражения. Культура народа, его менталитет, чувства отдельных личностей передаются с помощью языка.

Русский язык – один из самых богатых, красивых языков мира. Множество форм, синонимов, формулировок, но, к сожалению, несмотря на это, мы в речи всё же пользуемся готовыми шаблонами, штампами, дабы не напрягать себя подбором замены. Это конечно же обедняет нашу речь.

Можно сравнить канцелярит с болезнью «Это — самая распространённая, самая злокачественная болезнь нашей речи», недуг. «Это окаянный и зловредный недуг нашей речи». И мы понимаем, что канцелярит действует на наш родной язык убийственно, как болезнь: «Быстро разрастаются чужеродные, губительные клетки — постылые штампы, которые не несут ни мысли, ни чувства, ни на грош информации, а лишь забивают и угнетают живое, полезное ядро». Наш язык беднеет, становится скучнее. Это дает нам повод задуматься, что надо что-то делать.

Для спасения языка каждый должен заботиться о своей речи, не использовать готовых шаблонов, если они не уместны. Ведь чистота речи – дело всех носителей того или иного языка.

В книге «Слово живое и мертвое» Нора Даль размышляет о проблеме омертвления языка через жаргонизмы, канцеляризмы, неологизмы.

Мы настолько привыкли «смешивать» в своей речи иностранные слова в разговоре с русскими людьми, что это нередко приводит к непониманию и абсурду. Это усиливает комичность ситуации, добавляя русские окончания к английским

Наш язык – наше богатство, ровно также, как нефть, газ, которыми славится наша страна. Последние невозобновимы, их нельзя улучшить или сохранить, а язык можно. Для этого от каждого нужно совсем немного: следить за своей речью и любить свой язык! Так давайте же постараемся изменить ситуацию, не дадим обеднеть нашему прекрасному русскому языку!

Язык – зеркало жизни народа. Какую важную роль он играет! Без него нельзя обойтись ни в одной сфере деятельности человека: везде очевидно его огромное значение. У каждого народа свой язык, а язык русский – один из самых замечательных, что подтвердят слова многих классиков нашей литературы. Однако под влиянием жизни язык меняется вместе с ней, притом не всегда в лучшую сторону.

За короткий срок сумели обрусеть» и «размежеваться по значению» слова,

относящиеся раньше только к определенной среде. Так же автор отмечает, что наш язык – интереснейшее явление для наблюдения лингвистов и литераторов, однако он пестрит не только иноязычными словами, но и уголовной лексикой, а слова, которыми пользовались классики, из него «ушли временно» и «ждут светлых дней».

Поэтому вслед за И.С. Тургеневым хочется обратиться к носителям русского языка во всем мире: «Берегите наш язык, наш прекрасный русский язык, этот клад, это достояние, переданное нам нашими предшественниками…».

**Заключение**

Всякое счастье рождается от качества мысли - слова - дела. Общество замыслило решение демографической проблемы, желая своим гражданам прежде всего личного семейного счастья, и продолжает вести антисемейную пропаганду большинством доступных речевых средств.

В погоне за всем иностранным, в стремлении копировать западные образцы, мы всё больше теряем свою самобытность, в том числе и в языке, ибо язык отображает образ жизни и образ мыслей. Как следствие этого потеря интереса к родному (русскому) языку, русской литературе и культуре, косноязычие, снижение грамотности и языковой и общей культуры. Нужно гордиться своим родным языком, который доверен нам нашими предками, который хранит традиции.

Многие факты русского языка свидетельствуют о том, что он есть для нас не просто лингвистическая система, одна из многих, он жизнь, освещённая божественным светом. В нем запечатлена миссия русской нации, что подтверждает И.С. Тургенев словами: «…Но нельзя верить, чтобы такой язык не был дан великому народу».

Список использованной литературы:


1. Нора Галь статья «Слово живое и мертвое».
2. Максим Кронгауз в статье «Русский язык на грани нервного срыва».
3. М.Зощенко рассказ "Обезьяний язык".
4. А. Кнышев «О великий и могучий русский язык
5. М. Кронгауз «Русский язык на грани нервного срыва»
6. ТАЙНА РУССКОГО СЛОВА. Заметки нерусского человека. - Даниловский благовестник, 2009 г..

Ирзабеков Василий (Фазиль)

7. РУССКОЕ СОЛНЦЕ, или Новые тайны русского слова, - Даниловский благовестник, 2011 г.


**<u>Татар телен аралашу аша өйрәтү</u>**

**Каримова Алсу Мансур кызы,**
*Менделеевск шәһәре*
*1нче урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Укытучыларыбыз алдында бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, телебезне саклап калу бурычы булса, икенчедән, рус телле балаларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, үстерү бурычы. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын таләп итә. Бүгенге көн укытучыдан иҗади эшли белүне сорый. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык – бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу.

Коммуникатив белем бирү технологиясе тел өйрәтүдә кирәкле нәтиҗәләргә ирешүдә зур роль уйный.Тел ул – аралашу чарасы, шәхесне төрле мәдәни кыйммәтләр белән таныштыру.

Укытучы һәм укучы телне өйрәнү процессында төп катнашучылар булып торалар. Алар арасындагы мөнәсәбәтләр хезмәттәшлеккә һәм тигез хокуклы партнерлыкка нигезләнгән булырга тиеш.

Татар телен аралашу аша өйрәтү дәреснең практик юнәлешен билгели. Сөйләшеп кенә сөйләшергә өйрәтеп була. Дәрескә сайлаган күнегүләр никадәр реаль аралашуга ошаган булса, шулкадәр эффектлырак була. Бу очракта тормышта очрамый торган бер генә фраза да кулланылырга тиеш түгел. Дәрестә бирелгән лексика тормышта аралашырга ярдәм итәрлек булсын. 3 нче сыйныф дәреслегендә “Ашамлыклар” темасы буенча лексиканы өйрәнгәч, ныгыту өчен кызыклы текстлар бар. Шуларны сәхнәләштерү – аралашу өчен бик кулай. (видеоматериаллар күрсәтелә)

Сөйләм эшчәнлеге өч юнәлештән тора: лексик, грамматик һәм фонетик. Алар сөйләм процессында бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгәннәр. Димәк, сүзләрне кулланылган формасыннан аерып үзләштерү мөмкин түгел. Күнегүләр ярдәмендә сөйләм берәмлекләрен истә калдырырга кирәк.

Белем бирүнең функциональлеге сүзләрне һәм грамматик формаларны үзләштерү процессында – фикерне дәлилләгәндә, нәрсә турында булса да сораганда, әңгәмәдә катнашканда – үзләштерүне күздә тота. Дәрескә укучылар билгеле бер темага чыгыш әзерләп киләләр, калган укучылар чыгыштан соң үзләрен кызыксындырган сорауларны бирәләр. “Гаилә” темасы буенча сөйләгәннән соң, укучылар “Син нинди чәчәкләр яратасың? Әтиең ашарга пешерәме? Әниең нинди төсләр ярата?” кебек сораулар биреп, әңгәмәне

җанландырып җибәрәләр. Бу укучыларны кызыксындырып кына калмый, йомшагракларын да әңгәмәгә тарта.

Уку процессында төрле ситуацияләрне куллану мөһим. Укучыларның яшь үзенчәлеген, кызыксынуларын истә тотып сайланган ситуацияләр генә зур әһәмияткә ия. Р.З.Хәйдәрова дәреслекләрендә ситуатив күнегүләр, диалоглар бик күп. Бу күнегүләрне башкарганда, укучының сүзләрне дөрес әйтүенә, интонациясенә, мимикасына игътибар итәргә кирәк. Шулар төгәл үтәлгәндә генә нәтиҗәгә ирешеп була.

Һәр дәрес яңалык алып килергә тиеш. Дәрес төрләре, формалары яңарып, үзгәреп торса, кирәкле сүзләрне укучы үзеннән-үзе истә калдыра.

Төрле укучылар бар. Алар бер-берсеннән табигый сәләтләре, характерлары, сөйләм һәм уку процессын тормышка ашыра белүләре, тормыш тәҗрибәләре, билгеле бер хисләре һәм эмоцияләре, кызыксынулары һәм коллективта тоткан урыннары белән аерылып торалар. Шуңа күрә коллективта эшне дөрес оештыру мөһим, чөнки монда укучылар бер-берсе белән актив аралашалар, бер кешенең уңышы башкаларныкы да булып санала. Төркемнәрдәге төрле эшләрне башкару, әсәрләрне сәхнәләштерү барышында, бер-берсе өчен җаваплылык хисе үстерелә. (9 нчы сыйныф укучылары белән төшерелгән Г.Ахуновның “Хәзинә” романыннан өзек, 4 нче сыйныфта А.Алишның “Куян кызы” әкиятен сәхнәләштерү)

Белем бирү процессында бөтенесе дә күнегүләргә бәйле. Күнегүләрдә белем бирүнең бөтен концепциясе чагылыш таба. Коммуникатив белем бирү процессында барлык күнегүләр дә характерлары буенча аралашу күнегүләре булырга тиеш. Шартлы сөйләм күнегүләрен һәм сөйләм күнегүләрен аерып карарга була. Шартлы сөйләм күнегүләре – күнекмәләр формалаштыру өчен махсус оештырылган күнегүләр. Аларга бер типтагы лексик берәмлекләрнең гел кабатланып торуы хас. “Кыш”, “Һава торышы” темаларын үткәндә, “кар” сүзенә бәйле лексиканы истә калдыру өчен, шул сүз белән сүзтезмәләр, тезмә сүзләр төзү аралашуга чыгу өчен нигез булып тора. (Кар бабай, кар кызы, кар көртләре, кар бөртеге...)

Сөйләм күнегүләре – төрле текстларның эчтәлеген үз сүзләреӊ белән сөйләү, төрле рәсемнәр, кешеләр, предметлар турында сөйләү, комментарийлар бирү. Бу күнегүләр индивидуаль үзенчәлекне исәпкә алып сайлананалар. Аралашырга өйрәнү вакытында укучылар тарафыннан хаталар да җибәрелә.

Аларны ничек төзәтергә соң? Бу эш төренә бәйле. Мәсәлән, фонетик хаталарны бөтенесен берьюлы төзәтеп бетереп булмый. Башта бер авазны, соңрак башка авазларны да дөрес әйтергә өйрәтәсең. Авазларны, сүзләрне җырлап әйтү, тизәйткечләр, эндәшләр, табышмаклар куллану – аерым игътибарга лаек булып тора. Грамматик хаталарга сыйныфның игътибарын

юнәлтергә кирәк. Ләкин кагыйдәне озак итеп аңлатып, укучының игътибарын сөйләм процессыннан читкә җибәрергә ярамый.

Шулай итеп, укучының шәхси үзенчәлеген исәпкә алып сайланган реаль аралашуга ошаган күнегүләрне үтәү вакытында булган хаталарны төзәтеп, аңлатып кына укучыларны татар телендә аралашырга өйрәтеп була.

## "Бәетләрдә халкым язмышы"

**Касимова Венера Наил кызы,**
*башлангыч сыйныф укытучысы,*
**Лотфуллина Илгизә Зөфәр кызы,**
*мәктәп китапханәчесе*
*Әгерҗе муниципаль районы*

*Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе*

А.б. Исәнмесез, кадерле тамашачылар! Сезнең белән бүген мөнәҗәтләр тыңлап, аларның эчтәлекләрен анализлап, мөнәҗәт әйтүче безгә ни турында әйтергә теләгәнен төшенергә тырышырбыз.

Мөнәҗәт һәм бәет – көйле әсәрләр. Эчтәлекләре ягыннан бер-берсенә якын торалар. Бәетләрдә язылу сәбәбе конкрет сүрәтләнә, мөнәҗәтләрдә исә вакыйга күзгә бәрелеп тормый.

Татар халык авыз иҗаты искиткеч бай, искиткеч тирән эчтәлекле ул. Озак еллар буена үткән буыннарның тормышы, язмиышы, иҗаты өйрәнелмәде, шуңа күрә ерак бабаларыбызның хисләре, уй-кичерешләре язмышы, тарихы, тормышы чагыла да инде. Халык авыз иҗатын тирәнтен өйрәнүне без үзебезнең максат итеп куйдык. Бүген без өлкәннәр көненедә бәет, мөнәҗәтләр хакында сөйләшергә җыелдык.

Мөнәҗәтләрнең төп темалары:

Туган-үскән илне сагыну, әсирлек, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре, гомер, картлык, үлем.

Туган –үскән илгә багышланган әсәрләрдә туган җиреннән, туганнарыннан аерылган шәхесләрнең хисләре чагылдырыла. Монда лирик геройның туган иленә, туган туфрагына, туганнарына, дус-ишләренә карата хисләре шундый кайнар.

**Ак йөзләрем сары булды.**

Фирак уты, фирак уты сүнәр микән йөрәкләрдә?
Исән чакта кайту насыйп булыр микән ераклардан?
Туган илнең ераклыгы яндыра сагыш – утларында,
Алам каләм, язам сәлам өзгәләнгән минутларда.
Моны яздым сагынганда, фирак уты кабынганда,
- Безнең илдән килгәннәр – дим, кошлар килеп кагынганда.
Әллә язмыш, әллә ялгыш аерды безне илләрдән,
Хәбәр көтәм мин сезләрдән кичен искән җилләрдән.

Кич утырып каләм юндым су буе камышыннан,
Ак йөзләргә сары төште сагыну сагышыннан.
Туган илдән китүләрем кабергә кергән кебек,
Зираттагы бабаларым:"Балам, китмә!"-дигән кебек,
Чит илләрдә мин яшимен, ата-ана туфрагын күрми.
Сагынуларым бетмәс инде үлеп каберләргә керми.
Мөнәҗәтем минем бетмәс, кәгазь белән каләм җитмәс,
Туган ил исемнән китмәс, сабырлык бирсен газиз алла.
Мөнәҗәтләр яза-яза, каләм тоткан кулым тала,
Күземнән канлы яшь ага, ерак булганга ара.
Туган якка күзем төшсә. Башлардан уйларым китә,
Йөрәк бәгърем яна башлап, түзәргә дәрманым бетә.
Ятып та йокым килмидер, ашасам ашым үтмидер,
Сез, туганнар, күз алдымнан һич бер минутка китмидер.

А.б. Хөрмәтле тамашачылар! Әйдәгез, туган як турында бүгенге көннәрдә язылган җыр тыңлыйк. Мәгъсум Латыйфуллин сүзләре, Рәис Сафиуллин көе.
**"Бик сагындым, авылым"**

А.б.Әйе, "Үз илемдә ямьле миңа бәрәңге бакчасы да", - дип юкка гына җырламыйлар шул. 17 йөзнең икенче яртысында яшәгән Мәүлә Колый да "Кардәшлек турында"гы шигырендә мондый юллар яза.

Карендәш мәхәббәте бал – шәкәрдин
Ләззәтледер, кыйммәтене белер булсаң.
Карендәшсез кешеләрнең сердәше юк,
Дошманнарга каршы чыкса, юлдашы юк,
Һәркем моңлы – карендәшсез булыр булсаң.

А.б. Ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләрен чагылдырган мөнәҗәтләрнең күпчелек өлешендә балаларыннан аерылган ялгыз аналарның хисләре. Картлык көнендә балалары ташлап киткән яисә бергә яшәп тә баласыннан ачык йөз күрмәгән аналарның моң-зарларын чагылдырган мөнәҗәтләр дә күп. Андыйлары безне уйланырга мәҗбүр итә. Бу әсәрләрдә ата-анага тугры һәм миһербанлы булырга өндәү идеяләре кызыл җеп булып сузылган.

*Төннәрендә моңсу айга карап*
*Күзләремнән яшьләр коямын.*
*Күп бала үстереп ялгыз калдым*
*Уйлыймын да хайран каламын.*
*Күп бала үстердем, эшләдем,*
*Шулай үтте минем көннәрем.*
*Алар үстеләр дә киттеләр*
*Картлык көндә ятим иттеләр.*
*Төннәремне бер дә йокламый*
*Сезне сагынам, сезне уйлыймын.*
*Ялгыз калган аккош бик зур күлдә*
*Бер ялгызы чумып-чумып йөзә.*

*Ялгыз ана, ялгыз йөдә*
*Күңел белән сезнең янда гизә.*
*10 бала үстереп ялгыз калдым,*
*Уйлыймын да хәйран каламын.*
*Күктә кояш та ялгыз диеп,*
*Аңа карап сабыр кыламын.*

А.б. Бәет – татар халык иҗатының лиро-эпик жанры. Бәет сүзе – гарәп сүзе ул, ике юллык шигырь дигәнне аңлата. Бәетләр килеп чыгышлары белән бик борынгы заманга карыйлар. Бәетләрне көйләп әйтәләр.Аларның төрләре бик күп. Шунысы мәгъүм: бәетнең нигезендә булган хәл, вакыйга ята. Шуңа күрә бәет көнкүрешкә якын жанр. Халык җырлары, бәетләр һәм мөнәҗәтләр кеше күңеленә нык тәэсир итәләр. Төрле темаларга караган бәетләр арасында шәхси фаҗигаләргә багышланганнары аерым урын алып тора. Менә безгә бәләкәйдән таныш булган “Сак-Сок” бәете.

Халык авыз иҗаты әсәрендә Сак һәм Сок атамалы кошларга әйләнгән ике бала язмышын сүрәтләү трагизм белән сугарылган. Бәет нигезенә ана каргышы төзәтеп була алмаслык бәхетсезлекләргә китерә дигән фикер салынган.

Җимнәр ташыйдыр кошлар басудан.

Әнкәй каргады безне ачудан. Бу бәеттә сүз ике баланың этиләре өйдә югында, сүз тыңламаган өчен, әниләренең каргышына дучар булуы турында бара. Дини китапларда “Ата-ананың баласына карата кылган догасы, пәйганбәрның өммәтенә карап кылган дога кебек булыр”, диелгән. Шуңа күрә ата-ана каргышыннан, рәнҗешеннән сак булу соралган. Әсәрдән күренгәнчә, әниләренең каргышы шулкадәр көчле булган ки, балалар шунда ук Сак һәм Сок атамалы мифик кошларга әверелеп, очып киткәннәр. Димәк, безгә бу дөньяда бәхетле булу өчен эти-әниләрнең сүзен тыңлап, аларны хөрмәтләп яшәргә кирәк.

А.б. Хөрмәтле, тамашачылар! Әйдәгез, Роберт Миңнуллин сүзләренә Илгиз Закиров көе “Әнкәмнең догалары” җырын тыңлап китик.

А.б. Хөрмәтле тамашачылар! Өлкәннәребезгә һәм янәшәдәге эти-әниләргә мәрхәбәтле булыйк. “Җәннәт ачкычы – ата-ана аягы астында”, - диләр бит. Эти-әниләрнең исән чакта кадерләрен белеп, хөрмәтләп, ризалыкларын алып калырга тырышыйк.

Тормышта төрле фаҗигалы хәлләр һаман булып тора. Еш кына мондый хәлләр китергән авыр югалтуларга карата кеше үзенең мөнәсәбәтен белдереп бәет иҗат итә, дөресерәге, моң, хәсрәт белән сугарылып ул үзе халык, яки кеше күңеленнән бәет булып чыга, яшәешнең, язмышның бер өлешен чагылдыра. Шәхси фаҗигалар турындагы бәетләрдә яшәү һәм үлем фәлсәфәсе дини мотивларга нигезләнеп тә аңлатыла. Бу читен хәлләр Алладан тәкъдирдә язылганнан килә, дигән фикерләр дә яши.

Ни генә булмасын, татар халык авыз иҗаты әсәрләре, шул нисбәттән бәетләр дә әдәбиятебезнең алтын фондына кергән. Аларны укучылар да, галимнәр дә укый, өйрәнә, гыйбрәт ала.

Безне аеруча әле яшәү тәмен дә тоеп өлгермәгән язмышлар бик нык тетрәндерә: 20 яше дә тулмыйча бу фани дөньяны, туганнарын калдырып киткән яшьләрнең, фаҗигале төстә һәлак булучыларның саны аеруча күп булуы тетрәндерә. Мәсәлән: «Азалия»бәете. Кыз, юл һәлакәтенә эләгеп, фаҗигале төстә вафат була.

Үзебезнең авылыбызда туып үскән, хәзерге вакытта Чаллы каласында яшәүче авылдашыбыз Лотфуллина Ләйсән “Азалия” бәетен иҗат итте.

“2003 елның июль аенда тетрәндергеч вакыйга булды: авыл яшьләре утырган ике мотоцикл бәрелеште. Бу фаҗигадә иң авыр яра алучы – дусты Азалия булды. Аның бер аягы нык җәрәхәтләнде. Ул ике ай буе – Ижау больницасында ятты. Аңа ике операция ясарга тиешләр иде. Беренчесе бик нык уңышлы булды. Дусты терелү өмете белән елмая башлаган иде. Тик... икенчесе яраткан, кадерле Азалиябезне арабыздан алып китте. Ул наркоздан айный алмыйча, октябрь аенда хастаханәдә җан бирде. Гөлчәчәк апа бердәнбер таянычы, өмете булган кызын югалтты. Бу үлем ботен авыл халкы өчен ышынмаслык вакыйга булды. Ләйсәнгә Азалия белән гел урамда очрашырбыз кебек тоела. Азалиянең арадан китүе күңелендә нindидер бушлык хасил итте. Шул бушлыкны бераз гына тутыру өчен ул аңа багышлап бәет язды”.

**“Азалия” бәете**

Ике меңдә өченче ел,
Октябрьнең өчесе.
Кайгы-хәсрәт белән тулды
Шушы көнне өй эче.

Бәхетле язмыш теләүләр
Булгандыр бит заяга.
Озын гомер язмаган шул
Ходай Азалиягә

Әнисенә,әбисенә
Бик тә газиз бу бала-
Уналты яшен тутырып
Күчте мәңгелек йортка.

Бу кадәр ач сагышка
Чыдасын әңкәң генә.
Аның кайнар күз яшьләре
Тамды салкын тәнеңә.

Соңгы сулышың алганда,
Уеңда кемнәр иде?
Әйтәсе сүзең калгандыр-
Хәзер нишләргә инде?

Ышанасым килми һич тә

Синең үлемнәреңә.
Соңгы тапкыр карадым мин
Синең нурлы йөзеңә.

Бик акыллы чибәр идең,
Яхшы дус була белдең.
Япь-яшь көе җаныкаем
Салкын гурләргә кердең.

Соңгы юлга озатканда
Үзәкләрем өзелде
Гомер юлың дускаем
Чирегендә киселде.

Бергә йоргән урамнардан,
Инде ялгызым үтәм.
Тик шулайда каршыма.
Чыгуыңны мин көтәм.

Никадәр генә көтсәмдә,
Чыкмассың шул каршыма.
Күбәләк булып җаннарын
Кайтыр минем яныма.

Сайрар кошлар җыр сузарлар,
Сызылап таннар атканда.
Шуңа карап сокланырга,
Син булмассың янымда.

Сине алган көзләр тагын килер,
Яралар да кабат яңарыр
Дус-ишләрең мәңге онытмаслар,
Элеккечә сине яратыр.

А.б. Вөждан, намус. Мөнәҗәтләр бу күркәм сыйфатлар турында да сөйли.
Кеше өчен иң әвәле – Намус,
Намусыңны сатып итмә табыш.
Байлык өчен илен – көнен саткан-
Ике дөнья өчен дә ул явыз.

Икенчесе иң кирәклесе – Акыл,
Вөңдансызда акыл ягы такыр.
Акылсызда намус та юк, иман да,
Алганга ант итеп барын сатыр.

Өченчесе – иң кыйммәтлесе – Әдәп,
Әдәп – көчле мәхәббәткә сәбәп.
Әдәпсездә бәхет тә юк, тәүфыйк та,
Кеше исемен күтәрүе дә гаҗәп.

Дүртенчесе иң кыйммәтлесе – Күңел,
Күңеле бозык кеше – кеше түгел.
Бозыкларга җир өстеннән юктыр урын,
Яшәмә дә, үлеп җиргә күмел.

Бишенчесе – иң мөһиме – Сабыр,
Сабыр кеше зур бәхетләр табыр.
Бер дә юкка ачуланып дөнья бозу –
Бер кайгыдан икенчегә салыр.

А.б. Хөрмәтле тамашачылар ” Менә шундый заман җитәр” мөнәҗәтен безгә .........................................апа укып күрсәтер.

Бу мөнәҗәттә кисәтү, алдан күрү, хаталанмауга өндәү һәм гөнаһлы булып яшәүдән куркырга кирәклеге хакында сөйләнә.

Менэ шундый заман житэр

Доньяда иман бетэр, халык карар унга - сулга,
Изге гамэл хис кылмаслар маллары куп булганга.

Ата-анадан хэят бетэр, балаларга шэфкать бетэр,
Туганнардан рэхим бетэр, менэ шундый заман житэр.

Биналары биек булыр, эче тулы зиннэт булыр,
Доньясы бозык булыр, менэ шундый заман житэр.

Зур-зур биналар салырлар, ашыгып ана барырлар,
Эчеп гауга кубарырлар, менэ шундый заман житэр.

Яхшыларга юл ачмаслар, яманнарга суз катмаслар,
Ахирэт, дип хич эйтмэслэр, менэ шундый заман житэр.

Машиналар чабып торыр, кайберлэре авып торыр,
Халыклары улеп торыр, менэ шундый заман житэр.

Ата-ана карап торыр, балалары хокем итэр,
Ни булганын хичкем белмэс, менэ шундый заман житэр.

Уз туганын танымаслар, хэлен барып сорамаслар,
Чит кешене дус курерлэр, менэ шундый заман житэр.

Жаннары да хич тыныч булмас, тэннэрендэ сихэт булмас,
Кайда кем нишлэрен белмэс, менэ шундый заман житэр.

Алып баручы. Менә шундый заман җитәр… Әйе, җитте ул заман. Без менә әлеге мөнәҗәттә тасвирланган заманда яшибез. Тирә — ягыбызны тәртипсезлек, әдәпсезлек, бозыклык, шәфкатьсезлек, битарафлык чолгап алган. Эчүчелек көннән-көн киңрәк колач җәя. Яшьләребез арасында наркомания, СПИД корбаннары көнләп түгел сәгатьләп арта.

Без, үз балаларыбызда да АКЫЛ, НАМУС, ИМАН тәрбияләргә тиеш. Ни чәчсәк, шуны урырбыз. Сарымсак, суган утыртып, алма, слива җыя алмабыз. Кеше җир йөзенә бары тик яхшылык эшләр өчен генә җибәрелгән. Сынар һәм сыналыр, яратыр һәм яратылыр өчен. Яратуны үтермик. Кеше кешене яратырга тиеш; ата-анасын, балаларын, туганнарын, туган җирен һәм, ниһаять, Җир шарын.

**ҖЫР “Яратыгыз” яки “Канатлансын күңелләр”**

“Алар өчәү иде” бәете ( Илгиз бәете)

А.б. Бәетләр кебек үк мөнәҗәтләр дә халыкның аһ-зары, эчке кичерешләрен сүрәтлиләр. Алар күп очракта Ходайдан рәхим-шәфкать сорап иҗат ителәләр. Мөнәҗәтләрдә шулай ук хуҗага рәхмәт, әдәплелек-итагатьлелекне сакларгакирәклеге турында еш әйтелә.

**ДИДЕ, МУСА.**

- Раббем Алла диде Муса
Җәннәт булыр микән миңа?
- Сиңа җәннәт булыр Муса
Сиңа җәннәт булыр Муса
Атаң - анаң разый булса.

- Раббем Алла диде Муса,
Миңа җәннәт булыр микән?
- Сиңа җәннәт булыр Муса
Сиңа җәннәт булыр Муса
Кыз туганың разый булса.

- И ходаем диде Муса
Җәннәт булыр микән миңа?
- Сиңа җәннәт булыр Муса
Күршеләрең разый булса.

- Раббем Алла диде Муса
Җәннәт булыр микән миңа?
- Җәннәт сиңа булыр Муса,
Җәннәт сиңа булыр Муса
Хәләл җефетең разый булса.

- Раббем Алла диде Муса
Миңа җәннәт булыр микән?
- Сиңа җәннәт булыр Муса.
Сиңа җәннәт булыр Муса
Гарипләрнең хәлен белсәң.

- Раббем, Алла - диде Муса,
Җәннәт булыр микән миңа?
- Сиңа җәннәт булыр Муса,
Сиңа җәннәт булыр Муса
Гамәлләрең дорес булса.

- Раббем, Алла - диде Муса
Миңа җәннәт булыр микән?
- Сиңа җәннәт булыр Муса
Сиңа җәннәт булыр Муса
Кыйлган изгелегең булса.

- Раббем, Алла диде Муса,
Җәннәт булыр микән миңа?
- Җәннәт булыр сиңа Муса,
Җәннәт булыр сиңа Муса
Ходаңның барлыгын белсәң.

**Җыр “Җиде ятлар туган түгел”**

Пока команды готовятся, болельщикам тоже предлагается попробовать себя в роли «писателей» Переведите пословицы на другие языки.

*1.* Ике куян артыннан кусан, берсен дэ тоталмассын / *Кок мераным поктет гын, иктыжымат от кучо-За двумя зайцами погонишься, ни одного не поймаешь*
*2.* Ко пашам ок ыште, тудо ок коч/ *Кто не работает, тот не ест. Кем эшләми, шул ашамый./*
*3.* Жиде тапкыр улчэ, бер тапкыр кис/ *Семь раз отмерь, один раз отрежь. Шым гана висе, ик гана пӱч* /
4. Не имей сто рублей, а имей сто друзей/ *Йөз сум акчаң булганчы йөз дустың булсын. Шудо тенге ынже лий – шудо йолташет лийже/*

**V конкурс** «Назови автора»

Участникам конкурса предстоит назвать писателя либо поэта по его произведению.

Задание 1 команде

1. Басня «Стрекоза и муравей» */Иван.Андреевич Крылов/*
2. Сказка «Шурале» */ГабдуллаТукай/*
3. Рассказ «Кияр». */ НиколайНиколаевичНосов/*
4. Басня «Шына»*/ Герасим Микай/*

Задание 2 команде

1. Сказка «Куянкызы.» / *Абдулла Алиш../*
2. Рассказ «Ванька» / *Антон Павлович Чехов/*
3. Сказка«Малыше кугыжа ўдыр да шым онар»*/Александр Сергеевич Пушкин/*
4. Рассказ « Канде лышташ» */Валентина Александровна Осеева/*

Подведение итогов. Слово жюри. Награждение команд.

## Башлангыч сыйныф укучыларының коммуникатив күнекмәләрен формалаштыруда проект эшчәнлеген файдалану үзенчәлекләре

**Мортазина Л.И.**

*Әгерҗе муниципаль районы*

*Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбенең*

*башлангыч сыйныф укытучысы*

Хәзерге вакытта кешенең аралашу культурасы шәхес формалашуның мөһим сыйфаты, тормышта үз урыныңны табу, уңышка ирешүнең әһәмиятле шарты буларак кабул ителә.Заман кешедән социаль аралашу, тәэсир итешү пространствосын киңәйтүне таләп итә, ә бу, табигый рәвештә, әлеге пространствоны үзләштерү чарасы булган аралашу, коммуникациянең әһәмиятен дә арттыра. Шул рәвешле шәхеснең коммуникатив күнекмәләренә куелган таләпләр дә арта бара. Мәктәпнең мөһим бурычларының берсе буларак укучыларның коммуникатив күнекмәләрен, сәләтен, коммуникатив процессны нәтиҗәле кора белүне күздә тоткан коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру, камилләштерү билгеләнә. Әлеге бурыч мәктәптә укытыла торган төрле предметлар – рус теле, әйләнә-тирә дөнья, музыка, математика һәм башкаларны өйрәнү процессында чишелә. Татар теле һәм әдәбияты дәресләре бу очракта каршылык эчендә калды. Бер яктан караганда, тел һәм әдәбият – аралашу осталыгын формалаштыру, сөйләм культурасын арттыруда иң зур потенциалга ия булган дәресләр. Икенче яктан, заман вазгыяте укучыларда, бигрәк тә ата-

аналарда сорау тудыра: “минем балама татар телендә аралашу осталыгы кирәкме икән? Телнең кулланылыш даирәсе махсус рәвештә чикләнгәннән-чикләнә барганда, татарча уку вакытны бушка уздыру түгелме икән?” Мин үзем тел тирәсендәге вазгыятьне үтә күңелсез, әрнеткеч, әмма вакытлы күренеш, дип саныйм. Шуңа күрә мондый шартларда укучыларымның татар телендә аралашу күнекмәләрен үстерү өчен яңа, кызыклы алым, метод, технологияләргә мөрәҗәгать итүне актуаль дип уйлыйм. Шундый методларның берсе – проектлар методы. Укучылар проект эшчәнлеген оештыру, тормышка ашыруның аерым үзенчәлекләре белән узган ел башкарган проектлардан (“Балалар мәйданчыгы”, “Су – безнең дустыбыз һәм җирдә яшәвебезнең мөһим шарты” һ.б.) таныш булалар. Агымдагы уку елында без 2 нче сыйныф укучылары белән“Мин кышны яратам” проекты өстендә эш алып бардык. Эшебезнең кайбер нәтиҗәләре белән сезне дә таныштырып үтәсем килә.

Проектның максаты түбәндәгечә билгеләнде: укучыларны кыш турында матур, тәэсирле итеп сөйләргә өйрәтү; туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияләү.

Проект барышында шәхескә караган түбәндәге бурычлар чишелде:

1) тирә-яктагы матурлыкны күрә белергә өйрәтү;

2) үз гамәлләреңөчен җаваплылык хисе тәрбияләү;

3) төркемдә бер-береңә ихтирамлы мөнәсәбәт корып эшләргә өйрәтү.

Метапредмет бурычлар буларак түбәндәгеләр билгеләнде:

1) сораштыру, анкета методлары ярдәмендә мәгълүмат тупларга өйрәтү;

2) төркемдә эшләгәндә рольләрне, вазифаларны дөрес бүләргә, нәтиҗәле хезмәттәшлек итәргә өйрәтү;

3) фикерне дәлилле, төгәл итеп җиткерергә өйрәтү.

Предмет бурычлары:

1) “Әйләнә-тирә дөнья”, “Әдәби уку”, “Туган тел” дәресләрендә алган белем һәм күнекмәләрне гамәлдә кулланырга өйрәтү.

Проектка юнәлеш бирүче сораулар белән таныштырып китәм:

Нигез сорау: сез кышны ни өчен яратасыз?

Проблемалы сораулар:

- Кыш көне буш вакытны ничек үткәрергә була?

-Кыш турында китап чыгарсагыз, аны ничек бизәр идегез, нинди материаллар кертер идегез?

Уку-укыту сораулары:

- Кыш турында нинди шигырьләр, табышмаклар беләсез?

- Кышкы рәсем дигәндә, күз алдыгызганиләр килә, сурәтләп бирегез.

Проект эше ориентлаштыру, әзерлек, мәгълүмат туплау, мәгълүматны эшкәртү, проектны гамәлгә ашыру, проект папкасын эшләү, проектны тәгъбир итү кичәсен оештыру, проектны бәяләү, рефлексия этапларыннан торды. Әлеге докладта эшнең һәр этабындагы барышы белән таныштыруны күздә тотмыйм, ә бәлки коммуникатив күнекмәләрне ныгытуда проект эшебезнең потенциалы белән таныштырып китәм.

Эш барышында балалар өч төркемгә бүленде. Һәр төркем өчен үзгә биремнәр тәкъдим ителде. Беренче төркем “Кышның саф һавасы – табигатьнең дәвасы”

дип аталды һәм кыш көнен саф һавада вакытны файдалы үткәрү турында стенгазета чыгарды. Икенче төркем – “Буранлы булса да көн, моңсуланмый ич беркем” девизы астында эшләде, буш вакытны оештыру буенча материал әзерләде. Өченче төркем “Кышның аклыкка һәм алтынга төрелгән әкияти матурлыгы” темасы өстендә эшләп, шул исемдәге кечкенә китапчык чыгарды. Төркемнәрдә эш бүленеше, вазыйфаларны ачыклау, башкарылган эшкә төзәтмәләр кертүне укучылар үзләре хәл итте. Шул рәвешле, проект эше үзара хезмәттәшлеккә корылган коммуникатив күнекмәләрне формалаштыру буенча да эшләүне күзаллавын ассызыклап үтәсем килә. Шуны да искәртеп үтим: төркемнең лидерыннан, укытучының юнәлеш бирүеннән дә күп нәрсә тора. Мәсәлән, проект эше барышында икенче төркем эчендә бәхәсле момент урын алды: бурынлы көндә өйдә ни эшләргә була? Укучыларның тәкъдимнәре күп иде: иң элек китап уку юнәлешендәге эшләр тәкъдим ителде, әмма әлеге аспект өченче төркем тарафыннан башкарылганлыктан, бу тәкъдимнәр кире кагылды. Ары таба, дусларны кунакка чакырып чәй эчү, тәмле пирог пешерү һәм эш барышын презентация рәвешендә башкаларга күрсәтү буенча тәкъдим яңгырады. Әмма әлеге фикер дә уңышлы дип табылмады, чөнки, беренчедән, буранлы көндә кунакка йөрисе килми; икенчедән, пирог пешерүдә төркемнең барлык әгъзаларын да катнаштыру авырлык тудырачак. Ниһаять, укучылар өстәл уенын тәкъдим иттеләр, уйлаша торгач, кышкы темага туңдырма таякчыклары ярдәмендә эшләнгән паззллар ясап, башка төркемнәргә бүләк итү идеясен яклап чыктылар. Күмәк аралашу үпкәләшүсез генә оптималь фикергә килергә ярдәм итте. Өлге итеп алынган рәсемне кушымтада тәкъдим итәм.

Проект эшен башкару олылар (ата-аналар, күршеләр, туганнар, мәктәп укытучылары) белән коммуникатив мөнәсәбәтләргә керүне дә күздә тота. Өченче төркем укучылары китап өстендә эш башлар алдыннан балалар һәм олыларның әлеге китапка булган ихтыяҗларын ачыклау өчен анкета-сораштыру уздырдылар. Биреләчәк сораулар шулай ук төркем эчендә хәл ителде. Укучыларның эшләре буенча түбәндәге нәтиҗәләр билгеләнде: олыларның күбесе кыш турында 1-2 табышмак, 1-2 җыр белә. Балалар белән уку яисә яңа ел кичәсе өчен ятлау ихтыяҗы туганда, күбесе Интернетка мөрәҗәгать итә, әмма бу күбрәк укытучы таләбе белән эшләнә. Ял көннәрендә буш вакытны оештыру максаты белән беркем дә кыш турындагы материал эзләү белән шөгыльләнми. Шуларны истә тотып, укучылар “Кышның аклыкка һәм алтынга төрелгән әкияти матурлыгы” китабының актуаль икәнен дәлилләделәр. Эш вакытында мөстәкыйль рәвештә мәгълүмат туплап, китапка алар тарафыннан кыш турындагы табышмаклар кертелде, кроссворд төзелде, берничә шигырь теркәлде, кыш турындагы җыр да урын алды. Китап укучыларның кышкы тематикага кагылышлы рәсемнәре, төсле фотосурәтләр белән бизәлде.

Проект эшен тәкъбир итү аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнүне дә күздә тота. Дусларың, таныш һәм таныш булмаган кешеләр алдында чыгыш ясый, үз фикереңә ышандыру, аны тәэсирле һәм дәлилле итеп җиткерә белү – заман кешесенең үтә дә әһәмиятле сыйфаты ул. Әлеге проект эшенең нәтиҗәләре турында укучылар сыйныфташлары һәм эти-әниләр алдында чыгыш ясадылар.

Һәр төркем үзенең эше турында бәян итте, стенгазета, паззл, китапларын күрсәтте, нәкъ менә үзенең эшенең әһәмиятен аңлатырга тырышты. Эшебездәге тагын бер мөһим моментка тукталып китәсем килә. Проект эшен тәкъбир итәргә әзерләнгәндә, мин укучыларымны көтелмәгән сораулар алдында югалып калмаска өйрәтәм, "сез бу эшне бөтен йөрәгегезне биреп, чын күңелдән башкардыгыз, димәк, сез җавап бирә алмаслык сораулар юк", – дип тынычландырам. "Әгәр сорау бирүче темадан читкә китә икән, сез җавабыгызда шул хакта әйтә аласыз", – дип кисәтәм. Эшемнең нәтиҗәләрен дә күрәм. Әйтик, "Мин кышны яратам" проектын тәкъбир итү барышында китап чыгаручы төркемгә "Кыш турында нинди әкиятләр беләсез?" дигән сорау бирелде. Уку дәресләрендә, рус әдәбияты дәресләрендә укучылар, әлбәттә, мондый әсәрләр белән танышалар, һәрхәлдә, Һ.К.Андерсенның "Кар патшабикәсе" ("Снежная королева") әкияте укучыларга таныш. Әмма җаваплы минутта укучылар, күрәсең, аның турында оныттылар, әмма югалып калмадылар: "Без кыш турында әкиятләрне өйрәнүне максат итеп куймадык, әмма икенче проектны башкарганда, сезнең теләкне истә тотып, шушы сорауга да җавап бирәчәкбез", – дип җавап кайтардылар. Әлбәттә, укучы сорауга җавап итеп әкиятне атаса, уңышлырак булыр иде, мондый тип сорауларга җавапны алдан әзерләргә мин дә тәкъдим итәргә тиеш булганмындыр. Әмма хәзерге заманда әзер белемнәр суммасына ия булудан бигрәк мәгълүмат дөньясы эченнән кирәклесен табып эшкәртү, куллану күнекмәсе әһәмиятлерәк булу күзлегеннән караганда, укучының җавабы да уңай бәягә лаек.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: хәзерге вакытта республикабызда татар мәктәпләренең саны күп түгел. Без шул азчылыкка кергәнлектән, үзебезгә йөкләнгән җаваплылыкны тулысынча аңлап, укучыларның татар телендә коммуникатив мөнәсәбәтләр кору күнекмәләре өстендә эшне активлаштырырга тиешбез. Мин, үз эш тәҗрибәмнән чыгып, проектлар методына зур өметләр баглыйм. Әлеге докладымның максаты да эшемдә соңгы булып оештырылган проект эше мисалында аның укучыларның үзара, олылар белән коммуникатив мөнәсәбәтләр кору күнекмәләрен формалашытрудагы һәм аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәтүдәге ролен күрсәтүдән гыйбарәт. Минем тәҗрибәм сезне кызыксындырса, эшегездә куллана алсагыз, мин бик шат булыр идем.

Кушымта




**“Ашамлыклар”**

*(дәрес планы)*

**Мулланурова Лариса Данифовна,**
*Менделеевск шәһәре 3 нче урта мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Дәрес максатлары:**

**Укытучы өчен**: “Ашамлыклар” темасына караган лексиканы ныгыту; чагыштыра, нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү; кешеләр белән итагатьле аралашырга, сөйләшергә өйрәтү.

**Укучы өчен: “**Ашамлыклар” темасы буенча лексиканы өйрәнү; ашханәдә, кибеттә үзеңә кирәк булган ашамлыкларны татар телендә сорап алырга өйрәнү.

Җиһазлау: А3форматында кәгазь ; дәреслек: Күңелле татар теле (рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбе) 3нче сыйныфы өчен дәреслек(рус балалары өчен), Р.З.Хайдарова,Г.М.Ахметзянова, Л.А.Гиниятуллина Казан:Татармультфильм,2014.

Дәрес барышы:

1. Оештыру өлеше:

1) Уңай психологик халәт булдыру.

-Исәнләшү.

-Исәнмесез.

-Хәерле көн.
-Исән,имин үтсен көнебез.

2. Актуальләштерү. МЭНЭДЖ-МЭТ куллану

3. Уку мәсьәләсен кую.
СИ-ФИНК-УАНДЭ структурасы
Укучылар:
1) Мин нәрсә күрәм?
2) Мин нәрсә уйлыйм?
3) Мин нәрсә турында уйланам? - дигән сорауларга җавап бирәләр
Бу эшкә 2 -3 минут вакыт бирелә.

4. Уку мәсьәләсен чишү:
Дәрес темасын билгеләү.
-Димәк, бүгенге дәреснең темасы “Ашамлыклар”

5.ФИНК РАЙТ РАУНД РОБИН.
Укучылар алдында бурыч куела: һәрбер укучы, сөйләшмичә, ашамлыклар эчемлекләр, яшелчәләр,җиләк-җимешләрнең исемлеген язып куя.
Бу эшкә 3 - 4 минут вакыт билгеләнеп куела.
Вакыт узганнан соң укучылар чиратлашып сөйлиләр: беренче номерлар бар исемлекне укып чыга, ә калган укучылар үз исемлекләрендә булмаган сүзләрне өстәп баралар. Шулай итеп : һәр укчы яза-укый һәм фикер алыша.
Бу эш өчен дә вакыт билгеләнә: Һәр укучы 30секунд сөйли.

**Укытучы.**
-Әйдәгез тикшерик әле: 1нче номерлар сөйли.
-Ә хәзер, карыйк әле кайсыларын исегездә калдырдыгыз икән.

5. МИКС - ФРИЗ - ГРУП ( Ял итү өлеше. )
Укучылар музыка астында хәрәкәтләнәләр. Музыка туктагач парлашып басалар һәм “Син нәрсә яратасың?” соравына җавап бирәләр, үз фикерләрен җиткерәләр ( вакыт исәпләнә 3 минут )

6.РАФТ.
Төркемдә эшләү һәм проект эшен яклау.
Укучылар алдында проблема куела: меню төзү
№1өстәл спортсменнар өчен
№2өстәл-кунаклар өчен
№3өстәл-балалар өчен
№4 өстәл-өлкәннәр өчен
Укучылар меню төзиләр һәм бергәләп рәсемнәр ясап бизиләр дә.
Һәр өстәлдән 2нче номерлар сөйли һәм үз эшен яклый.

Бу эшне башкару өчен дә вакыт билгеләнә: 10 минут

КОНЭРС куллану.
Сиңа нинди ризыклар күбрәк ошый? Ни өчен? ( укучылар нинди ризыклар күбрәк ошаганын аңлаталар)
Укучылар үзләре сайлаган почмакка басалар(итле ризык,баллы ризык,яшелчәләр, җимешләр ) һәм парлашып бер-берсенә аңлаталар),3минут бирелә.
Укучы: өчпочмак тәмле,йомшак ...

7.Йомгаклау өлеше.
-Укучыларның белемнәрен бәяләү.
-Дәрестә катнашуыгызга карап үзегезгә билге куегыз

8. Өй эше бирү:
- рәсем яса һәм ашамлык исемнәрен яз;
- дустыңа меню төзе (составь меню для друга)

**9.Рефлексия.**
Парковкага төсле кәгазь ябыштыралар.
Сез ике төстәге кәгазь битләрен күрәсез. Әгәр сезгә дәрес ошаса, яшел кәгазьне ябыштырыгыз. Әгәр дәрес материалын аңлап, берәр сораугыз калса сары кәгазьне ябыштырыгыз.

Дәрес шуның белән тәмам. Рәхмәт. Сау булыгыз!

## “Без ашханәгә барабыз”

*(3 класс)*

**Нуркаева Гөлнур Флит кызы,**
*Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 9нчы урта гомуми белем мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Предмет:** татар теле.
**Сыйныф**: 3а, рус төркеме.
**Тема:** Без ашханәгә барабыз.
**Планлаштырылган нәтиҗәләр**: Шәхси: татар телен куллануга уңай караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге формалаштыру, татарча аралашуга тарту.

Танып-белү: биремнәрне үтәү, тиешле мәгълүматны сайлап алу, объектларны чагыштыру, фикерне логик чылбырга салу.

Коммуникатив: укытучы сөйләмен тыңлау һәм аңлау, диалог төзүдә катнашу, фикерне дәлилли итеп җиткерә белү, мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару.

Регулятив: дәреснең темасын һәм максатын формалаштыру, ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру, эш сыйфатына бәя бирә белү, нәтиҗә ясый алу.

Предмет буенча: Өйрәнелгән барлык төзелмәләрне яңа дидактик материаллар, ситуатив күнегүләр, ишетеп аңлау күнегүләре аша куллана белү.

**Эшне оештыру:** Фронталь, төркемдә, парларда, индивидуаль.

**Ресурслар**: проектор, компьютер, электрон презентация, биремле карточкалар.

**Дәрес барышы:**

**1. Оештыру. Мотивлаштыру.**

1) *Уңай психологик халәт булдыру*.

- Исәнмесез, укучылар!
- Хәерле көн!
- Хәлләрегез ничек?
- Бүген сыйныфта кем дежур?

2) *Фонетик күнегү*.

Чәй, чәкчәк, бәлеш, гөбәдия.

**2. Өй эшен тикшерү.**

Ш. Галиевның “Кунаклар” шигырен сәнгатьле уку.

**3. Уку мәсьәләсен кую.**

- Укучылар, хәзер экрандагы кроссвордны чишәбез һәм бүгенге дәреснең темасын белербез. (3 слайд)

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | п | ы | ч | а | к | | | |
| | | | | к | а | ш | ы | к | | |
| | | | | | | х | ө | р | м | ә |
| | | | | | | а | ш | | | |
| | | | | ч | ә | н | е | ч | к | е |
| т | ә | л | и | н | к | ә | | | | |

- Нинди сүз килеп чыйты?
- Ашханә.
- Без бүген ашханәгә барырбыз, ләкин башта безгә биремнәр үтәргә кирәк булачак. Сез әзерме?
- Әйе.

**4. Уку мәсьәләсен чишү.**

1) *Татар халык ашлары.*

“Джот тотс” структурасы.

- Татар халык ашлары исемнәрен язарга.
- Предложите соседу по парте любое блюдо из списка.

2) *Җөмләләр төзү.*

– Экранга карагыз. Беренче рәт нәрсә? икенче рәт нинди? өченче рәт нишли? соравына җавап биргән сүзләрне аерып языгыз. (4 слайд)

- Хәзер төрле рәттә утыручы укучылар очрашыгыз һәм шул сүзләр белән җөмләләр төзегез.

3) *Сүзләрне төркемнәргә бүлү.*

- Хәзер 1 нче вариантта утыручы укучылар эчемлекләрне, ә 2 нче рәттә утыручы укучылар ашамлыкларны күчереп язалар.

- Предложите партнеру по плечу эти продукты.

4) *Артык сүзне табу.*

- Слайдта бирелгән сүзләрдән артык сүзне табыгыз.

- Шул сүзләр белән җөмләләр төзегез.

5) *Тәрҗемә эше.*

Слайдта бирелгән җөмләләрне тәрҗемә итегез.

6) *Физкультминут.*

7) *Ситуатив күнегүләр.*

Спроси у друга, какие каши он любит.

Спроси у друга, какие супы он любит.

Спроси у друга, что он сегодня ел.

Спроси у друга, что варит его мама.

8) *“Снежный ком” уены.*

Мин ашыйм җөмләсен киңәйтеп язарга.

9) *Диалогик сөйләм.*

“Микс пэа шэа” структурасы.

Бирелгән шаблоннар буенча диалог төзиләр.

10) *Тест*.

1. Выбери правильный перевод: **От стола.**

А) өстәл янына

Ә) өстәл янында

**Б) өстәл яныннан**

2. Выбери правильное окончание: Ашханә... (кайда?) бик тәмле пешерәләр.

**А) –дә**

Ә) –дән

Б) –гә

3. Выбери правильный перевод: **К столу.**

**А) өстәл янына**

Ә) өстәл янында

Б) өстәл яныннан

4. Выбери лишнее слово.

А) кыстыбый

Ә) коймак

**Б) кесәл**

5. Выбери нужное слово. Марат ботка ... башлады.

**А) ашый**

Ә) яза

Б) укый
6. Выбери правильный вопрос к слову ***тәмле.*** Кәбестә ашы бик тәмле булды.
А) нәрсә?
**Ә) нинди?**
Б) кайда?
7. Найди вопросительное предложение.
А) Ашханәдә тәмле пешерәләр
**Ә) Аш тәмле булганмы**
Б) Мин дөге боткасы яратам
**5. Рефлексия.**
- Дәреснең темасы нинди иде?
- Без бүген дәрестә нишләдек?
- Кемгә дәрес җиңел булды?
- Кемгә дәрес авыр булды?
**6. Укучыларның белемнәрен бәяләү.**
**7. Өй эше.**
1 нче рәт – иртәнге аш өчен меню төзи.
2 нче рәт – көндезге аш өчен меню төзи.
3 нче рәт – кичке аш өчен меню төзи.

## Татар әдәбиятыннан планлаштырылган метапредмет нәтиҗәләрен бәяләү өчен контроль-диагностик материаллар

***XX гасыр 20-30 нчы еллар татар әдәбияты***

**Ризванова Ә. Ә.,**
**НогмановаГ.Ф.,**
*Әгерҗе шәһәре 1нче гимназиясенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Әдәбият мәктәптә төп предметларның берсе булып тора. Гамәлдә булган укыту программаларында һәм дәреслекләрдә предметны укытуда планлаштырылган метапредмет нәтиҗәләрен бәяләү һәм контроль-үлчәү материаллары җитәрлек дәрәҗәдә эшләнелмәгәнлеге күзәтелә.

Укытучылар тема һәм төркемнәр белән эшне планлаштыруда коммуникатив компетентлыкны тәэмин итүче уку предметының эчтәлеген яңартуны һәм яңа бәяләү критерийларын күздә тоткан контрольне оештыруда авырлыкларга очрыйлар.

Бүгенге көндә татар әдәбиятыннан ФДББСка нигезләнгән контроль-үлчәү материаллары юк дәрәҗәсендә. Шул сәбәпле без әлеге проблеманы чишү юлларын эзләдек һәм предметны укытуда планлаштырылган метапредмет нәтиҗәләрен бәяләү һәм контроль-үлчәү материаллары эшләдек.

Бу материаллар түбәндәгеләргә юнәлтелгән:

1. Мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә төрле чыганаклардан (интернет ресурслардан, энциклопедияләрдән, масса-күләм мәгълүмат чараларыннан, ЦОРдан) таба белү;
2. “20-30 нчы еллар әдәбияты” темасы буенчаматериалларны сайлап алу һәм системалаштыру алымнарын үзләштерү;
3. Мәгълүматны мөстәкыйль эзләү, аны сайлау һәм анализлау күнекмәләре булдыру;
4. Фикерне язма һәм сөйләмә формада төгәл, иркен, дөрес, урынлы әйтә белү.

Әлеге җыентыктагы биремнәр материалны үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү буенча объектив мәгълүмат алу максатыннан бирелгән бер ситуациядә тел проблемаларын чишүдә шәхеснең уникаль мөмкинлекләрен ачуга ярдәм итә. Ул күләме ягыннан зур булмаган фәнни һәм әдәби текстлар төзү, аларны кыскача һәм тулы итеп сөйләү, темасын, идеясен билгеләү, текст өстендә эшләү өчен гади план төзү, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белү кебек биремнәр укучыларның формалашкан компетентлык дәрәҗәсен билгеләүне күздә тота.

Программаны тормышка ашыруның нигезе - эшчәнлеккә системалы якын килү. Ул укучының шәхси үсешенә юнәлтелгән универсаль уку гамәлләрен үзләштерүне, дөньяны танып-белүне, индивидуаль яшь, психологик һәм физиологик үзенчәлекләрне күздә тотып, башлангыч, төп һәм уртабелем бирүдә дәвамчанлык принцибына нигезләнә.

Кешене иҗат итәргә мәҗбүр итеп булмый. Әмма безнең бурыч- укучыда иҗатка теләк- мотивация булдыру, аларны үзләренең кечкенә, бәлки (кем белә?) зур ачышларын ясарга ярдәм итү, яңалыкка омтылучы, эзләнергә, үзлегеннән белем алырга сәләтле, үзаңы үскән, үз-үзенә тәнкыйди карашлы шәхес тәрбияләү.

Дидактик материаллар җыентыгы рус мәктәбенең 11нче сыйныфында укучы татар балалары белән эшләүче укытучыларга кулланма була ала.

Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка заман
өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка
бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр.
*Ризаэтдин Фәхреддин*

## Сәләтле балалар белән эшләү

**Садыкова А.Н.**

*Менделеевск шәһәре*

*1нче урта мәктәбенең*

*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Хәзерге чорда дөнья күләм мәсьәләләр хакында фикер йөртерлек шәхес тәрбияләү аеруча әһәмиятле. Төрле телдәге фәнни чыганаклардан мәгълүматлар туплап, үз карашын берничә телдә аңлатып бирә алырлык киләчәк кешесен тәрбияләү төп бурыч булып тора. Яшьләр безнең икътисадны, сәнгатьне, фәнне алга җибәрәчәк". Безнең балаларыбыз тиз үсә. Укыту өлкәсендә сәләтле балаларны табу һәм аларның эшчәнлеген үстерү – хәзерге көндә төп бурычларның берсе булып тора. Без баланың сәләтен никадәр тизрәк күреп алабыз, үстерәбез, уңай шартлар тудырабыз, шул очракта гына көтелгән уңышларга ирешә алабыз. Хәзерге заман шартларында сәләтле балалар белән эшләү системасы зур җаваплылык сорый дип әйтергә кирәк. Ни өчен дигәндә, һәрбер кеше үзенең мөмкинлекләреннән, үз кызыксынуларыннан чыгып, киләчәк һөнәр сайлый, олы тормыш юлына аяк баса.

Һәр уңышка ирешүнең сәләт-талант нәтиҗәсе генә түгел, ә тырышлык нәтиҗәсе икәнен беләбез. Баланың сәләтен дөрес юнәлештә үстергәндә ул берничә өлкәдә үзенең талантын күрсәтә ала. Укытучыларга балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булуын белү бик мөһим. Алардан сәләтле балаларның күңелен аңлау, аларның үсешенә көч-куәт бирерлек эшләр башкару, шәхси якын килү таләп ителә. Мөгаллимнәр укучылар белән эшләгәндә берничә принципны күздә тотырга тиешләр.

Аларның беренчесе – укучыларның белем үсеше дәрәҗәсен бик тиз һәм төгәл билгеләү һәм шуның белән бәйләнешле рәвештә, дәресләрнең тема һәм формаларын планлаштыру вариантларын төгәл фәнни нигезләп сайлап алу.

Икенчесе – дәрестә дифференциале укытуны фәнни нигездә гамәлгә ашыру, үсеш дәрәҗәләре һәм әзерлекләре төрлечә булган укучыларның тиешле белем алуына ирешү, дәресләрдә нинди алым һәм эш формалары кулланырга кирәклеген билгеләү.

Өченчесе – дәрестә укытучы-укучы дуслыгын тагын да нәтиҗәле итү юлларын табу.

Акыл сәләтен эшкә җигү – шулай ук хәл итәсе мәсьәләләрнең берсе. Бу – туктаусыз алга бару мөмкинлеге тудыру дигән сүз.

Сәләтле балалар белән эшләгәндә нинди алымнар кулланыла һәм аларның нәтиҗәлелеге нинди?

Терәк схемалар (конспектлар) – үзара нык бәйләнештәге сораулар яки тема буенча кыскача нәтиҗәләр системасы ул. Алар укучыларга теманы аңлату алдыннан өләшенә һәм балалар укытучы сөйләгәннәрдән җавап эзлиләр яки тема нәтиҗәләрен таба баралар. Әлеге конспектларда көчлерәкләр өчен текстлы биремнәр яки өстәмә сораулар бирелә. Мондый укытуның уңай нәтиҗәсе бар. Сәләтле балалар да, уртача белем алучылар да биремнәрне бик теләп үтиләр, сорауларга җавап табалар. Шулай итеп аларның белеме тирәнәя.

Текстлы биремнәр, шулай ук тестлар да киң кулланыла. Укучы үзе дөрес дип санаган җавапның берсен сайлап ала. Сәләтле балаларга катлаулырак, эзләнә торган сораулар яки җаваплар тәкъдим итәргә мөмкин. Балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булулары укучыларның бер-берсенең белемен тикшерү, проектларны яклау, дәрес-конференцияләрдә, семинарларда ачык күренә. Мәсәлән, дәрес-семинарларны алыйк. Һәр баланы актив катнаштыру – дәреснең төп таләбе. Алардан өстәмә әдәбият белән җитди мөстәкыйль эш (яңа чыганакларны уку, материалларны чагыштыру, кызыклы мәгълүматлар сайлап алу) таләп ителә.

Эшләү методларымның тагын берсе – кроссвордлар. Кроссворд чишү -җиңел эш. Ә аны төзү – авыр, катлаулы; укучыдан тырышлык һәм эзләнү сорый. Сүз төркемнәрен, кош-корт, җәнлек, агач исемнәрен өйрәнгәндә укучылар кроссвордларны бик рәхәтләнеп төзиләр. Аларны төзегәндә табышмаклар куллану тел дәресләрен әдәбият дәресләре белән бәйли. Әлеге кроссвордларны халык авыз иҗаты әсәрләрен үткәндә куллану яхшы нәтиҗә бирә. Шулай ук сочинение язу, шигырь, хикәя, әкиятләр уйлап чыгару укучыларның иҗади фикерләү дәрәҗәләрен үстерә, сүзлек запасын баета, сөйләм телләрен үстерә.

Сәләтле балалар белән эшләүнең төп максаты: һәр укучының сәләтен, иҗади башлангычын үстерү. Мондый укучылар белән эшләгәндә эзләнергә, яңа мөмкинлекләрдән файдаланырга туры килә.

Шактый еллар инде мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадалар үткәрелә. Олимпиадаларга әзерләнгәндә, төрле эш алымнары кулланыла. Укытучы белән укучы арасындагы әңгәмәләр, фикер алышулар, тест биремнәрен үтәү, яңа чыккан фәнни китаплар, методик кулланмалар белән танышып, өйрәнеп бару зур әһәмияткә ия. Дәресләрдә бу укучыларга, темаларны үткән вакытта, өстәмә чыганаклардан файдаланырга, иҗади эзләнергә кушыла.

Фәнни конференцияләргә әзерләнүнең дә укучылар сәләтен үстерүдә зур әһәмияте бар. Бирелгән тема буенча укучы өстәмә чыганаклардан файдаланып әзерләнә. Үзен кызыксындырган сорауларга җавап эзли. Теманы тулысынча ачып бирү өчен, берничә чыганактан файдалана. Үзенең дәлилләрен берничә галимнең фикерләре белән ачыклый. Монда укучының мөстәкыйль фикер йөртүен, эзләнүен, нәтиҗә ясавын ассызыклап үтәргә кирәк

Белгәнебезчә, укыту өлкәсендә сәләтле балаларны табу һәм аларның эшчәнлеген үстерү – хәзерге көндә төп бурычларның берсе булып тора. Без баланың сәләтен никадәр тизрәк күреп алабыз, үстерәбез, уңай шартлар тудырабыз, шул очракта гына көтелгән уңышларга ирешә алабыз.

Хәзерге заман шартларында сәләтле балалар белән эшләү системасы зур җаваплылык сорый . Ни өчен дигәндә, һәрбер кеше үзенең мөмкинлекләреннән, кызыксынуларыннан чыгып, үзенә һөнәр сайлый, олы тормыш юлына аяк баса.

Укучыларның иҗади казанышлары – бу мәктәпнең җимеше. Авыл җирендә шәһәрдәгегә караганда үз-үзеңне үстерү өчен мөмкинлекләр чикле, шуңа күрә сәләтле балаларны ачыклау, югалтмыйча үстерү укытучы өлешенә төшә.

Мөгаллимнәргә һәм тәрбиячеләргә балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булуын белү бик мөһим. Алардан сәләтле балаларның күңелен аңлау, аларның үсешенә көч-куәт бирерлек эшләр башкару, шәхси якын килү таләп ителә. Мөгаллимнәрне гадәти мәктәптә сәләтле балалар белән эшләү, аларга ничек итеп шәхси якын килү, малайлар һәм кызларны индивидуаль программа белән укыту мәсьәләләре кызыкксындыра. Бу юнәлештә эшләгәндә, берничә мәсьәләне хәл итәргә кирәк була. Аларның беренчесе – укучыларның белем үсеше дәрәҗәсен бик тиз һәм

төгәл билгеләү һәм шуның белән бәйләнешле рәвештә, дәресләрнең тема һәм формаларын планлаштыру вариантларын төгәл фәнни нигезләп сайлап алу, ягъни методиканы төгәл бер төркем, сыйныф яки укучы үзенчәлекләре белән килештерү механизмын булдыру. Икенчесе – дәрестә дифференциале укытуны фәнни нигездә гамәлгә ашыру, үсеш дәрәҗәләре һәм әзерлекләре төрлечә булган укучыларның тиешле белем алуына ирешү, дәресләрдә нинди алым һәм эш формалары кулланырга кирәклеген билгеләү. Өченчесе – дәрестә укытучы-укучы дуслыгын тагын да нәтиҗәле итү юлларын табу. Акыл сәләтен эшкә җигү – шулай ук хәл итәсе мәсьәләләрнең берсе. Бу – туктаусыз алга бару мөмкинлеге тудыру дигән сүз.Сәләтле балалар белән эшләгәндә нинди алымнар кулланыла һәм аларның нәтиҗәлелеге нинди? Терәк схемалар (конспектлар) – үзара нык бәйләнештәге сораулар яки тема буенча кыскача нәтиҗәләр системасы ул. Алар укучыларга теманы аңлату алдыннан өләшенә һәм балалар укытучы сөйләгәннәрдән җавап эзлиләр яки тема нәтиҗәләрен таба баралар. Әлеге конспектларда көчлерәкләр өчен текстлы биремнәр яки өстәмә сораулар бирелә. Мондый укытуның уңай нәтиҗәсе бар. Сәләтле балалар да, уртача белем алучылар да биремнәрне бик теләп үтиләр, сорауларга җавап табалар. Шулай итеп аларның белеме тирәнәя. Текстлы биремнәр, шулай ук тестлар да киң кулланыла. Укучы үзе дөрес дип санаган җавапның берсен сайлап ала. Сәләтле балаларга катлаулырак, эзләнә торган сораулар яки җаваплар тәкъдим итәргә мөмкин. Балаларның ни дәрәҗәдә сәләтле булулары укучыларның бер-берсенең белемен тикшерү, проектларны яклау, дәрес-конференцияләрдә, семинарларда ачык күренә. Мәсәлән, дәрес-семинарларны алыйк. Һәр баланы актив катнаштыру – дәреснең төп таләбе. Алардан өстәмә әдәбият белән җитди мөстәкыйль эш (яңа чыганакларны уку, материалларны чагыштыру, кызыклы мәгълүматлар сайлап алу) таләп ителә. Олимпиадалар уздыру – укучыларның иҗади һәм танып белү сәләтен активлаштырырга, талантлы балаларны ачыкларга мөмкинлек бирә, белем туплау белән кызыксынуны арттыра. Олимпиадаларга әзерләнгәндә, төрле эш алымнары кулланыла. Үзенең дәлилләрен берничә галимнең фикерләре белән ачыклый. Монда укучының

мөстәкыйль фикер йөртүен, эзләнүен, нәтиҗә ясавын ассызыклап үтәргә кирәк. Укучыларның иҗади сәләтен үстерүдә иҗади дәресләр, иҗади биремле күнегүләр, биремнәр зур роль уйный. Мәсәлән, сочинение язу, шигырь, хикәя, әкиятләр уйлап чыгару укучыларның иҗади фикерләү дәрәҗәләрен үстерә, сүзлек запасын баета, сөйләм телләрен үстерә. Бары тик сәләтле балалар белән эшләгәндә генә, мөгаллим үзе дә күп нәрсәгә өйрәнә, белемен тирәнәйтә, тәҗрибә туплый.

## «Сәламәт бул!»

***(1 нче сыйныф, рус төркеме)***

**Садыкова Гөлнур Рәис кызы,**
*Зәй муниципаль районы*
*6 нчы урта гомуми белем мәктәбе,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Технологик карта

| | |
|---|---|
| **Укытучы** | Садыкова Гөлнур Рәис кызы |
| **Предмет** | Әдәби уку |
| **Сыйныф** | 1 д, рус төркеме |
| **Вакыты** | 14 нче март , 2017 ел |
| **Тема** | Сәламәт бул! |
| **Дреснең тибы** | рефлексия |
| **Максат** | Сәламәт булу өчен киңәшләр бирә белү. Авыру кешенең хәлен сорау, аңа дару, чәй тәкъдим итә белү күнекмәләрен формалаштыру |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | **Шәхескә кагылышлы:** эшчәнлекнең максаты һәм нәтиҗәсе арасында бәйләнешне билгеләү; мөстәкыйль фикер йөртүгә омтылу; һәр эшне ахырына кадәр җиткерә белү, сәламәт булырга йогынты ясау. - эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү; рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;<br>**Метапредмет:**<br>***Танып-белү:***<br>- булган белемнәрне куллана белү;<br>- өйрәнгәннәрдән чыгып сорауларга җавап табу;<br>- чагыштыру, нәтиҗә ясау. |

| | |
|---|---|
| | ***Коммуникатив :***<br>- фикереңне телдән әйтә белү, башкаларның сөйләмен тыңлау һәм аңлау;<br>- парларда аралаша, эшли белү.<br>***Регулятив***:<br>- дәрес бурычын һәм максатын формалаштыру;<br>- үз фикереңне әйтү;<br>- эшчәнлекне планлаштыру, контрольдә тоту, бәяләү;<br>- танып – белү эшчәнлеген формалаштыру.<br><br>**Предмет буенча:** Сәламәт булу темасынүзләштерү |
| **Эшне оештыру** | Фронталь, төркемнәрдә, индивидуаль,парларда. |
| **Ресурслар** | “Татар теле”. 1 сыйныф өчен дәреслек, презентация, ноутбук, проектор, мультимедиа дәреслеге. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре (УУГ) |
|---|---|---|---|
| **1. Оештыру. Мотивлаштыру.**<br>Максат: уңай психологик халәт тудыру. | -Исәнмесез, укучылар! Кәефләрегез ничек?<br>-Әнә кояш та безгә карап елмая.Сездә бер- берегезгә уңышлар теләгез.<br>Фонетик зарядка. | Сыйныф эшкә әзерләнә (укытучыны сәламлиләр).<br>-Исәнмесез!<br>-Кәефләребез яхшы.<br>Кояшлы иртә кебек<br>Тукай телен – татар телен<br>Өйрәнергә без килдек. | ШУУГ: бер-берсенә уңышлар теләү.<br>КУУГ: укытучы һәм сыйныфташлар белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;<br>РУУГ: эш урынын оештыру. |
| **2. Белемнәрне актуальләштерү.**<br>Максат:яңа белем алуга әзерлекне тикшерү. | Дәресебезне башлыйбыз. Игътибарыгызны экранга юнәлтегез.Үткән дәрестә өйрәнелгән | Укытучының сорауларына җавап бирәләр.<br>Экраннан иллюстрацияләр карау. сорауларга җавап бирәләр, сөйләм эшчәнлегенә кушылалар.<br>-бу –чәч. | КУУГ: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү; башкаларның фикерләрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | теманы искә төшерү.<br>-Бу нәрсә?<br>-Шушы тән әгъзаларын I,II,III затта төрләндерик әле. | - бу- баш....<br>-Минем башым, синең башың... | тыңлый, аңлый белү; |
| **3.Проблемалы сорауны ачыклау өчен сынап карау этабы.**<br>Максат: укучының нинди авырлык белән очрашуын билгеләү. | -Оля, синең башың авыртамы?<br>.- Ә менә без караячак мультфильмда куян кызы авырган.Ни өчен авырган икән?Шуны белер өчен игътибар белән карагыз. | -Юк, минем башым авыртмый..<br><br>Мультфильм карау. | ТБУУГ: танып белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау;<br>КУУГ: үзенең карашын әйтә һәм дәлилли белү;<br>РУУГ: дәреснең темасын формалашты ру. |
| **4. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**<br>Максат: кыенлыктан чыгу юлларын ачыклау. | -Укучылар, мультфильм ошадымы?<br>-Куян кызы нишләгән?<br>-Әнисе сүзен тыңлаганмы?<br>-Әнисе сүзен тыңламагач, кайсы җире авырткан?<br>- Димәк, әниләрнең сүзен тыңласаң, сәламәт буласын.<br>-Шулай итеп буген дәрестә нәрсә турында сөйләшәчәкбез? | Укучыларның җавапларын тыңлау.<br>Җавапларны табалар һәм әйтәләр.<br><br>Бирелгән сораулардан чыгып, дәреснең темасын билгелиләр<br><br>-Сәламәтлек.Сәламәт бул! | ТБУУГ: нәтиҗә ясау, гомумиләште рү;<br>КУУГ: башкаларның фикерләрен тыңлый, аңлый белү, үз фикереңне дәлилләп башкаларга җиткерә белү;<br>РУУГ: уку мәсьәләсен дөрес аңлау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **5) Планны тормышка ашыру.** | Дәреслек белән эш.55 нче бит.<br>-Рәсемдә нәрсәләр күрәсез?<br>-Алар кем янына килгән?<br>-Хайваннарның кайсы җирләре авырта?<br>-Вика, этнең кай җире авырта?<br><br>-Ребята, животные пришли к доктору Айболиту и каждый говорит о том, что у них болит. Как вы думаете, что они говорят. Представьте что я Айболит .Подойдите ко мне и говорите. | Укытучының сорауларына җавап бирәләр.<br>Әкият геройлары турында сөйләшәләр.<br><br>Биремнәрне мөстәкыйль рәвештә эшлиләр.Чиратлап дөрес җавапны әйтәләр. | ТБУУГ: дәреслектән кирәкле информацияне табып аера белү;<br>КУУГ: башкаларның фикерләрен тыңлый, аңлый белү, үз фикереңне дәлилләп башкаларга җиткерә белү; |
| **Ял минуты** | | | |
| **6)Беренчел ныгыту.** | Мин сезгә сәламәт бул дип теләдем.Доктор Айболитта шул теләкләрне тели.Сәламәт булу өчен ниләр эшләргә кирәк? Шуны белер өчен сезгә “Пазлы”уены тәкъдим итәм.Без доктор Айболит киңәшләрен белербез.<br>. | Укытучыны тыңлыйлар, ишетеп аңларга тырышалар, мөстәкыйль эшлиләр.<br>Әйтелгән ситуация буенча<br>җөмлә төзеп тактага беркетү. | ШУУГ: активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә өйрәнү;хезмәтне ярату хисләре булдыру;<br>ТБУУГ:кирәкле информацияне таба белү;<br>КУУГ: башкаларның фикерләрен тыңлый, аңлый белү,<br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **7)Үз – үзеңне тикшерү өчен мөстәкыйль эш.** | Һәр төркем темага кагылышлы ситуатив бирем эшли. | Укучылар парларда эшлиләр. | ШУУГ: активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә өйрәнү; хезмәтне ярату хисләре булдыру.<br>ТБУУГ: төп фикерне аерып чыгара белү;<br>КУУГ: башкаларның фикерләрен тыңлый, аңлый белү, үз фикереңне дәлилләп башкаларга җиткерә белү;<br>РУУГ: мөстәкыйль эшли белү; үзбәя; |
| **8)Белемнәрне системага салу.** | Иҗади бирем эшлибез. Һәр төркем сәламәт бул темасына караган рәсемнәрне сайлый һәм А3 форматындагы биткә беркетеп куя.<br>Дәрестә өйрәнгәннәр буенча һәр төркем үзенең мини проект эшен презентацияләргә әзерләнә. | Укучылар рәсемнәрне табалар.<br><br>Төркемнәрдә эш.<br>Һәр төркем проект эшен тәкъдим итә,<br>үз фикерләрен әйтәләр. | ТБУУГ: төп фикерне аерып чыгара белү;<br>КУУГ: башкаларның фикерләрен тыңлый, аңлый белү, үз фикереңне дәлилләп башкаларга җиткерә белү;<br>РУУГ: үзбәя; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **9) Рефлексия.** | Йомгаклау: Шулай итеп сәламәт булу өчен спортны яратырга, җиләк – җимеш ашарга кирәк.Сәламәт булыйк!Афәрин, укучылар. Сез дәрестә актив катнаштыгыз, матур итеп җавап бирдегез, булдырдыгыз. Рәхмәт!<br>Үзбәя. Ә хәзер үзегезгә бәя бирегез: мин дәрестә бик яхшы эшләдем яисә бераз тырышырга кирәк. | Укучылар үзләренә бәя бирә. | ШУУГ: эшчәнлекнең максаты һәм нәтиҗәсе арасында бәйләнешне билгеләү, үз уңыш-уңышсызлыкларыңның сәбәбен ачыклау;<br>КУУГ: башкаларның белү, үз фикереңне фикерләрен тыңлый, аңлый дәлилләп башкаларга җиткерә белү;<br>РУУГ: үзбәя. |

## Роль семьи в сохранении и развитии родного языка и национальных традиций

**Семякова Елена Борисовна,**

*учитель начальных классов,*

*МБОУ «Ильнетская СОШ*

*имени Микая(Герасимова М.С.)»*

*Менделеевского муниципального района*

*Республики Татарстан*

Как рыба не может жить вне воды, так и человек не может оставаться человеком вне языка. Потому владение языком – главное, чему стоит учиться в жизни, в семье и в школах любой страны родной язык – самый важный предмет

Обучение родному языку – дело большой государственной важности. От того, как будет владеть, и распоряжаться языковым богатством каждый из нас и все мы вместе, зависит настоящее и будущее нашей национальной культуры. "Развивать национальное самосознание можно только на родном языке", – писал марийский писатель Шабдар Осып. Следовательно, вся образовательная и воспитательная работа в семье, детском саду, школе должна вестись на родном языке, который является первоосновой воспитания современного гражданина.

Актуальной задачей школы сегодняшнего дня является формирование нового поколения, достойных продолжателей традиций своего народа, преемников культуры народа и вместе с тем равноправных и свободных от национальных предвзятостей, терпимых и уважительно относящихся к чужой мысли, культуре. обычаям, обрядам, языкам, истории, праздникам и религии соседствующих с нами народов. Эти задачи можно решать благодаря использованию местного материала, народной педагогики во всем педагогическом процессе в целом. В нем должно отражаться национальное и региональное своеобразие культуры, литературы и искусства. Для современного человека стало актуальным восстановление культурно- исторических связей с родным краем, своей малой родиной.

Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Ильнетская средняя общеобразовательная школа имени Микая(М.С.Герасимова) – является национальной школой, но обучаются дети разных национальностей и поэтому образование и воспитание обучающихся тесно связаны с национальным образованием. Это ставит перед школой особый комплекс образовательных и воспитательных задач. Их решение должно обеспечить молодому человеку возможность самоидентифицироваться как представителю той или иной национальной культуры, создать условия для равноправного диалога с этнокультурным окружением, вовлечь развивающую личность в

цивилизованные процессы, основывающиеся на национальных общероссийских и общечеловеческих ценностях.

Финно-угорские языки представляют малочисленные языки, большая часть которых классифицируется как исчезающие языки. Финский, эстонский и венгерский языки являются доминирующими языками, а финно-угорские языки в России находятся в положении языков национального меньшинства. Язык, на котором говорят в семье, зависит от семьи и, в основном, от женщины. Так как формирование своего “я” человека зависит от его отношения с окружающими, то матери принадлежит главная роль в передаче и языка национального меньшинства. Всякий язык есть богатство, часто он является ключом к культуре и подчеркивает собственное отождествление с нацией. Язык матери есть родной язык и распределительная власть матери в семье обуславливает также и то, что матери принадлежит в семье право определять, на каком языке в семье будут говорить и посредством языка уважать национальную культуру. Язык передается по наследству и поэтому роль семьи и роль матери особенно велика.

Семейная, образовательная и культурная политика включают в себя мероприятия, пронизанные принципами равноправия полов. В финно-угорском языковом регионе женщины несут гигантскую ответственность в качестве воспитателей, передающих родной язык последующим поколениям. Проблемой является недостаток поддержки. Во многих сельских местностях существуют традиционные связи взаимодействия между женщинами, основанные на помощи соседей и родственников, в рамках которых женщины оказывают друг другу поддержку. Молодые женщины все более осознают положение женщины и связанные с этим проблемы. Женские организации и сети сотрудничества нужны, так как они содействуют развитию самосознания женщин о собственном статусе и ответственности в качестве хранительниц национальной принадлежности.

Все уральские языки, на которых говорят в России, находятся в положении языков национального меньшинства, и их подстерегают те же опасности, как и другие языки национального меньшинства в мире. Язык является существенным

фактором с точки зрения отождествления нации: без языка нет и народа, иначе говоря, народ, теряющий свой язык, сливается рано или поздно и в культурном смысле с окружающим большинством.

С точки зрения духовного развития личности, хорошее знание родного языка является необходимостью. По социолингвистическому исследованию дети, которые дома не овладевают в полной мере родным языком и которые в школе обучаются на каком-нибудь другом языке, никогда не смогут как следует владеть тем или иным языком; они не будут "ни одно – ни двуязычными", а "полуязычными". Язык – основное средство общения и одновременно важнейшее средство восприятия мира. Ребенок, лишенный этого средства, не сможет по-настоящему впитывать в себя другие знания и навыки, а также не сможет в полной мере развивать свои духовные способности.

У марийцев, живущих в селе, проблемы языка актуализировались тем, что в 60-80-ые годы XX века выросло целое поколение людей, оторванных от духовных корней.

Как показали наблюдения за семьями нашего сельского поселения , где оба родителя мари по национальности, общение на уровне семьи и быта происходит в основном на русском языке. Только в 13% семей говорят на своем родном марийском языке. По словам учителей, преподающих марийский язык в других школах подобная картина характерна и для их деревень.

На мой взгляд, необходимо сделать следующее:

– во-первых, в семье прививать детям желание говорить на родном языке, воспитывать уважение к родному языку, культуре, обычаям и традициям своего народа.

– во-вторых, изучение марийского языка, как средства общения и воспитания, необходимо начинать с дошкольного возраста.

Рассмотрение вопроса о сохранении, развитии родного языка и национальных традиций позволяет говорить о том, что данный процесс осуществляется в первую очередь в семье.

Мы не должны забывать свой родной язык, свою культуру. Знакомство с культурой своего народа- это, прежде всего, обращение молодого поколения к своим корням, способ не потерять  себя, свою самобытность в этом огромном мире.

Язык остается жизнеспособным лишь в том случае, если он является средством всякого человеческого общения. Хотя с точки зрения передачи человеку ( родного) языка роль дома и велика, язык не может сохраняться, если он не имеет в обществе официально признанного статуса. Языковой закон, определяющий равноправный статус русского языка и языка национального меньшинства, – это обязательное условие повышения престижа языка национального меньшинства и обеспечение прав носителей языка.

## **Татар теле дәресләрендә сәләтле балаларның дивергент фикерләвен үстерү чарасы буларак фәнни тикшеренү эшчәнлеген оештыру**

***Смирнова Г.Р.***

*Менделеевск шәһәре 1нче урта мәктәбенең*

*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Сәләтлелек термины дигәндә, “теге яки бу эшчәнлек өлкәсендә уңышка ирешү-ирешмәүне билгеләүче сәләтләрнең үзенчәлекле сыйфати җыемасын” аңлыйлар [Штерц, эл. ресурс]. Мәктәптә сәләтләрен лингвистик, әдәби юнәлештә үстерү өчен табигый башлангычлары, талантлары булган балалар һәр сыйныфта диярлек очрый. Алар белән эшләгәндә дивергент фикерләү үсешен тәэмин итү зур роль уйный. Дивергент фикерләү – өлге һәм калыплар аша үтә алган, стереотипларны җиңә алган, проблеманы хәл итүдә чикләрне күрмәүгә нигезләнгән ирекле фикерләү төре ул [Гатанов 1999: 5].

Мәктәп дәресе уртача сәләтле, уртача өлгерешле балаларга юнәлдерелгән. Дәреслекләр, методик кулланмалар тәкъдим иткән бирем, күнегүләрнең күбесе конвергент фикерләүне үстерүне күздә тота. БДИ кертелү белән актуальләшкән, төрле дисциплиналарны, шул исәптән, татар теле, әдәбият дәресләрен укытканда

да еш кулланыла торган тест биремнәре дә бары конвергент фикер йөртү үсешен тәэмин итә. Бу биремнәрнең барысын да ахыр нәтиҗә буларак билгеле бер дөрес җавапка килү, укучыларның эшләрендә башкару тизлеге, төгәллек, пөхтәлек кебек сыйфатлары бәяләнү берләштерә. Әмма чынбарлык кешедән дивергент, иҗади фикер йөртүне дә таләп итә. Тормышта бердәнбер дөрес җавап, бердәнбер дөрес гамәл булмаган ситуацияләр дә очрый. Моны эчке сиземләве белән аңлаган, иҗади якын килү үзенчәлеге булган балалар мәктәп шартларында сәләтләрен еш кына үстерә алмыйлар. Алардан тизлек, бирелгән шаблон буенча эшләү таләп ителгәндә, алар проблеманы үрнәктәгечә түгел, башка яктан килеп чишәргә омтылалар. Нәтиҗәдә стереотипик фикер йөртүчеләр яхшы билге ала, ә сәләтле бала омтылышы битарафлылыкка дучар ителә. Моны булдырмау өчен, сәләтле укучыларга индивидуаль биремнәр тәкъдим итәргә, иҗади якын килүне таләп иткән эшшчәнлеккә тарту кирәк.  Минем фикеремчә, балаларның иҗади фикерләвен үстерүдә аларны фәнни-тикшеренү эшчәнлегенә җәлеп итү нәтиҗәле алым булып тора. Мондый эшчәнлек темасы бала өчен кызыклы да булырга тиеш, шул ук вакытта укучыларның киләчәктә фәнни үсешен дәвам иттерү перспективалары да булу уңай. Моңа ничек ирешергә соң? Педагогик тәҗрибәмә таянып, бер мисал китерим. Дәрестә мин балалаларны бер басма кысаларында өч телдә – татар, рус, инглиз телләрендә дөнья күргән китаплар белән таныштыруга игътибар бирәм. Нәкъ шундый өч телле басмалар хәзерге вакытта популярлашып баралар. Балалар Г.Тукай, А.Алишның шундый өр-яңа, матур бизәлешле китапларын карыйлар; шулай ук “Салават күпере” балалар журналының һәр санында диярлек татар шагыйрьләренең иҗаты өч телдә басылып чыга. Мондый эш укучыларның татар әдәбиятына, татар теленә карата кызыксынуын арттыра. Нәтиҗәдә сәләтле балалар, төбәкара яисә республика күләм фәнни-гамәли конференцияләргә әзерләнгәндә, тәрҗемә әсәрләрнең лексик үзенчәлекләрен тикшерүне күзаллаган темалар өстендә зур теләк белән эшлиләр. Теманың балага илһам бирүе бик мөһим, аның өстендә эшләгәндә, балага кечкенә ачышлар ясау өчен урын калырга тиеш. Укучыларны төбәкара

һәм республика күләм фәнни-гамәли конференцияләргә әзерләү тәҗрибәмә таянып, укучыларым ясаган берничә “ачыш” белән таныштырып китим:

1) А.С. Пушкинның “Бакыр һәйкәл” (“Медный всадник”) поэмасын татар теленә адекват тәрҗемә итү өчен, тәрҗемәчә татар һәм рус дөнья картиналарында беренче стихия (ут, су, һава, җир) образларының символик мәгънәләрен яхшы белергә тиеш (Ильина Д. 7сыйныф)

2) әдәби әсәрләрне тәрҗемә итү процессында язучының фикерен, чыганак телне йөртүче халыкның дөньяны кабул итү үзенчәлекләрен тәрҗемәдә төгәл тапшыру өчен, фразеологизмнар түбәндәге алымнар ярдәмендә тәрҗемә ителә ала: фразеологик эквивалент куллану, өлешчә фразеологик эквивалент куллану, калькалаштырылган фразеологизм, лексик тәрҗемә, тасвирлама тәрҗемә ясау ( Грудцова К.).

Уйлавымча, мондый ачышлар ясау өчен, баланың дивергент фикер йөртүе үсеш алган булырга тиеш: беренче мәкалә авторы поэмада, авторның әсәргә салган мәгънәви йөкләмәсенә ярашлы рәвештә, стихияләрнең традицион символик мәгънәләре үзгәреш кичергәнен, бу үзгәрешләрнең тәрҗемәдә ни рәвешле бирелешен күзәтә алган. Икенче мәкаләдә укучының дивергент фикер йөртүе шунда күренә: ул рус әсәрендәге фразеологизмнарны татар теленә тәрҗемә иткәндә, тәрҗемә ителүче телдә ул гыйбарәләрнең эквивалентлары яисә мәгънәдәш гыйбарәләр булу-булмауга бәйле рәвештә, тәрҗемәче төрле алымнаргы мөрәҗәгать итә алу турында гипотеза кора.

Әлбәттә, укучыларның фәнни эзләнү-тикшеренү эшләренең уңышы конвергент фикер йөртү дәрәҗәләренә дә бәйле. Һәр фәнни эштә эзләнү-тикшеренүнең гамәли өлешен башкару нәтиҗәсендә алынган мәгълүмат анализлана һәм әлеге анализ конвергент фикерләүне, билгеле бер алгоритм буенча, логик эзлеклелек саклап эш итүне таләп итә. Шулай итеп, нык үскән дивергент фикер йөртү конвергент фикерләү белән үрелү нәтиҗәсендә генә уңышлы фәнни эш язуның шарты булып тора.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: ковергент фикерләү үсешен күзаллаган урта мәктәп шартларында дивергент фикер йөртү өстенлек иткән сәләтле балаларның

талантлары үсеше өчен уңай шартлар юк диярлек. Проблемадан чыгу юлы буларак, алар белән индивидуаль эш алып бару, шуның бер алымы буларак фәнни-тикшеренү эшләренә җәлеп итүне тәкъдим итәргә була.

Библиография


1. Гатанов Ю.Б. Курс развития творческого мышления по методы Дж. Гилфорда, Дж. Рензулли (для детей 8-12 лет). – СПб.: Иматон, 1999. – 59с.
2. Штерц О.М., Штерц Н.Т. Научно-исследовательская деятельность на уроках истории в работе с одаренными детьми. Электронный ресурс. – URL: http://cyberleninka.ru/article/n/nauchno-issledovatelskaya-deyatelnost-na-urokah-istorii-v-rabote-s-odarennymi-detmi; дата обращения: 02.01.2016.


## **Проблема повышения мотивации при изучении родного языка в общеобразовательных учреждениях**


**Софронова Вера Васильевна,**
*МБОУ «Средняя школа № 5»*
*ЕМР РТ*





Софронова ПРОБЛЕМА ПОВЫШЕНИЯ МОТИВАЦИИ ПРИ ИЗУЧЕНИИ РОДНОГО ЯЗЫКА В ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ УЧРЕЖДЕНИЯХ (1).wmv

**(рәсемгә 2 тапкыр басарга)**

**Татар теле һәм әдәбиятын укытуда килеп чыккан**

**кыенлыклар һәм аларны чишү юллары**

**Тухбатова Чулпан Илдар кызы,**

*Менделеевск муниципаль районы*

*“Ижевка урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең*

*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

И телем,сансыз гасырны

Исән – сау кичкән телем,

Сыкраулар теле түгел син,

Күкрәүләр теле бүген!

- дип язган Хәсән Туфан “Туган тел турында җырлар”шигырендә. Туган телнең аяныч язмышы, яшь буынның үз телләрен онытуы аны борчыган.

Бүгенге көндә телебезгә карата карашларның үзгәрүе безне борчый. Туган телебезне саклау,өйрәнү һәм үстерү мөһим.

Тел ул- кешеләр һәм кешелек буыннары арасында аралашу коралы.Һәр кеше,тормыш алып бару өчен, башкалар белән аралаша һәм тормыш тәҗрибәсен үзеннән соң килгән буынга тел ярдәмендә өйрәтеп , биреп калдыра.Шул юл белән җәмгыять үсә.Кеше нинди телдә сөйләшсә, шул телдә уйлый да. Туган тел – үз телендә сөйләшүче халыкларның күп гасырлар буе тупланган рухи хәзинәсен чагылдыручы тылсымлы сихри көзгесе дә. Укучыларның эзлекле фикерләү,образлы уйлау сәләтләре үссен һәм нәтиҗәле өлгерешкә ирешсен өчен,укытучылар аларның туган телне яхшы белүләренә кече яшьтән үк зәвык нәфис итеп сөйләргә һәм язарга өйрәнүләренә омтылырга тиеш.

Балага туган тел иң беренче чиратта гаиләдә сеңдерелә. Гаиләдә, аннан соң балалар бакчасында , мәктәптә туган телендә тәрбияләнгән бала ана телен һич онытмаячак.

Башлангыч мәктәптә татар теле ,нигездә,әдәби телнең практик курсы булып тора. Балаларны үзләренең фикерләрен, кичереш һәм хисләрен сөйләп , язып бирерлек итеп әдәби телгә өйрәтү аларның һәрьяклап үсүләренә дә ярдәм итә.Бала үз сүзләре белән дөрес,ачык, төгәл һәм аңлаешлы итеп сөйләп ,язып бирә һәм телне оста куллана алганда гына , белем үзләштерелгән булып санала.

Хәзерге заманда туган телен дә, русча һәм инглизчә дә белгән кешеләр кирәк.Әмма һәр милләт вәкилләре, шул исәптән татарлар да,әлбәттә,туган телләрен мөмкин булганча яхшы белергә һәм шул телдә дә- һич югында гаиләләрендә – иркен аралашырга тиеш.Бу милләтнең ,халыкның саклануы өчен төп шарт.

Телне яхшы белүдә төп метод-сөйләшү һәм язу. Укырга,язарга өйрәнә башлау белән һәр баланың авазны, хәрефне, иҗекне, сүзне, җөмләне гамәли белүе мөһимгә әйләнә.

Укучылар,татар теле дәресләрендә аңлап укырга, дөрес сөйләргә һәм язарга өйрәнәләр; әйтмә,язма сөйләм кагыйдәләрен үзләштерәләр. Укырга һәм язарга өйрәтү барышында балалар үзләрен чолгап алган табигатьне укытучы җитәкчелегендә актив күзәтәләр; үз кичерешләрен сөйлиләр;укытучы ярдәмендә уй-фикерләрен телдән һәм язмача эчтәлекле һәм грамоталы итеп әйтә бирә белү күнекмәләре алалар.

Бүгенге көндә татар телен һәм әдәбиятын укытуда. Бу бигрәк тә туган телләрен начар белгән яки бөтенләй белмәгән балаларны өйрәтүгә карый. Мәктәпләрдә укыган балаларның ата-аналарыннан, татар телен өйрәтүгә карата зарлануларын еш ишетергә туры килә. Татар телен җитәрлек белмәүләренең һәм еш кына бу телне өйрәнүгә тиешле җитди караш, игътибар булмауның төрле сәбәпләре бар.

Беренчесе - балаларның сөйләм теле ярлы,сүзлек запасының аз булуында ;

Икенчесе – дәреслекләрнең сыйфаты тиешле дәрәҗәдә булмавы;

Өченчесе – туган телләрендә сөйләшми торган татар балаларын татар теленә өйрәтүнең методикасы камил булмавы;

Дүртенчесе- патриотлылык рухы, милли горурлык хисе, әхлакый тәрбиясе җитмәү;

Бишенчесе – ата-аналарның татар теленә карата җитди караштa булмавы.

Туган телне саклау,үстерү, ныгыту төшенчәсе аннан файдаланучыларның санын арттыруны гына түгел ,телнең сыйфаты,ягъни дөрес кулланышы тиешле дәрәҗәдә булуны да күздә тота.Шулай ук,информацион – коммуникатив чараларны куллану унай нәтиҗә бирә.Бу – яңа технологияне нәтиҗәле куллануның иң мөһим педагогик шарты. Укучы эшчәнлеген компьютер технологиясе ярдәмендә тирәнтен, төптән үзгәртү зур әһмияткә ия.

Компьютер – укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы. Компьютердан файдалану укыту эшчәнлеген баета, укыту процессын кызыклы, нәтиҗәле һәм иҗади итеп оештырырга мөмкинлек бирә.

- Дәресләрдә информацион-коммуникатив технологияләрне куллану укучыларның укуга кызыксынуы арттыра;дәрестә эш формаларын төрлеләндерелә;
- тиз арада укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшереп алырга мөмкинлек бирә;
- барлык укучыларның да эшчәнлеген контрольдә тота; укучыларны эзләнергә мәҗбүр итә.

Фәнни-тикшеренү эше укучылырның үзләренә шәхси сыйфатлар бирә:

- мөстәкыйль яңа белем үзләштерергә һәм аны практикада куллана белү;
- ижади фикерли белү, авырлыклардан чыгу юлын табу; мәгълүмат өстендә дөрес эшләү, кирәкле фактларны җыю, аларга анализ эшләү, дөрес нәтиҗә ясау, йомгаклау;
- китаплардан, интернеттан һәм башка чыганаклардан кирәкле материалны табып, эшкәртү;

Бу сыйфатлар барысы да аларның киләчәк тормышында кирәк булачак. Дәресләрдә компьютер презентациялереннән файдалану тагын да эчтәлеклерәк, тәэсирлерәк, нәтиҗәлерәк, күрсәтмәлерәк укыту мемкинлеге бирә. Презентацияне дәреснең:

- белемнәрне актуальләштерү;
- яңа материалны анлату;
- белемнәрне беренчел ныгыту;
- белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру этапларында кулланырга мөмкин.

Гомумән,информацион-коммуникатив чараларны куллану - ул өйрәнелә торган фәнгә кызыксыну уята, танып-белү активлыгын үстерә, аралашу процессында үзара аңлашу һәм ярдәмләшү мохитен тудыра, укучыларның иҗади сәләтләрен ачыклый.

Мәктәпләрдә балаларны дөрес итеп туган телебездә сөйләшергә өйрәтү,аларда татар теленә ,сәнгатенә мәхәббәт уяту бик зур тырышлык сорый. Шуңа күрә, тел күбрәк кулланышта һәм хәрәкәттә булырга тиеш.

Кулланылган әдәбият

1.Сыйфатлы белем бирүдә информацион технологияләр куллану.

Казан . 2010 ел.

## **Сынмаганнар, сыгылмаганнар...**

*(Татар мәктәбенең 8 нче классында А. Гыйләҗевнең*

*“Язгы кәрваннар” әсәрен өйрәнү)*

**Умнова Лилия Ивановна**

*Тукай районы*

*Мәләкәс гомуми урта белем бирү мәктәбенең*

*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Аннотация**

Дәрес эшкәртмәсе ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының сайтында китерелгән үрнәк программага нигезләнеп эшләнде (Төзүче-авторлары: Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова, 2013 ел). Дәреслек - 8 кл. Ганиева Ф. Ә., Рамзаева Ч.Р., 2006, Казан, “Мәгариф” татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия.

А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәре татар мәктәпләре өчен 8 класста үзләштерелә. Программада әлеге әсәр өчен 3 сәгать вакыт бирелә. Бу- йомгаклау дәрес.

Дәрес коллектив фикер йөртү технологиясе (технология коллективной мыслительной деятельности- КМД) буенча оештырылды (проблема ситуациясенә кертү –группаларда эш- фикер алышу- рефлексия). Әлеге дәрес әсәрнең мәгънәви эчтәлеген ачып, укучыларга тормыш тәҗрибәсе бирүгә нигезләнә.

Дәрес, ФГОС таләбе буенча, гомуми метадологик дәрес структурасы буенча оештырылды. Үзмаксат (укучыларны мотивацияләү җыр аша башкарылды) – кыенлык (ачкыч сүз) -уку мәсәләсе (сугыш яшүсмерләре чор авылыкларын нәрсә хисабына җиңгәннәр?)- эш стратегиясе билгеләү -эш барышы (соңыннан эталон буенча тикшерү), мөстәкыйль эш (темпераментларны билгеләү, аларны әсәр геройлары белән бәйләп дәлилләү)- рефлексия (күркәм холык моделе төзү)

ФГОС дәресе буларак: өйрәнелә торган материал баланың тормыш тәҗрибәсе белән бәйләнештә, проблемалы сораулар куела, эзләнү эшчәнлеге: искә төшер, мисал китер, дәлиллә, аңлат форматында бара. Дәрестә укучыларның эшчәнлеге 70%; аралашуның диалогик формасы кулланыла, кеше темпераментлары белән әсәр геройларын бәйләү ярдәмендә стандарт булмаган ситуация тудырыла. Дәрестә балалар индивидуаль һәм группада эшлиләр. Кире бәйләнеш җаваплар һәм эш карталары ярдәмендә башкарыла. Үзбәя һәм үз контроль бәяләү кәгазләре ярдәмендә дәреснең һәр этабында үтәлә һәм, азактан, һәр группа гомуми нәтиҗә чыгарып, аны дәлилли.

Әлеге дәрес барышында укучылар тормышны хисси-эмоциональ тәэсир чаралары ярдәмендә кеше холкы сурәтен, моделен төзү һәм шуңа карата мөнәсәбәт формалаштыру сәләтенә ия булалар. А. Гыйләҗев фикере аша гомумкешелек кыйммәтләрен, куркәм холыкның мөһимлегенә төшенәләр. Тормышчан

проблемаларга әсәрдән аргументлар китереп, үз фикерләрен дәлиллиләр. Кеше темпераментлары белән укучылар хәбардар. (7 нче класс, җәмгыять белеме) Бу дәрестә, укучылар кеше темпераментлары аша, геройларны характерлап, үзләренә киләчәккә ориентир билгелиләр.

**Дәреснең максаты:** Коммуникатив һәм танып белү универсаль уку күнекмәләрен булдыру.

**Өйрәтү максаты:** А. Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” әсәре геройларына характеристиканы кеше темперамантлары аша бирергә өйрәтү; монологик, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстертү.

**Белем үстерү максаты:** тормыш тәҗрибәсе бирү, кеше танырга өйрәтү, үз фикерләрен дөрес, матур итеп әйтә белергә өйрәтү.

**Тәрбияви максат:** киләчәк бүгенге яшүсмерләр кулында, шуңа күрә аларда матур холык , эшләгән эшләре өчен җаваплылык хисе һәм бердәмлек тәрбияләү.

**Метапредмет белемнәр-** темперамент , текст һәм модель белән эш.

**Көтелгән нәтиҗә:**
**УУГ-универсаль уку гамәлләре**
**Шәхси:**
-индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру;
-кешенең башкаларны кабул итүләрен, аңлауларын, фикерләрен җиткерә алу сәләтләрен үстерү.
Патриотик һәм кешелеклелек тәрбиясенә юнәлеш бирү. Үткәннәргә хөрмәт һәм сак караш тәрбияләү
**Регулятив:** бәйләнешле сөйләм,үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белүләрен үстерү;
**Коммуникатив:** ишетә һәм тыңлый белү күнекмәләре формалаштыру,фикерләү сәләтен үстерү;
**Танып-белү:** үзләренең белем системасында ориентлаша белергә өйрәтү; яңа белемнәр табу, үткәндә өйрәнгәнне укытучы ярдәмендә яңасыннан аера белү; яңа белемнәр табу, дәрестә алган информациядән файдаланып сорауларга җавап бирү.

**Предметара бәйләнешләр**- психология, җәмгыять белеме
**Төп ресурслар-** А. Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повесте, аңламалы сүзлек, интернет

**Өстәмә ресурслар -** Презентация, интерактив такта, карточкалар, рәсемнәр, ноутбук, экран, эш кәгазьләре
**Эш формалары-** Фронталь эш, төркемнәрдә эш.

**Дәрес барышы**

**Кереш әңгәмә**

**Укучылар, минем сезгә бер бик мәгънәле җыр тыңлатасым килә. Әлеге җырны тыңлаганда, ачкыч сүзләрне табарга тәкъдим итәм.** (Укучыларга Фәридә Алсу дуэтының «Борма юллар» җырының бер өзеге тәкъдим ителә. Укучылар тыңлаганнан соң, өзекнең ачкыч сүзләрен табалар. Һәр группа үз вариантын тәкъдим итә, группаларда киңәшләшү өчен вакыт бирелә)

**Әлеге җырда ачкыч сүзләр?** Җаваплар тыңланыла (Көтелгән җавап: гомер юлы һәм адәм баласы)

**Адәм баласы гомер юлын үткәндә, аның белән янәшә, нәрсә бара соң?** Җаваплар тыңланыла (Көтелгән җавап: холык)

**Димәк, без бу дәрестә ни турында сөйләшербез?** Җаваплар тыңланыла (Көтелгән җавап: Холык турында сөйләшербез)


**Слайд №1**

**Нәрсә соң ул – холык?** (кешенең табигате, характеры.)(Миллият сүзлеге/ Казан «Мәгариф» нәшрияты, 2007)


**Холык, укучылар, нәрсәгә нигезләнеп формалаша соң?**
(Көтелгән җавап- темпераментка нигезләнеп формалаша**.)**

**Әйе, сез моны 7 нче класста җәмгыять белеменнән үзләштердегез инде. Укучылар, сезнең алда эш кәгазьләре, бирелә сез сыйфатларыннан чыгып, темперамент төрләрен китязарга тиеш . Эш барышында сүзлек, интернет, 7 нче класс өчен җәмгыять белеме дәреслеге файдаланырга** мөмкин (Группаларда киңәшләшү өчен вакыт бирелә. Һәр группа үз вариантын тәкъдим итә) (эш кәгазе №1)

Слайд №2




Слайд №3 группалар, чиратлап, темпераментларны әйтә баралар һәм слайдтан тикшерә баралар (эталон буенча тикшерү ),




**(Һәр группа членнары гомуми бәя кәгазенә дәреснең бу этабына бәя куя)**

**Укучылар,без бүген кайсы әсәр геройларының темпераментларын карарбыз икән соң?** (Көтелгән җавап: узган дәрестә А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар » әсәрен өйрәндек. Шуңа күрә, әлеге әсәр өстендә эшләрбез дип уйлыйм)

**Әсәр темасы турында нәрсә әйтә аласыз?**

Көтелгән җаваплар:

-Бу әсәр сугыш чорыдагы авыл кешеләре турында. Әсәрдә төп вакыйгалар Сарман районы Кәсле глубинкасы һәм Зәй районы Югары Баграж авыллары арасындагы юлда бара. Вакыйгалар да Югары Баграж кешеләре белән бәйле. Әлеге чор кешеләре бик катлаулы юл үткәннәр. Әлеге юлны һәр кеше үзе булдыра алганча үткән.

**Әсәр сездә нинди хисләр уятты?**

- Ул миндә ниндидер яктылык хисе уятты. «Язгы кәрваннар» повестенда А. Гыйләҗев геройларның язмышын күбрәк кырыс буяулар белән тасвирласа да, әсәрдән эчке бер җылылык бөркелеп тора.
- Әсәр миндә кызгану хисе уятты, ә гаделсезлеккә ачуым килде. Сугыш чоры авырлыкларын фаҗигагә әйләндергән төп сәбәп- Сарман районы Чокырлы авылы (Кәсле авылының күршесе) кешеләрен Зәй районы Сарсаз глубинкасына, ә Зәй районы Югары Баграж (Сарсазның күршесе) кешеләрен Сарман районы Кәсле глубинкасына солы семенасына җибәрүләрендә. Хәкимҗан абый:«Чокырлы кешеләрен очратуыгызны бүтәннәргә сөйләмәгез инде.. Ишеттем мин аны! Нишлисең, кушканны үтәмичән ярамый. Көне буе районда шуны даулап йөрдем» (85 нче бит)
- Мин геройларга карап сокландым да, аларны кызгандым да. Алар 75 чана тезелеп 65 чакрым ераклыктагы Кәсле авылына җәяү чана тартып чыгып китәләр. Иң аянычы шунда: әлеге семенаны күрше авылдан гына да алырга булган. Ә Чокырлы кешеләрен, киресенчә, Сарсаз Багражга җибәрәләр.

- Алар өчен горурландым. Әсәрдә вакыйгалар сугышның соңгы язын тасвирлый. ( Хәкимҗан абзый болай ди : Инде быелгы читен яз соңгысы булсын! Тезләнсәк

тә, егылыр өчен түгел, сикереп торып йөгерп китәр өчен тезләнәбез (68-69 нчы бит) )

*Укучыларга картада Югары Баграж һәм Кәсле авылы аралары күрсәтелә.*

**Слайд №4**

**1. Проблемага кертеп җибәрү**

<u>**Уку мәсьәләсе кую**</u>

**Әсәр кемнәр турында?**

Җаваплар тыңланыла (көтелгән җавап: яшүсмерләр турында; сугыш чорында авыл халкы турында; шушы кешеләрнең гомер юллары турында)

**Аларның гомер юллары җиңел булганмы?** Җаваплар тыңланыла. (көтелгән җавап: аларның гомер юллары бик авыр булган. Бу яшүсмерләрнең гомер юллары авыр сугыш елларына туры килгән. Аларның гомер юллары авыр булуына Баграж Кәсле арасындагы юлда күргән авырлыклардан сизенәбез. Бу аларның бөтен гомер юлларын күрсәтә кебек.

**Үзеннән үзе нинди сорау туа?** (көтелгән җавап)

Сугыш чоры яшүсмерләре гомер юлларындагы авырлыкларны нәрсә хисабына җиңеп чыга алганнар?

**Без дәрес азагында нәкъ менә шушы сорауга җавпны табарга тиеш тә инде.**

**Слайд №4**

<u>**2. Уку мәсьәләсен чишүнең беренче этабы- индивидуаль эш**</u>

**Ә хәзер, әйдәгез әле әсәрнең эчтәлеге белән танышлыгыгызны тикшереп үтик**

Һәр укучы алдында әсәр турында тезизлар таблицасы. Укучылар мөстәкыйль рәвештә эшлиләр.

Эшләп бетергәннән соң эталон бенча тикшерәләр, һәр дөрес җавапка 1 балл куялар. Слайд №5

| тезис | әйе | юк |
|---|---|---|
| Әсәрдә символлар: кәрван, җыр, бүреләр, җил | + | |
| Дамир, Әдилә, Ибраһим- ярдәмче геройлар | | - |
| Элеваторга 7 атта, 7 кеше бара | + | |
| Кәслекгә 75 чана кузгала | + | |
| Ибраһим белән Әдилә эт улаганын ишетәләр | | - |
| Гыймай фатихының кызы Гөлбәдәр табынга арыш ипие куя | | - |
| Кәследән семена алып кайтышлый алар Чокырлы кешеләрен очраталар | + | |
| Иң авыр вакыйга кайтканда, завод тавында, Сабираттәй язмышы белән бәйле | + | |
| Әдилә чана бавын, шәлен рәтләгәндә, Дамирга тоттыра | | - |

**Төп вакыйгалар кайда бара?** Көтелгән җавап: Төп вакыйгалар Баграж белән Кәсле авыллары арасындагы юлда бара.

**Ә менә шул юл әлеге геройларның нәрсәсенә ишарәли соң?** Көтелгән җавап: әлеге юл геройларның авыр, сикәлтәле гомер юлларына ишарәли һ.б.

**Әсәр үзәгендә яшүсмерләр дидек. Ә кемнәр соң алар?** Һәр группа үзенә бер геройны сайлап ала һәм аңа характеристика бирә. (Группаларда киңәшләшү өчен вакыт бирелә)

- Ибраһим- җитез, үткен, максатына ирешүчән, тракторчылар курсында укып кайткан. Ярдәмчел, арыган хатыннарның, хәле авырайган Сабираттәйне, Дамирның чанасына утыртып, зводка кадәр тартып алып бара, тәвәккәл (Әдиләгә мәхәббәтен аңлата ала).

-- Әдилә- моңлы , матур итеп җырлый белә, ярдәмчел (Юлда барганда, өлкән апаларга булыша), яхшы күңелле (Бу аның җырыннан күренә: Алтын булып тамаем/ Көмеш булып агаем). 2 кыш апасының 4 баласын карый, бер эштән дә тартынмый. Инициативалы, башкалар өчен җаваплылыкны үз өстенә ала. (Кәслегә җитәрәк, ул берничә кызны ияртеп, алгарак китеп, Кәсле идарәсенә бара. Анда фатирлар белешеп, кешеләрне өйләргә бүлгәләп тә куя, Сабирәттәйнең хәле авырайгач, төп җаваплылыкны үзенә ала. )

- Дамир- кәрле аяклы кара чутыр малалай. Әтисе сугышка кадәр конюх булган, хәзер үзе атлар карый. Бераз астыртын. (Тиктомалдан, Әдиләне яманлый башлый) Дальтоник, колакка катырак, үпкәчән. (Ибраһимның саңгылау түгел лә мин, дигән сүзенә үпкәли); Армиягә яраксыз, әмма максатына ирешү өчен тырыша. (мунчада биергә өйрәнә, ат өендә гармун кычкыртып маташа, Кәслегә дә күтәрәмгә калган атларга солы бирүләренә өметләнеп юлга кузгала.)

**(Һәр группа членнары гомуми бәя кәгазенә дәреснең бу этабына бәя куя)**


**Уку мәсьәләсе чишүнең икенче этабы- группада эш**

**Укучылар, без дәрес башында темперамент турында сөйләштек, яңа гына геройларга характеристика бирдек. Ә хәзер нишләрбез?** ( көтелгән җавап: Ә хәзер төп геройларның темпераментларын билгеләп үтәрбез)

**Әйе, укучылар группаларда киңәшләшеп, геройларның темпераментларын билгеләрбез, моның өчен эш кәгазьләрендә эше дәвам итәбез.** (Группаларда киңәшләшү өчен вакыт бирелә)

Һәр группа үзе фикерен әйтә һәм дәлилли. (эш кәгазе №1)

**Үзбәя кую (Һәр группа членнары гомуми бәя кәгазенә дәреснең бу этабына бәя куя)**



**Слайд №7**

**3. Фикер алышу**

**Темперамент сыйфатлары нинди булуга карамастан, аларны төп сыйфаты?** (Көтелгән җавап )

- Темперамент сыйфатлары төрле булуга карамастан, алар кешелекле, киң күңелле, җаваплы.
- Алар барысы да оптимистлар булганнар. Ягъни киләчәккә ышанганнар, әле ышанып кына калмаганнар аны якынайту өчен мөмкин булганны да, мөмкин булмаганны да эшләгәннәр.
- Алар кешелекле һәм бердәм булганнар. (Кәсле авылында да Сәрвәр апа кәрванчыларны , үзләрендә дә санаулы гына калган, бәрәңге белән сыйлый. Җитмәсә, күршеләренә кунарга кергән юлчыларны да ашарга алып чыга. Чөнки күршеләре алардан да авыррак торалар.)
- Әйе, характер сыйфатлары, темпераментлары нинди булуга карамастан, алар бер- берсенә терәк, ярдәмче, мәрхәмәтле. Алар күркәм холыклы: бар булганнары белән бүлешә белгәннәр ( Габбас абый йортына кунарга кергәч тә, бәрәңге ашаганда һәркем үз күршесенә бәрәңгенең тәмлерәген куярга тырыша; Сабирәттәйне дә берсе дә ярдәмсез калдырмый)

Әдилә җыры да шуңа ишарәли.

Алтын булып агаемла…

Көмеш булып тамаем…(60 нчы бит)

**Әсәрнең төп идеясе. (**Көтелгән җаваплар)

- Өлкән буын үзенең гомере, сәламәтлеге хакына сугышның ахырын- язны якынайта Сабирәттәй үлеме дә шушы корбаннарның берсе. Инде дилбегә «Язгы кәрваннар»- яшьләр- кулына күчә. ( Кәслегә барганда буран чыккач, яшьләрне кәрванның алдына куялар) Бу символик мәгънәгә ия, димәк, сугыштан соңгы тыныч тормыш төзү нәкъ менә шушы яшүсмерләр кулында булачагына ишарәләнә.
- Кәрван алдындагы кешеләр эз салып бара, алар кая барса кәрван да шул якка бара бит.
- Хәкимҗан абый Ибраһимга: «Даула син үскәнем, даула. Әгәренки дауламасак, эшебез җайга китәчәк түгел безнең. Тракторын да, машинасын да- барын да даула.» (64 нче бит) Илне сугыш ялангачлыгыннан явызлыгыннан, тотолитар система алып килгән афәтләрдән тыныч, җылы, гадел тормышка бары тик алар гына алып чыга алганын искәртә автор. Хәкимҗан абзый аша, **автор позициясе** чагыла. Ул яшьләрне актив булырга чакыра.

**4. Рефлексия**


**Ә хәзер дәрескә куелган уку мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк әле**.

**Бу авылыкларны алар нәрсә хисабына җиңеп чыга алганнар соң ?**

( Җаваплар тыңланыла. Көтелгән җавап: Күркәм холык һәм бердәмлек)

**Әлеге яшүсмерләр нинди холыклы булганнар соң?** ( Җаваплар тыңланыла)

**Слайд № 8** Әйдәгез әле, без дә беренче номерлы эш кәгазенә нигезләнеп, күркәм холык моделен ясап карыйк. **(Һәр төркем үз күркәм холык моделен төзи һәм аны яклый)**




**3 нче этап**

**Слайд №9 Укучылар, сез бүген бик уңышлы эшләдегез, әйдәгез әле, дәрес дәвамында үзбәя кәгазьләрендәге билгеләрне гомумиләштирик һәм группаларда эшебезне бәялик, куйган билгебезне дәлиллик.** (киңәшләшү өчен вакыт бирелә)

**Сез яшьләр! Сез - бүгенеге заман яшүсмерләре! Димәк, киләчәк дилбегәсе кем кулында? Кайчандыр Ибраһим, Әдилә, Дамирлар «кәрван » алдына баскан кебек, тиздән безнең кәрван алдына кемнәр басарга тиеш соң? Шулай булгач, безнең картлыгыбызның, сезнең киләчәгегезнең нинди булуы кемнән тора? Безнең «кәрваныбыз» сикәлтәле гомер юлыннан көчле, шәп барсын дисәк, сезгә нинди булырга кирәк соң? Ә моның өчен эшне каян башлыйк?**

**Слайд №10 Өй эше: 1. Әдилә, Ибраһим, Дамирның холыкларын, темпераментларын күз алдында тотып, аларның алдагы тормышлары турында эссе яз (1 бит)**

**2. Бөек Ватан сугышы чоры яшүсмерләренең рух ныклыгын сурәтләп, 2038 елдагы яшьтәшеңә хат яз.**

**3. Киләчәк бүгеннән башлана дигән фикерне дәлилләп, реклама яз.**

**Кулланылган әдәбият**

1.Ганиева Ф.Ә., Рамазанова Ч.Р. \ Әдәбият, 8 нче сыйныф, татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы, икенче кисәк\Казан\ Татар Китап Нәшрияты, 2015.-57-85 бит

2.Миллият сүзлеге/ Казан «Мәгариф» нәшрияты, 2007.-526 бит


3.Муслимов Н. А., Уразова М. Б. Формирование профессиональной компетентности будущего педагога посредством использования технологии коллективной мыслительной деятельности (КМД) на занятиях педагогики // Молодой ученый. — 2012. — №11. — 462-464бит.

4.Симонов П. В., Ершов П. М \Темперамент. Характер. Личность\Академия наук СССР\ Москва,1984


5.http://studopedia.ru/1_51530_noveyshie-pedagogicheskie-tehnologii.html

**Кушымта №1 (һәр группага тарату өчен )**

**Эш кәгазе №1**




**Эш кәгазе №2**




Кушымта №2 (Һәр укучыга бирелә)

| тезис | әйе | юк |
|---|---|---|
| Әсәрдә символлар: кәрван, җыр, бүреләр, җил | + | |
| Дамир, Әдилә, Ибраһим- ярдәмче геройлар | | - |
| Элеваторга 7 атта, 7 кеше бара | + | |
| Кәслекгә 75 чана кузгала | + | |
| Ибраһим белән Әдилә эт улаганын ишетәләр | | - |
| Гыймай Фатихының кызы Гөлбәдәр табынга арыш ипие куя | | - |
| Кәследән семена алып кайтышлый, алар Чокырлы кешеләрен очраталар | + | |
| Иң авыр вакыйга кайтканда, завод тавында, Сабираттәй язмышы белән бәйле | + | |
| Әдилә чана бавын, шәлен рәтләгәндә, Дамирга тоттыра | | - |

Бәяләү кәгазьләре (Һәр группага бирелә)

| Эш төре | 1 нче укучы | 2 нче укучы | 3 нче укучы | 4нче укучы | Гомуми нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| Темпераментларны билгеләү:<br><br>Эш кәгазе №1 (1 нче өлеш) | | | | | |
| Индивидуаль эш: әсәрнең эчтәлеген белү | | | | | |
| Группаларда эш: геройларга характеристика<br><br>Эш кәгазе №1(2 нче өлеш) | | | | | |
| Рефлексия: | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| күркәм холык моделен ясау (кушымта №2) | | | | | |
| Гомуми нәтиҗә | | | | | |

## Кышкы табигать

*4 нче сыйныф, рус төркеме*

**Фатыйхова Флүзә Әнәс кызы,**
*Алабуга шәһәре*
*Аерым предметлар тирәнтен*
*өйрәнелә торган*
*9нчы урта гомуми белем мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Предмет:** әдәби уку.

**Дәреслек:** Татар теле. 4 нче сыйныф: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен) Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә. Гыйниятуллина - Казан: Татармультфильм, 2014. – 152 б.

**Максат:** укучыларның туган як табигате темасы буенча сөйләм телен үстерү, сөйләм байлыкларын арттыру, табигатькә сакчыл караш һәм хайваннарга карата ярдәм итү хисе тәрбияләү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру.**

Регулятив УУГ: эшчәнлекне планлаштырырга, үз алдыңа максат куя белү, эш тәртибен аңлап, эшли белү, эш сыйфатыңа нәтиҗә ясау.

Танып-белү УУГ: дәрестә ориентлаша белү, төрле биремнәр үтәү, проблема кую һәм аны чишү.

Коммуникатив УУГ: әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү, аралашу холкы белән идарә итү.

**Дәрес тибы:** лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү дәресе (ЛГКК).

**Эш формалары:** фронталь, индивидуаль, парлап һәм төркемнәрдә эшләү.

**Җиһазлау:** проектор, компьютер, презентация, биремнәр язылган карточкалар, имтихан биремнәре, бланклар, татарча музыка, проект эшләү өчен А3 форматындагы кәгазь, маркерлар, төсле кәгазьләр, җилем, кайчы, степлер, чыршы рәсеме, уенчыклар.

**Дәрес барышы:**

**1) Дәресне оештыру:**

- дәрескә әзерлекне тикшерү;
- исәнләшү

(- Исәнмесез, укучылар. – Исәнмесез.

- Хәлләрегез ничек? – Рәхмәт, яхшы.
- Ә сезнең хәлләрегез ничек? – Рәхмәт, яхшы.

**2)Актуальләштерү:**

**А)Сорауларга җавап бирү .**

(укучылар бер-берсеннән сорыйлар)

- ..., спроси у партнёра по плечу, сегодня какое число (Бүген ничәнче число?)
- ..., спроси у партнёра по плечу, сегодня какой день недели (Атнаның нинди көне?)
- ..., спроси у партнёра по плечу, сегодня какая погода (Бүген һава торышы нинди? (салкын, җилле, ...))

**Б)Фонетик зарядка.**

- Әйдәгез, уку дәресендә дөрес, матур сөйләшү өчен телгә фонетик күнегү эшлик. (Сүзләрне укытучы укый, укучылар хор белән кабатлыйлар, бу сүзләр нинди темага карый? сорауга җавап әзерлиләр)
- Куян, урман, сарык, ат, тиен, төлке, яши, сыер, ашый.
- Бу сүзләр нинди темага карый? (Хайваннар дөньясы)
- Без нинди теманы өйрәнеп беттек? (Хайваннар дөньясы)

**В) Ситуатив күнегүләр.**

✓ **Спроси у друга:**

- Любит ли он животных; (Син җәнлекләрне яратасыңмы?)
- Каких животных он любит; (Син нинди җәнлекләрне яратасың?)
- Каких лесных животных он знает; (Син нинди җәнлекләрне беләсең?)
- Каких домашних животных он знает; (Син нинди йорт хайваннарын беләсең?)

✓ Представим, что вы в зоопарке. Тебя интересует, чем питается медведь, лиса, белка, заяц, еж, волк. Как ты спросишь об этом у экскурсовода? Работаем в парах, один из вас посетитель зоопарка, другой экскурсовод.

(- Әйтегез әле, аю, ... нәрсә белән туклана?)

**2) Төп өлеш. Яңа теманы үзләштерү.**

**А) Табышмаклар белән эш.** (Укытучы укый, укучылар җавап бирә, бу табышмаклар нәрсә турында?)

✓ Йомшак карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән,
Бөтен җир
Кардан ак тун кигән. (Кыш)

✓ Бабай килгән сагынып,
Ак тунын ябынып. (Кыш)

- Димәк, без бүген нинди ел фасылы турында сөйләшәбез? (Кыш)

Бүген өйрәнгән сүзләрне кабатларбыз, белемнәребезне ныгытырбыз. Без сезнең белән кышкы урманга экскурсиягә барырбыз. Җәнлекләр безгә бүләк әзерләгәннәр, без бу бүләкне табарга тиеш. Бүләкне табу өчен биремнәр эшләргә кирәк булыр. Кышкы урманда җәяү йөреп булмый, безгә чаңгылар кирәк. Әгәр сүзләрнең тәрҗемәләрен белсәк, безнең барыбызның да чаңгылары булыр.

**Б) Сүзләрне кабатлау.**

Ә хәзер сүзләрне кабатлыйбыз: (сүзләр слайдта чыга, укытучы артыннан кабатлыйлар, тәрҗемәсен әйтәләр.)
Кыш – зима
Кыш көне, кышын – зимой
Кышкы көн – зимний день
Салкын – холодно
Буран – метель
Кар ява –снег идет
Җил исә – ветер дует
Көннәр кыска – дни короткие
Төннәр озын – ночи длинные
Су туңа – вода замерзает
Боз белән каплана – льдом покрывается
Бәс – иней
- Барыбызда чаңгылы булдык, урманга киттек.

**3) Ныгыту.**

**<u>А) 1 нче тукталыш</u>.**

- Безне тиен каршы алды.
Ул безгә бирем әзерләгән. Әгәр биремне үтәсәк, урманга керергә рөхсәт бирәм, ди
(Бирем карточкаларга язылган, сүзләр бирелгән, шул сүзләрдән җөмләләр төзиләр, сорау җөмләләр ясыйлар, һәр төркемгә аерым сүзләр (ФИНК-РАЙТ-РАУНД-РОБИН, җавапларны язалар, киңәшләшәләр):

- ✓ Кар, урамда, ява, йомшак. (Урамда йомшак кар ява.)
- ✓ Кар, ясадылар, бабай, балалар. (Балалар Кар бабай ясадылар.)
- ✓ Туңа, кыш, су, көне. (Кыш көне су туңа.)

**<u>Б) 2 нче тукталыш</u>.**

- Куян да безне көтеп тора. Ул безгә нинди бирем әзерләгән икән?
(Диалогта төшеп калган репликаларны тулыландырып сөйләргә)

<u>1, 2 нче номерлы партнерларга.</u>

- Сәлам, ... .
- Сәлам, ... .
- ...?
- Юк, чыкмыйм.
- Ни өчен?
- ... .

<u>3, 4 нче номерлы партнерларга.</u>

- Сәлам, ... .
- Сәлам, ... .
- ..., әйдә урамга чыгабыз.
- Әйдә. ...?
- Юк, салкын түгел, кар гына ява.
- ... .

**В) Ял минуты.**

**Кышкы урманда**

Кышкы урманга килдек,
Матур урыннар күрдек.
Тун кигән каен – уңда,
Ямь-яшел чыршы – сулда.
Кар бөртекләре оча,
Әйләнеп җирне коча.
Әнә куян сикерә,
Ул бүредән элдертә.
Кызылтүшләр очалар,
Бигрәк тә матур алар.

**<u>Г) 3 нче тукталыш</u>.**

- Ябалак та безгә бирем әзерләгән.

(Кыш турында хикәя бирелгән, биремнәрне имтихан бланкларында эшлиләр, соңыннан бер-берсенең эшләрен тикшерәләр)

Кышкы урман бик матур кар өстендә җәнлек эзләре (следы) күренә аю, керпе кар астында йоклыйлар тиен чикләвек, гөмбә ашый куян ак тунын кигән кышын җәнлекләргә авыр кешеләр аларга ярдәм итәргә тиеш.

В1. Сколько предложений в этом тексте?

В2. Найдите и запишите из текста правильный перевод слова: зимой.

В3. Найдите и запишите из пятого предложения глагол неопределенного прошедшего времени.

В4. Найдите и запишите в первом предложении прилагательное в превосходной степени.

**<u>Д) 4 нче тукталыш</u>.**

- Безне төлке каршы ала. Ул безгә сораулар әзерләгән.
- *Сез кышны яратасызмы?*
- *Ни өчен?*

(МИКС ПЭА ШЭА. Музыка астында сыйныф буенча йөриләр, музыка туктагач парлашалар, бер-берсенә сорау бирәләр, берничә парның җавабы тыңланыла.)

- Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, ә җәнлекләр кышны яраталармы? Ни өчен?

(Укучыларның җавабы тыңланыла, хайваннарга ярдәм итү турында әңгәмә)

- Әйдәгез, без сезнең белән хайваннар өчен урманда ашханә төзибез. (РАФТ, укучылар проект эше эшлиләр. Урмандагы хайваннар өчен ашханә төзиләр)
- Укучылар, булдырдыгыз. Хайваннар да безгә менә нинди бүләк әзерләгәннәр. (Чыршы, аңа конфетлар беркетелгән)

**4) Өй эше.**

Карточкаларда бирем. Кыш турында хикәя, җөмләләрне дөрес тәртиптә урнаштырырга. (Алар кышны яраталар. Балалар урамга уйнарга чыктылар. Кыш килде. Балаларга бик күңелле булды. Урамда көн матур. Алар тау ясадылар, чанада шудылар.)

**5) Йомгаклау, билгеләр кую.**

**6)Рефлекция** “Кәеф чыршысы”. Кем дәрестә биремнәрне эшләргә җиңел булды, мин барысын да аңладым ди, алар чыршыга алсу уенчыкларны беркетә, кем биремнәрне эшләргә авыррак булды, мин барысын да аңлап бетермәдем ди, алар

чыршыга яшел уенчыкларны беркетә, кем биремнәрне эшләргә авыр булды, мин бернәрсә дә аңламадым ди, алар чыршыга сары уенчыкларны беркетә.

## **“Чөнки, шуңа күрә теркәгечләре”**
## ***(“Безнең Татарстан” тексты буенча)***

**Шайдуллина Гүзәл Хатмулла кызы,**

*Алабуга муниципаль районы*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*“Россия Федерациясе Герое А.Н.Епанешников исемендәге*
*3 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Класс: 6 нчы сыйныф (рус)

Укытучы өчен:

1. Белем бирү максаты:

Татарстанның климаты, анда яшәгән хайваннар турында сөйли белү, Дәлилләр китергәндә теркәгечләрдән файдалану.

2. Үстерү максаты:

Укучыларны актив аралашуга, иҗади сөйләшүгә тарту; гомумиләштереп нәтиҗә ясый белү күнекмәләренә өйрәтү.

3. Тәрбия максаты:

Укучыларның Татарстанга карата кызыксынуларын арттыру; туган якка мәхәббәт тәрбияләү.

Укучы өчен:

Өйрәнелгән лексиканы аңлап куллана белүләренә ирешү, теркәгечләрне актив сөйләмгә кертү; Татарстан турында сөйли белү.

Дәрес барышы.

I. Оештыру.

1. Уңай психологик халәт тудыру.

Укытучы. Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! Кәефләрегез ничек?

II. Актуальләштерү

Бирелгән, сүзләрне ике төркемгә аерып языгыз. (төркемдә эш) Укучыларга төркемнәрдә эшлиләр һәм ничек бүлгәннәрен аңлаталар.

*Татарстан, чөнки, хайваннар, елгалар, шуңа күрә, климат, ләкин, һәм.*

Көтелгән нәтиҗә: Беренче төркем исемнәр: Татарстан, хайваннар, елгалар, климат

Икенче төркем теркәгечләр: чөнки, шуңа күрә, ләкин, һәм

Дөрес,укучылар. Беренче төркем сүзләре белән узган дәрестә таныштык. Ә бүгенге дәреснең темасын кем әйтергә тели. Димәк икенче төркем сүзләр безнең теркәгечләр. (Дәреснең темасы әйтелә).

Нинди максатлар куябыз. Татарстан турында сөйләү һәм сөйләмдә теркәгечләрне куллану.

Сүзләр тәрҗемә итү

Сүзтезмәләр әйтү

Сүзтезмәләр белән җөмләләр төзү.

**Нәтиҗә ясала. Димәк, чөнки, шуңа күрә теркәгечләрен кайчан кулланабыз? Дәлилләр китергәндә**

III. Яңа белемнәр бирү

Уку мәсьәләсен адымлап чишү.

Текстны кычкырып уку

6 эшләпә алымы белән анализлау

Укучыларга төрле төстәге эшләпәләр таратыла.

1. Ак эшләпә. Укучы бары тик фактлар белән генә эшләргә тиеш. Хисләр, субъектив бәяләр бирүнең кирәге юк.
2. Сары эшләпә. Бары тик уңай фикерләр генә әйтелә. Һәр вакыйганың, образның позитив яклары турында сөйләнә. Ни өчен шулай уйлаулары турында аңлаталар.
3. Кара эшләпә. Бу эшләпәне алган төркем киресен, ягъни вакыйгаларның яки геройларның тискәре яклары турында гына сөйли. Килеп чыккан проблемаларга бәя бирә. Тискәре сыйфатлар булмаска да мөмкин
4. Кызыл эшләпә. Бу эшләпә төркеменә хисләр турында сөйләү кирәк. Алардан эмоциональ фикерләү таләп ителә.
5. Яшел эшләпә. Бу эшләпәне алган төркем башкалардан иҗади булуы белән аерылып торырга тиеш.
6. Зәңгәр эшләпә. Бу эшләпә фәлсәфи фикер йөртү турында. Ул дәрескә йомгак ясарга ярдәм итә. Гомуми нәтиҗәләр чыгарыла. Бу эшләпә “хуҗалары” башкаларның фикерләрен игътибар белән тыңларга тиешләр, чөнки алар алдында иң җаваплы бурыч – барлык төркемнәрнең җавапларын берләштереп, нәтиҗә чыгару тора.

Шушы алым белән текст анализлана.

IV. Физкультминутка

V. Белемнәрне ныгыту.

1. Синквейн төзү.Төркемнәрдә шушы темалар буенча синквейн төзелә

Татарстанның табигате.

Татарстанның климаты.

Синквейн буенча сөйләү

Текст буенча сөйләшү үткәрәбез.

2. Сораулар буенча җөмлә төзү.( бер укучы сүз яза һәм иптәшенә бирә. Шулай сорау сүзләре беткәнче дәвам ителә. Соңыннан укыйлар, җөмлә дөрес төзелгәнме, юкмы тикшерелә)

Нинди? Кем? Кайчан? Кайда? Нишли?, шуңа күрә Нинди? Нәрсә? Нишли? Кем? Кем белән? Кайда? Ничек? Нишлиләр, чөнки Нинди? Кемнәр?

VI. Өй эше. 7 күнегү Текстның эчтәлеген сөйләргә.

Текст буенча рәсем ясарга

Кечкенә генә хикәя төзергә.
VII. Рефлексия.
Укытучы. Дәрестә бүген нинди максат куйган идек?
Максатка ирештекме? Татарстан турында нәрсәләр белдек?
Гомуми бәя кую.
Бәяләү битен тутыралар

**Бәяләү бите**
**ФИО сыйныф________________________________**
**+ эшли алам /беләм** могу\ знаю
**+\-шикләнәм** сомневаюсь
**-эшли алмыйм/ белмим** не могу\ не знаю белмим

| № п \ п | Критерийләр /Критерий | Үзем/ Сам/Сама | Укытучы/ Учитель |
|---|---|---|---|
| 1 | Дәреснең темасын беләм<br>Знаю тему урока | | |
| 2 | Дәреснең максатын беләм<br>Знаю цель урока | | |
| 3 | Текстны яхшы укый алам<br>Могу хорошо читать текст | | |
| 4 | Текст буенча сорауларга җавап бирә алам<br>Умею отвечать на вопросы по тексту | | |
| 5 | Текст буенча үзем сорау төзи алам<br>Сам могу составить вопрос к тексту | | |
| 6 | Группада эшли алам<br>Умею работать в группе | | |
| 7 | Үз фикеремне исбат итә алам<br>Могу доказать свои высказывания | | |
| 8 | Дәрестә үземнең эшемне бәяли алам<br>Могу оценить свою работу на уроке | | |
| 9 | Дәрестә иптәшләремнең эшләрен бәяли алам<br>Могу оценить работу своих товарищей | | |
| 1 | Дәрес файдалы үтте дип әйтә алам<br>Могу сказать что урок прошел с пользой | | |

**Ихсан Әхтәмнең “Ана рәхмәте” хикәясе**

**Шафикова Гүзәлия Рәхимша кызы,**

*Алабуга муниципаль районы*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*“Россия Федерациясе Герое А.Н.Епанешников исемендәге*
*3 нче урта гомуми белем мәктәбе” нең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Максат:**

**1. Белем бирү максаты:**

- балаларны И.Әхмәтнең “Ана рәхмәте” хикәясенең эчтәлеге белән таныштыру;
- анда өйрәнелгән лексиканы актив кулланылышка кертү.

**2. Үстерү максаты:**

- укучыларның эзлекле фикерләү сәләтен үстерү;
- текстта ориентлаша белүне үстерү;
- -диалогик, монологик сөйләм үстерү;

**3. Тәрбия максаты:**

- аналарга ихтирамлылык хисләре тәрбияләү;
- өлкәннәргә, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү;
- парларда, төркемнәрдә эшли һәм аралаша белү осталыгына өйрәнү
- бер-береңне тыңлый, бәяли, төзәтә белү

**Дәрес тибы**: ЛКК

**Дәрес материалы, җиһазлау: презентация “Ана рәхмәте”, тест, рәсемнәр, карточкалар.**

**Дәрес барышы:**

I. <u>*Мотивлаштыру (оештыру, уку эшчәнлегенә мотивация булдыру*)</u>

1. Уңай психологик халәт тудыру. *(положительный настрой)*

- Исәнмесез, укучылар!
- Исәнмесез!
- Хәерле көн!
- Хәерле көн!
- Кәефләрегез яхшымы?
- Әйбәт, яхшы. Ә сезнең хәлләрегез ничек?
- Минем дә хәлләрем яхшы. Рәхмәт, утырыгыз.
- Бүгенге дәресне сездә мин үткәрәм. Минем исемем Гүзәлия Рәхимшовна.

***II. <u>Актуальләштерү(шушы дәрескә кирәкле белемнәрне генә актуальләштерәбез):</u>***

1) Фонетик зарядка: Татар телендәге авазларны кабатлап китик әле: ә – чәнечке, , ө –өй, ү- үзем, җ – җиләк, , һ – шәһәр, ң- соң,

2) (угадывание темы)

Бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез икән? Бу сорауга җавапны бергәләп табыйк. Экранга карагыз һәм игътибар белән тыңлагыз. Посмотрите очень внимательно видео, догадайтесь о чем мы сегодня будем говорить?

– (презентация о мамах, "Мин әнигә булышам" җыры )

- Какие будут догадки? Нәрсә турында тыңладыгыз?
- Әниләргә булышу турында тыңладык.
- Ә сез әниләрегезгә булышасызмы?
- Әйе. (кул күтәргән бала үзенең ничек булышуын әйтә)
- Ничек булышасыз? Рәсемнәргә карап җавап бирегез.
- (мин тузан сөртәм, мин савыт-саба юам, мин идән юам, һ.б. рәсемнәр буенча сөйләшү (рәсемнәр слайдта)

**III.Уку мәсьәләсен кую (проблемное объяснение новой темы)**

Укытучы: Сез булышкач әниләрегез сезгә нәрсә әйтә?

- Рәхмәт әйтә, мактый.
- Бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез?
- Әниләргә булышу турында.

Укытучы: Әниләргә булышу темасын дәвам итеп, без дәрестә "Ана рәхмәте" хикәясен укырбыз.

- Дәреска максат куйыйк: без дәрестә нәрсәләргә өйрәнербез?
- яңа сүзләр өйрәнербез, әниләргә булышу турында сөйләшербез.( тактагы максатны язам)

***IV.Уку мәсьәләсен чишү (беренчел ныгыту):***

Дәреслекләрне ачыгыз, "Ана рәхмәте" хикәясен табыгыз.

**1)**Текстны укыр алдыннан бер уен уйнап алыйк. ( Кәрзиннәргә "Тәрҗемәче" уенын уйнау. (сүзләр тактада) Дәрес башында кулланган сүзләрне ТАНЫШ СҮЗЛӘР кәрзиненә салабыз, яңа сүзләрне ЯҢА СҮЗЛӘР кәрзиненә салабыз. Ваша задача: положить в корзину "Таныш сүзләр" только те слова, которые мы в начале урока повторили. А слова, которые не повторяли, в корзину "Яңа сүзләр".

- ( "Таныш сүзләр", "Яңа сүзләр" не кәрзингә тутыру.

Таныш сүзләр:, әни, юам, сибәм, себерәм, сөртәм, малай, кыз, булышам, мин, )

Яңа сүзләр: гаҗәпләнде, чисталык, үпте, соң кайтты).

2) Яңа сүзләрнең тәрҗемәсе белән танышыйк. (2 нче слайдта гаҗәпләнде, соң кайтты, чисталык, үпте сүзләренең тәрҗемәсе бирелә)

3) Сүзләрне минем арттан кабатлыйк, укыйм, хор белән кабатлатам..Ә хәзер син кабатла, ...... (шул тәртиптә 1-2 укучыдан кабатлатам. Шул сүзләр белән сүзтезмәләр, җөмләләр төзелә)

4)Балалар, ял итеп алыйк (физкультминутка.)

5) Ә хәзер текстны укыйбыз. Нәрсә турында укыганны аңларга тырышыгыз. (Текстны балалардан укытам (чылбырлап)

Текстны аңладыгызмы? Хәзер ничек аңлаганыгызны тикшереп карыйк:

***V. Тышкы сөйләмдә икенчел ныгыту.***

1) Мин хәзер сезгә русча җөмләләр әйтәм, сез шул җөмләләрнең тәрҗемәсен тексттан табып укыгыз. Найдите предложения, где говорится о том, что:
- сегодня мама поздно вернулась:
- удивилась чистоте;
- кто помыл пол?
- я сам мыл.
- мама поцеловала в лицо.
- мама поблагодарила сына.

2) Диалогик сөйләмгә чыгару өлеше:

2)Работа в парах. Сначала один задаёт вопросы, второй отвечает. Затем вы меняетесь ролями по хлопку!

- Сорауларга җаваплар бирү: сораулар язылган карточкалар алларында. 2 шәр сорау (парларда эшләтү) 30 секунд берсе сорау бирә, икенчесе җавап бирә, кабат 30 сек.икенчесе сорау бирә.
- 3) )Тестны эшләү, экрандагы җаваплар белән тикшерелә, үзләренә билге куялар
- 4) Найдите рисунки, которые подходят к содержанию текста. Дөрес рәсемнәрне экранда күрсәтәм. Ике рәсем дә туры килсә, “5”ле, берсе туры килсә “4”ле куялар.( 3 нче билгеләре)

VI. ***<u>Рефлексия:</u>***

- *Укучылар, без бүген дәрестә нәрсә белдек?*
- Яңа сүзләр өйрәндек, Рөстәм турында хикәя укыдык, сорауларга җаваплар бирдек,
- *Нинди яңа сүзләр өйрәндек?*
- Соң кайтты, гаҗәпләнде, үпте, чисталык.
- *Нәрсә турында сөйләшергә өйрәндек?*
- Әниләргә булышу турында сөйләргә өйрәнек.
- *Димәк, без дәрескә куйган максатларны үтәдек(*<u>тактага язылган максатка кире кайтам)</u>
- *Мин нишләргә телим?*
- Әнигә булышырга телим..
- *Учитель: Перед вами-набор смайликов,оцените себя:*
- -кто понял и запомнил все слова темы?-веселый смайлик
- -у кого остались вопросы-смайлик с вопросом
- -кто ничего не запомнил-унылый смайлик

***<u>Үзбәя. Билгеләр куябыз. (кем үзенә нинди билге куйганын аңлата; кемгә нинди билге икәнне аңлатып куям)</u>***

***<u>VII.Өй эше</u>***

1. *Малай белән әнисе арасындагы диалогны язып бетерергә. (79 бит, 8 нче бирем)*
2. *Текст эчтәлеге буенча 3 сорау җөмлә төзеп язарга.*
3. *Рәсем ясарга: Мин әнигә булышам.*

**Кушымта**

**1.Тактада фигыльнең моделен ясау өчен (1 нче өлештә).**

**ФИГЫЛЬ**

**эш-хәрәкәт**

**нишли?**

**нишлиләр?**

**1 предметның**
**эш-хәрәкәте**

**берничә предметның эш-хәрәкәте**

2. **Укучыларга тарату өчен(3 нче өлештә).**

**җырлый тыңлый тегә пешерә сөйликарый**

**укыйлар кисәләр уйныйларэшлиләркиләләрюалар**

**3. Тест биремнәре (5 нче өлештә)**

Укучының исеме ___________________________________

1. Фигыль нәрсәне белдерә?
а) предметны
б) билгене
в) эш-хәрәкәтне

2. Фигыль нинди сорауларга җавап бирә?
а) кем? нәрсә?
б) нишли? нишлиләр?
в) нинди? кайсы?

3. Кайсы рәттәге сүзләр фигыльләр?
а) утыра, уйлый, сөйли

б) зәңгәр, караңгы, ак



в) китап, дәфтәр, өстәл.

4. Сызыклар урынына тиешле кушымчаларны яз.

Укучылар дәрестә укый______ һәм сөйли______ .

5. **Җырлый** фигыле белән 4-5 сүздән торган җөмлә төзеп яз.

**4. Үзбәя кую өчен карточкалар**

| | |
|---|---|
| <br>1. _____<br>2. _____<br>3. _____<br>Дәрескә билге ______ | <br>1. _____<br>2. _____<br>3. _____<br>Дәрескә билге ______ |

**Кушымта/Приложение**

**Свидетельство о публикации**

**Фотосессия НПК**

**И другие материалы находятся во вложении**